**Илфак Шиһапов**

**Югалту**

Хикәяләр, юморескалар, монологлар, повесть

Казан

Татарстан китап нәшрияты

2012

Шиһапов, И. И.

Ш 50 Югалту : хикәяләр, юморескалар, монологлар, повесть / Илфак Шиһапов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012.

ISBN 978-5-298-02312-2

Илфак Шиһаповның бу китабында язучының төрле елларда иҗат иткән хикәяләре, юморескалары, монологлары һәм повесте урын алды. Автор кешеләр тормышындагы кызыклы, гыйбрәтле күренешләрне үтемле тел белән, көлеп сурәтли.

ISBN 978-5-298-02312-2

Татарстан китап нәшрияты, 2012

Шиһапов И. И., 2012

## Әйтәм бит...

Хикәяләр, юморескалар, монологлар

### Кемгә ничек...

Яңа ел бәйрәме якынлашып килгәндә генә, Җәмил өчен күңелсезрәк бер хәл килеп чыкты – аны колхоз тракторы белән күрше чуваш авылына көмешкәгә

йөргәне өчен трактордан алып, фермага каравылчы итеп куйдылар. Хәер, кайгыруын артык кайгырмады Җәмил, «аракыны аны өйдә эчсәң дә шул, эштә эчсәң дә шул» дигән фәлсәфи уй белән күңелен тынычландырды.

Җәмилнең хәләл җефете Гамилә исә шатланып туя алмады. «И-и, ичмасам, бәйрәм кичләрен бу исерексез генә уздырам икән, – дип уйлады ул. – Утырсын әнә каравыл йортында маллар саклап, тамагын тыя белмәгәч. Юкса ел да бик шәпләп бәйрәм итә иде Яңа елны».

Чыннан да, Җәмил нишләптер Яңа ел бәйрәмен аеруча көтеп ала иде. Кайчандыр каяндыр укыган «Елны ничек каршыласаң, ул шулай үтә» дигән сүзләрне ул беркайчан да исеннән чыгармады һәм, нәрсә генә булса да, Яңа ел өстәленең тәм-том, аннан да бигрәк эчемлек белән тулы булуын алдан ук кайгырта иде. Бәлки, шуңа күрә чын-чынлап айныганы да булмагандыр, күрәсең.

Гамилә исә, үзе генә, төгәлрәге бер-ике күрше хатынын дәшеп, аулак өйдә Яңа ел бәйрәмен уздырырга уйлаганлыктан, алдан ук хәстәрен күрә башлады. Әзрәк Җәмилдән яшереп җыйган акчасы булганга, бу эш авыр тоелмады аңа. Ике-өч шешә аракыга, кәнфит-мазар ише вак-төяккә әллә ни күп акча кирәкми иде. «Берәр тәмле әйбер пешерергә булыр, – дип уйлады хатын. – Аллага шөкер, бәрәңге җитәрлек, ит бар».

Ул: «Яңа елны бездә уздырабыз», – дип, җан дуслары Сәрия белән Әминәне алдан ук дәшеп куйды. Сер түгел: Гамилә дә, нәкъ Җәмил кебек үк, Яңа елны ничек каршыласаң, ел шулай үтә дигән сүзгә ышана иде. «Җәмил каравылында айнык утырса, шәт, киләсе елны эчмәс» дигән уе да бар иде хатынның.

...Үтеп бара торган елның соңгы көне тиз килеп җитте. Төнге каравылдан кайткан Җәмил көне буена диярлек диванда йокы симертте, ә Гамилә алгы якта плитә янында кайнашты.

Кич җитте. Йокысыннан кәефсез генә уянган Җәмил, нидер эзләгәндәй, өй буенча арлы-бирле йөренде. «Тизрәк каравылына китсен иде бу», – дип уйлады Гамилә, аны-моны дәшмичә генә. Ул Җәмилгә ашарга да көндәгечә

такы-токы гына куйды: «Бу исерек тәре тәмле ашатканны барыбер аңламый бит. Әзрәк эче чурласын әле. Бирмим бернәрсә дә...»

Сәгать кичке җиде тулгач, Җәмил мыштым гына киенде дә, капкаларлык ризык төйнәлгән төенчек алып, фермага китте. Дөресен генә әйткәндә, башын аска игән, моңсу карашлы иренең шушындый бәйрәм кичендә дә эшкә китүен күргәч, Гамилә аны жәлләп тә куйды. Тик хатын үзеннән мондый йомшаткыч уйларны тиз куды. «Күп эчте инде, күп бәйрәм итте. Әз генә киләчәккә сабак булыр». Хатын өстәл әзерләргә кереште.

Бергә Яңа елны каршыларга дип чакырылган Әминә белән Сәрия кичке тугызга килергә тиешләр иде. Икесе дә ирсез бу хатыннар да аз-маз пешеренеп килергә тиеш булганга, өстәл бик мулдан булыр дип уйлады Гамилә.

Сәгать тугыз тулгач, ул телевизорны кабызды, ашка барганда гына кия торган күлмәген киде. Көзге алдында чәчләрен рәтләгәндә, Гамилә тагын Җәмилне исенә төшерде. «И-и, утыра бугай каравыл өендә кукраеп, – хатын көлемсерәп куйды. – Ничава, утырсын, сакласын сарыкларын».

Сәгать унга якынлашты. Нишләптер Сәрия белән Әминә һаман күренмәде. «И-и, ул карт алашалар җыенганчы... – дип уйлады Гамилә. – Әле унбергә килеп җитсәләр, рәхмәт әйтерсең».

Ләкин ахирәтләр унбердә дә, уникенче яртыда да күренмәде. Гамиләнең бөтенләй кәефе төште. «Кара син аны, – дип уйлады ул, – тол хатын кебек утыр инде берүзең Яңа ел каршылап. Теге ике убыр киләбез дип вәгъдәләр бирделәр бит үзләре. Соң, кая йөрерләр икән, ә?» Сәгать телләре уникегә якынлашты. Гамилә авыр сулап куйды, берүзе булса да өстәл артына утырырга булды. Аның нигәдер өстәл тулы тәм-томга да исе китми иде инде. Хатын ачу белән бер яртының бөкесен каерып ыргытты да бер бокалга аракы койды.

Сәгать уникене суга башлады. «Эх, җитмәсә, Җәмиле дә өйдә юк, – дип уйлады Гамилә, тамагын яндырып төшеп киткән аракы артыннан

кыздырылган тавык ите чәйни-чәйни. – Ул әле Яңа ел җиткәнен дә белмидер, мескен. Сәгате дә юк бит аның».

Гамилә тагын бер чәркә салып эчте. Эчми эчкән нәрсә хатынның башына китте, ахрысы, – ул утырган урынында чайкалып куйды. «Карале, – дип уйлады Гамилә, – соң, аракы кабымлыгын алып, Җәмил янына барсам? Анда аңардан башка беркем юк. Утырырбыз икәү яшь чактагы кебек. – Хатын елмаеп куйды. – Сәке-мазар бар бугай каравыл йортында. Әминәләр йөрсен аптырап, ир хатыны ла мин...»

Гамилә сумкага ике шешә аракы, кабымлык тутырды да ашыга-ашыга киенә башлады...

...Колхозның каравыл йорты авылдан читтәрәк, сарык фермасы белән янәшә урнашкан иде. «И-и, мескенкәем, – дип уйлады хатын, тар гына сукмактан атлый-атлый. – Шушындый бәйрәм көнне ярым ач утыра бит ул».

Каравыл өе ягыннан ишетелгән тавышка Гамилә артык игътибар итмәде. Тавышның ниндидер җыр авазлары икәнен аңлагач кына, хатын бераз сәерсенеп куйды. «И Ходаем, әллә саташкан инде Җәмил, – дип уйлады ул. – Берүзең төннәр буе шушындый җирдә утыр инде...»

Каравыл йортының авыр ишеген ачу белән, Гамиләнең күзләре камашып китте. Өй эче халык белән тулы иде. Яхшылап себерелгән идән уртасында ашамлык-эчемлектән сыгылып торган өстәл артында кинәт исәрләнеп киткән хатын бик кәефле генә утырган Җәмилне, аның җан дусты Гарифны, Кар кызы киеменә киенгән Әминәне, инде «кәкрәеп» өлгергән Сәрияне күреп алды. Җитмәсә, өй түрендә гөлт иттереп бизәлгән чыршы да балкып утыра иде. «И Ходаем, – дип уйлады Гамилә, лып итеп бусагага утыргач. – Күрәселәрем бар икән әле...»

**«Дәва»**

Әллә нәрсә эшләде соңгы вакытта Фәрит. Тамырлары белән Казан ягыннан булса да, теле Озын Улак халкыныкыннан аерылып торганга, Мишәр кушаматы тагылган ир чын-чынлап, ягъни, Җәмил әйтмешли, «настояший»

итеп эчкәне булмагангамы, әллә бүтән берәр сәбәптәнме, узган төнне дә йоклый алмый интекте. Төн узганчы, ул үзе кебек ике кеше сыярдай трусигын төнге талгын җилдә җилфердәтеп, ишек төбендә баш-алты тапкыр тартып керде, алгы якта салкын чәй эчте.

Әллә нәрсәләр турында уйлады Фәрит бу төнне, ләкин һәр уе аны инде егерме елга якын бергә торган хәләл җефете Саниягә алып килде. «И-и, азаплаганмын да инде мин бәгырькәемне, – дип уйлады Фәрит, киң караватның бер почмагында тыныч кына мышнап йоклап яткан хатынына карап. – Эчкәләдем, көнләдем. Ярый кул күтәргәнем булмады әле». Үз уйларыннан Фәритнең кинәт күзләре яшьләнде, борыны йомшап китте. «Нишләп болай соң бу тормыш, – дип уйлады ир. – Яратам бит мин аны». Күңелен җилкендергән хисләрдән Фәритнең кинәт хатынын кысып-кысып кочаклыйсы килеп китте. Йөрәге кузгалган ир, чыгып, тагын тартып керде. «Борчымыйм инде, йокласын тынычлап», – дип уйлады ул.

Иртә белән эшкә китәр алдыннан, чәй эчкәндә, Фәрит Саниягә озак кына карап торды да: «Яратам мин сине, Сания», – дип әйтеп куйды. Кинәтрәк әйтелгән бу сүзләрдән хатын, сискәнеп, чәен түкте.

– Сорама да, бирмим дә баш төзәтергә, – диде ул, өстәлне сөртә-сөртә. – Эштән иртәрәк кайт бүген. Сарыкларның йонын аласы бар.

Хатынның бу кадәр дә агач йөрәкле булуыннан гаҗиз калган Фәрит ашык-пошык киенде дә эшкә китте.

Урамда аңа Озын Улакта хатын-кызны иң яхшы белүче исәпләнгән Җәмил очрады. Алдагы көнне бүген үзе дә хәтерләмәгән ниндидер бәйрәм хөрмәтеннән туйганчы эчкән Җәмил, бүген дә берәр бәйрәм түгелме икән дигәндәй, моңсу гына уйланып, фермага таба атлый иде.

– Кара әле, Җәмил, – диде Фәрит, авылдашы белән күрешкәч. – Менә син яратасыңмы хатыныңны?

Бу сүзләрдән Җәмил барган җиреннән егыла язды. Аннары ул шып туктады да махмырдан тагын да моңсуланып киткән соргылт күзләрен Фәриткә төбәде.

– Айнымыйча эчеп йөргәнең дә юк кебек, – диде ул җитди тавыш белән. – Әллә соң нәселегездә бар идеме сезнең?..
– Юк ла, – диде Фәрит, башын аска иеп. – Менә үзем дә аңламыйм күңелне... Егерме ел уйлаган да юк иде, хәзер әллә ничек, Сания янымда булмаса, йөрәгем шартлап ярылыр кебек.
– Алай икән, – Җәмил күзләрен кыса төшеп башын чайкап куйды. – Үзенә дә әйттеңме?
– Әйттем инде, – Фәрит тагын башын аска иде. – Ну, аңламый ул мине, ышанмыйдыр да, күрәсең. Соңгы вакытта эчкән дә юк, өйдә дә гел булышырга тырышам үзенә. Йокларга ятканда аякларны да юып ятам, ә Сания аның саен читләшә генә кебек...
– Вәт аңгыра, – Җәмил тәмәке кабызды. – Алай булгач шәһәрдән рауза чәчәге дә алып кайтып бир. Әнә Күзлек Гамиры хатынына, бәрәңге кәтмәнләгәндә дә, ызаннан чәчәк җыеп бирә, ди. Хатыны торганчы, иртән чәй дә әзерли, имеш.
– Син бигрәк инде, Җәмил, – диде Фәрит, нишләптер кызарынып. – Гамирның аңгыра икәнен бөтен авыл белә бит. Ә мин менә чынлап... Билләһи, үзем дә аңламыйм. Җитмәсә, салмый башлагач, Сания дә кырын карый.
Фәрит тә нишләптер калтырый башлаган куллары белән кесәсеннән тәмәке чыгарды.
– Инде тәмәкене дә ташлый язган идем.
– Ала-ай, – дип сузды Җәмил. – Сезнең гаилә корабы аңлашылмаучылык кыяларына бәрелергә бара икән. Сезне, туган, сручны дәваларга кирәк, эзгә салырга ягъни мәсәлән.
Җәмил бераз уйланып торды. Аннары бөдрәләнеп торган чәчләрен сыпырып куйды.
– Бүген эштән кайтышлый бер литрыңны алып керерсең безгә, – диде ул. – Башларга шул җитәр...

...Бер литрдан башланачак дәвага бик ышанып җитмәсә дә, Җәмилнең тәҗрибәсенә күңеле белән инанган Фәрит бу көнне тыныч кына эшләде. Кичкә таба, ике шешә аракы тотып, өенә кайтканчы, ул Җәмилләргә керде.

«Дәва» курсын Фәриткә кадәр үк башлап җибәргән Җәмил аны кырлы стакан, ярты ипи, бер баш суган белән өй артында көтә иде инде.

– Син тиле, Фәрит, – диде Җәмил, беренче шешәнең яртысына төшкәч, суган чәйни-чәйни. – Хатын-кыз үзен яраткан ирне беркайчан да ратмый ул. Ә менә аны яратмаган ир аңа кызыклырак. Ул кәнтәйләр бит бар да үзләрен, һич югы, йә Зөһрә, йә Зөләйха дип хис итә. Ишеткәнең бармы Таһир-Зөһрә, Йосыф-Зөләйха турында?

Җәмил беренче шешәне бәрәңге бакчасы ягына томырды да икенчесенең бөкесен каерып ыргытты.

– Алар гомерләре буе ниндидер сер көтә, аңладыңмы? Үзләрен яраткан ир алар өчен кызык түгел. Соң, менә сине генә алыйк. Егерме ел буе ишәк кебек эшләдең инде син. Ну, аз-маз эчкәләгәнсеңдер. Кеше белән йөрмәдең. Йомшак бит син. Сания шуны белә, эченнән генә «Кая китсен миннән бу мүкләк?» дип уйлый. Ул эчмә дисә эчмисең, эчсәң куркасың.

Җәмил стакандагы аракыны йотып куйды да тагын тутырып Фәриткә салды.

– Һе, яратам, имеш. Ә кайсы хатын-кызның йомшакны ратканын күргәнең бар. Катылык кирәк аларга барысына да. Син йомшаган саен, алар зәһәрләнә генә бара. Урынга аягын юып ята, имеш...

...«Дәвалау» кичкә кадәр сузылды. Ике шешәдән соң «дару» тагын табылды.

Бу көнне Фәрит өйләренә гомердә булмаганча исереп кайтты. Ишек төбендә үзен каршы алган Санияне әллә нинди урыс сүзләре белән сүгә-сүгә өйгә кергәч, башта сөрлегеп өстәлне әйләндереп каплады, аннары, пычрак резин итекләрен дә салмыйча, урынга менеп ятты. Яткач та тиз генә тынычлана алмыйча, үзенә комачаулаган мендәрне аптыравыннан нәрсә әйтергә дә белми катып калган Саниягә таба томыргач кына, гырлап йокыга китте җене купкан ир...

...Фәрит иртә белән уянганда, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Ул, ыңгырашып, тубалга әйләнгән башын күтәрде. Караван янында бер кулына стакан, икенчесенә ипи телеме тоткан Сания басып тора иде.
– Мә әле, җаныкаем, – диде хатын гомердә булмаган йомшак тавыш белән. – Менә шушыны тотып куй әле. Хәлең бик авырдыр. Аннары бүген эшкә дә барып йөрмәссең инде, чирли ул, дидем иртән бригадирга. Әзрәк ял да кирәк үзеңә...
«Кеше түгел, әүлиядыр бу Җәмил, – дип уйлады Фәрит, стакандагы аракыны эчкәч, ипи чәйни-чәйни. – Билләһи, әүлиядыр...» «Дәва» файдага киткән иде.

**Көтелмәгән хәл**

Көзнең чалт аяз бер көнендә, Күзлек Гамиры әйтмешли, катаклизмнарга күнеккән Озын Улак халкының яшәешен тетрәндергән бер хәбәр авыл буенча таралды: имештер, Колга Җәмиле эчүен ташлаган. Җәмилнең үзен белмәгән кеше өчен бу хәбәр, бәлки, куркыныч та булып тоелмас, ләкин менә авыл халкы бермәл сыны катып торды: «Ничек, нигә, нәрсә булды соң әле бу?»
«Хәерлегә була күрсен инде», – дип мыгырданышты карчык-корчык. «Әллә нишләп китте шул әле соңгы вакытта еллар: йә су баса, йә тагын нәрсә», – диештеләр.
– Булмас, – диде Җәмилнең гомерлек шешәдәше Габдерәшит. Аңа бу хәбәрне кибет янына баш төзәтергә төшкән җирендә җиткерделәр. – Ул миннән ун яшьләргә кече, ну, мин белгәндә эчә иде инде. Үзенә булса дүрт-биш яшь булгандыр, печән өстенә дип куйган әче балны урлап чөмерә иде бит. Булмас, ышанмыйм.
– Чыннан инде, – дип гөрелдәде Тәпән Сабиры Габдерәшиткә. – Гариф та, ышанмыйча, бер ярты тотып кереп караган. Якын да китерми, ди, малай. Хатыны да сөйләнгәләп йөргән, инде өч көн авызына да капканы юк, дип. Әле менә малайлар күреп килгән: билдән шәрә, тирләп-пешеп тыкрыкларында утын яра, ди. Менә аптырап торам әле: салам китермәгән килеш калды. Бер литрыңны әзерләп куй, дигән иде. Хәзер бармас инде ул.

– Бөкреңне чыгарып, үзең ташыйсың инде хәзер, – дип шаркылдады Габдерәшит һәм кибеткә атлады.

Саламы килмәгәннәр авылда бер Сабир гына түгел иде. Каяндыр арт яктан кибет янына килеп чыккан Хәлфә Хәниф тә саламсыз калган булып чыкты.

– Кара әле, Колга тәре, – дип мыгырданды ул, Сабир белән сөйләшеп алгач. – Минем бит әле әзрәк агач та егасы бар иде. Нәрсә булган соң аңарга, ә?

– Белмим шул, – диде Сабир, йөзенә аптыраган кыяфәт чыгарып. – Бозым-фәлән эләккән дисәң инде...

– Бернинди бозым да, чурт та түгел, бик каты чирләгән ул, – дип, сүзгә кушылды ирләр янына килеп баскан Бүдәнә Фатыймасы. – Йөрәге, бавыры, пучкысы берьюлы атказать итә башлаган, шуңардан куркып туктаган. Заразы, утыным ярмаган килеш калды инде. Өч ярты самагунга ярып бирермен, дигән иде...

– Әллә врачка алып бардылармы икән? – Хәниф сакал булырга тиешле урынын учлады. – Хәзер бит әнә шулай итәләр: укул кадыйлар да, кеше үкереп еласа да эчә алмый.

– Алып барырсың Җәмилне врачка, – диде Сабир, читкә карап. – Башы ук өзелеп чыкмаса бармый да бармый инде ул бальнис тирәсенә.

Шулчак кибет янәшәсендәге тыкрыктан нindидер чәрелдәгән тавыш ишетелә башлады.

– Әһә, Җәмилә килә, – диде Хәниф, шул якка карап. – Тавышы бар инде, хәзер үзе дә күренер.

Чыннан да, шул мизгелдә тыкрык почмагыннан, чәчәкле күлмәген җилфердәтеп, Түбән оч Җәмилә үзе дә күренде.

– Чукынып кына китсен инде дөньясы, – дип чәрелдәде ул, авылның аргы очына ишетелерлек итеп. – Теге җирбит эчүен ташлаган, ди, дөресме шул, ә?

Аңа бу хәбәрнең чыннан да дөрес булуын әйттеләр. Җәмилә тагын чәрелдәргә тотынды:

– Өченче көн инде күрше Зөбәернең эте улый. Әйтәм бит, юньлегә түгел бу дип. Чукынып кына китсен дөньясы. Аракыңны әзерлә, коймаңны тотарга

киләм дигән иде бит. Әллә килә инде ул хәзер? И-и, бер бәхетсез гел бәхетсез инде ул. Ходаем, кемнән тоттырыйм инде мин ул койманы? Җитмәсә, кыз да, кияүгә китәм, ди. Ауган койма белән ничек туй үткәрим мин. – Җәмилә елап ук җибәрде.

– Кара әле, Җәмилә, – диде Сабир йомшак кына. – Бетеренмә әле шулкадәр. Үзем тотармын коймаңны.

Җәмилә Сабирга үтергеч бер караш ташлады да:

– И-и, син тоткан койма бит ул үзең төсле була, – дип чәрелдәде. – Юк инде, юк. Җәмил кебек булдыра торган авыл ирләре арасында юк ул.

Кибет янына халык җыела торды, һәркайсының үз кайгысы иде. Кемнең утыны киселмәгән, кемнең мунча түбәсе ябылмаган, кемнең сарыгы суелмаган, кемнең капкасы ауган. Иң мөһиме: бу эшләрнең барысын да Җәмил эшләргә сөйләшкән булып чыкты. Бердән алып ун яртыга кадәр бәяләнгән бу эшләр эшләнмичә калуына халык кайгырышты. Хатыннар булдыксыз ирләрен сүкте, ирләр гаепсез булуларын исбатлады. Исерек чагында Җәмилне «алкаш» дип сүгүчеләргә дә яхшы гына эләкте стихияле рәвештә җыелган халык җыенынннан. Җәмилнең канына гел тоз салып килгән участковый Харисны кыйный ук яздылар. Ул шыпырт кына колхоз идарәсенә таба шылды.

Авыл мулласы Чатан Мөнир, халык җыелудан файдаланып, ниндидер вәгазь сөйләп алмакчы иде дә, тыңлаучы булмагач, ул да гомуми тавышка кушылырга мәҗбүр булды.

Ахырда Җәмил янына барырга булдылар, ләкин көпә-көндез бер көтү халыкның авыл урамы буйлап йөрүе килешеп бетмәгәнгә, илче сайларга килештеләр. Илче итеп, шул арада икенче тапкыр башын төзәтергә төшкән Габдерәшит сайланды. Аңарга бурычны аңлаттылар. Габдерәшит, бер ярты бирсәләр, барырга риза булды. Тиз арада шешә дә табылды.

...Габдерәшит килгәндә, Җәмил, чыннан да, тыкрыкларында утын яра иде. Габдерәшитнең үзләренә таба килгәнен күргәч, ул балтасын түмәргә кадады да аунап яткан күлмәгенең кесәсеннән тәмәке алып кабызды.

– Ни йомыш, Әптери туган? – дип елмайды ул, тәмәкесен авызыннан алмыйча гына, гомерлек шешәдәше аның янына килеп чүгәләгәч. – Гомер булмаганны, башламаган шешәң дә бар диимме?..

Туры сүзле Габдерәшит, түкми-чәчми, кибет янындагы хәлләрне сөйләп бирде.

– Кара әле, тиле тәре, – диде ул, сөйләп бетергәч. – Әллә чыннан да ташладыңмы син, ә? Саташмагансыңдыр бит? Әллә чирләде диюләре дөресме?

Җәмил, шушы яшькә кадәр ниндидер могҗиза белән сакланган тешләрен күрсәтеп, бер шаркылдап алды, аннары җитдиләнеп сорап куйды:

– Авыл халкы сорый дисең инде алайса?

– Сорый, – диде Габдерәшит, кулындагы шешәсенә моңсу караш ташлап. – Халык аптыраган анда, Җәмил брат. Нәрсә эшләргә дә белми.

Җәмил бермәл тын гына уйланып утырды. Кулындагы тәмәкесе сүнгәнен дә сизмәде ул, аннары, шап иттереп, Габдерәшитнең тезенә сукты:

– Тор, Әптерәй дус, – диде ул, күзен кыса төшеп. – Халык сүзен тыңламыйча булмас инде. Бу шешәңне монда калдыр да бар кибет янына. Әйт, хәзер үк ике кешегә бер ярты хисабыннан аракы җыеп бирсәгез, Җәмил тагын эчә башлый, диген. Ә юк икән, юк.

– Булмыймы соң, – дип мыгырданды урыныннан сикереп үк торган Габдерәшит, кесәсеннән чүпрәк букча чыгара-чыгара. – Булмыймы соң...

Ул, йөгерә-йөгерә, кибет ягына атлады...

**Кое**

Кечкенә генә Озын Улак авылында бердәнбер кое иде бу. Элегрәк халык суны авыл читендәге чишмәдән ташып көн итте, ләкин тирә-юньдә нефтьчеләр казына башлагач, чишмәнең суы авызга алмаслык булып тәмсезләнде. Озын Улак кешеләре суны авыл уртасындагы бабайлар заманыннан калган коедан ала башладылар.

Авыл халкы су ала торган коеның үзенә генә хас бер үзенчәлеге бар: аннан беркайчан да кайтаваз ишетелми. Моны берәүләр коеның тирәнлеге белән, икенчеләр исә бурасының искелеге белән аңлата.

Шуларны уйлый-уйлый, Гали кое янына килеп җитте. Ике чиләгенә дә су алгач, ул ашыкмый гына тәмәкесен кабызды да төпсез булып тоелган кое эченә күз салды.

– Әй, – дип кычкырды ул, кое төбенә бераз карап торгач, – эһе-һей...

– Нәрсә акырасың, дивана? – диде кинәт кемдер кое төбеннән гөбедән чыккан кебек тавыш белән.

Кинәт ишетелгән тавыштан Гали дерт итеп китте. Аның кулындагы тәмәке төпчеге, бармак арасыннан ычкынып, кое төбенә очты. Гали башын күтәреп як-ягына каранды, әмма кое тирәсендә беркем дә юк иде. «Әллә саташам инде», – дип уйлады, маңгаена кисәк бәреп чыккан тирне сөртеп. Ул тагын кое эченә карады.

– Кем бар анда?

– Кем, кем, имеш. – Коедагы тавыш бу юлы катырак та чыкты. – Кайтаваз мин, кем булыйм. Кое тавышы ягъни мәсәлән. Бер дә ишеткәнең юкмы әллә? Эчеп килүең генә җитмәгән, тәмәке дә ыргытасың монда. Су биргәнгә рәхмәт юк.

Гали тагын маңгаен сөртеп алды. «Саташам, ахры, – дип уйлады ул. – Салуны киметергә кирәк».

– Әй, кем дәшә анда? – дип сорады ул, тагын коега иелеп.

– И-и, аңгыра, әйттем бит инде кайтаваз дип, – коедагы тавыш тагын гөрелдәде. – Һаман ышанмыйсыңмы әллә, алкаш?!

Гали тагын, аптырап, як-ягына каранды. Коеда кеше-фәлән була алмавын аңлый иде ул. Нәрсә булыр соң бу? Гали калтыранган куллары белән тәмәкесен кабызып азапланганда, көянтә-чиләген күтәреп, кое янына авылның иң усал хатыннарыннан берсе саналган Хөбби Зөлфиясе килеп басты. Килә-килешкә үк ул үзенең әче тавышы белән:

– Нишләп торасың монда баядан бирле, күрше? – дип, Галигә текәлде.

– Торам әле, – диде тегесе авыз эченнән генә, – менә тәмәке тартып торам.

Зөлфия, ашыкмый гына чиләкләрен тутырып, су алды. Шулчак Галинең башына бер уй килде:

– Зөлфия, бу коедан, чыннан да, кайтаваз ишетелмиме әллә? – диде ул әкрен генә.

– Вәт тиле, – китәргә җыенган Зөлфия чиләкләрен кире куйды. – Бала-чага да белә бит бу коеның саңгырау икәнен. Әнә ышанмасаң кычкырып кара.

– Тавыш юк шул бүген минем, – дип пышылдады Гали, – тамак авыртып тора нигәдер. Син кычкыр әле.

– Салкын аракы чөмергәнсеңдер, – Зөлфия нидер уйлап кое янына килде. – Менә кычкырам, тыңлап кара.

Зөлфия кое авызына иелде дә ачы тавыш белән «әй» дип кычкырып куйды. Тын да алмыйча, ни булыр икән дип тыңлап торган Гали коедан баягы гөрелдәгән тавыш ишетелгәч тынычланып калды. Әле саташмаганмын икән. Аның каравы кычкыруына каршы коедан «Тагын нинди диванасы акыра инде» дигән тавыш ишетелгәч, Зөлфия баскан урынында сикереп куйды:

– Нәрсә, миннән көләргә уйладыңмы әллә, пеләш тәре?! Кайсы тилесе төште су ала торган коега?

Зөлфиянең чәрелдәвенә карамыйча, Гали аңа хәлне аңлатып бирде. Тегесе, бераз уйланып торгач, тагын коега иелде дә:

– Кайсы мөртәте бар анда? – дип кычкырды.

Зөлфиянең тавышы тынып беткәнче, кое төбе:

– Гайбәтче аламасы, нәрсә чәрелдисең әле син? – дип гөрелдәде. – Әнә ireңә кайтып акыр. Тотып кыйнасаң да, бер сүз дә әйтми торган мүкләк ул синең.

Зөлфия бер агарынды, бер кызарынды. Ул әле аптырап торган Галигә, әле коега карап алды да, башына кинәт кенә ниндидер фикер килгән кешедәй, коедан читкәрәк атлады. Аяк астында аунаган саллы гына кирпеч ватыгын алып коега томыргач, ул, бермәл тын калып, ни буласын тыңлап карады. Астан ул-бу ишетелмәде.

Алар шулай матавыкланган арада, кое янына капыл гына Галинең хатыны Әсма килеп чыкты.

– Нихәл, күрше, – диде ул балдай тавыш белән, Зөлфиягә карап. – Суга килдеңме әллә?

– Соң, кое янына тагын нәрсәгә дип киләләр? – Зөлфия Әсмага усал караш ташлап алды. – Синең мәңге айнымас Галиең янына килмәм бит инде.

Әсма да җавапсыз калмаска җыенган иде, тик аны янәшәдә тәмәке пыскытып торучы Гали туктатты.

– Карчык, – диде ул йомшак кына. – Коега берәр нәрсә дәшеп кара әле.

Әсма, күзләрен акайтып, Галигә текәлде:

– Әллә белая горячка башланамы синдә, алкаш?

– Дәш, дәш, күрше, – дип, иренең сүзен Зөлфия дә җөпләгәч, Әсма аптырап калды:

– Ни сөйләвегез бу сезнең?

– Курыкма, курыкма. Бер әкәмәт бар әле монда. Гали көрәктәй кулы белән хатынын коега таба этәрде. «Болар мине коега батырып үтерергә телиләр инде әллә?» дигән уй Әсманың башыннан яшен тизлеге белән үтеп китсә дә, ул чиләкләрен тотып коега якынлашып килүче авыл мулласы Мөнир абзыйны күргәч тынычланды.

– Соң, кычкырсам ни була? – диде ул, тегеләргә карап.

– Башта кычкырып кара әле, аннан күрерсең.

Әсма кое янәшәсенә килеп түбән иелде дә әкрен генә «әй» дип дәште. Кое озак көттермәде. Баягы гөрелдәвек тавыш:

– Бу кәнтәйгә ни кирәк инде тагын? – дип, Әсманың котын алды.

Ул, бермәл тын да ала алмыйча торараштай катып, күзләрен челт-мелт йомып, ире белән Зөлфиягә карап торды. Тегеләр берсенә берсе мәгънәле генә карашып алдылар. Бераздан һушына килгәч, Әсма:

– Нәрсә бу? – дип пышылдады.

Зөлфия дә, Гали дә җилкәләрен генә сикерттеләр. Әсма тагын коега иелде дә бар көченә:

– Күрсәтәм мин хәзер сиңа кәнтәйне, чык әле монда! – дип кычкырды.

Коедан башта көлүгә охшаган бытырдау ишетелде, аннары баягы тавыш:

– Кәнтәй генә түгел син, себерке, – дип гөрелдәде. – Тагын әзрәк акырынсаң, теге елны Багана Җәмиле белән ниләр эшләгәнеңне ирең сөйлим, җен хатыны.

Шартлар дәрәҗәгә җиткән Әсма Галине коедан читкәрәк сөйрәп маташканда, кое янына, кәҗә сакалын сәлперәйтеп, авыл мәчете имамы вазифаларын башкаручы Чатан Мөнир килеп җитте.

– Әссәламегаләйкем! – диде ул, чиләкләрен җиргә куйгач. – Ни хәлләр бар, авылдашлар? Исән-иминме?

Аңа, берсен берсе бүлдерә-бүлдерә, хәлне аңлаттылар.

– Аллаһы Тәгаләнең кодрәте киң! – диде Мөнир, сакалын учлап бераз уйланып торгач. Аннан ул, авыз эченнән бисмилласын пышылдап, коега якынрак килде дә азан әйтеп чыныккан тавыш белән аска кычкырды:

– Кем бар анда, кое төбендә?

«Төбендә» сүзе әле әйтелеп беткәнче үк, түбәннән тагын бытырдау ишетелә башлады:

– Карт төлке, нәрсә акырасың шулкадәр? Партбилетыңны базга күмеп мулла булдым дигәч тә, артык азынма. Тагын коега якын килсәң, бөтен авылга синең элек тә, хәзер дә кылган бар гамәлләреңне сөйләп бирәм, тәмуг кисәве, чатан!

Мөнир лып итеп артына утырды да авылның иң оятсыз ирләре дә сирәк куллана торган бер сүз әйтте. Аннан, корт чаккан кебек сикереп торып, чиләкләрен дә алмыйча, өенә йөгерде...

Кое янына халык берәм-берәм килә торды. Күпләрнең күңел түренә яшереп куйган тирән серләрен кое авылдашларга фаш итә торды. Серләрнең төрлесе бар иде. Укытучы Мәхмүтнең тәнәфес вакытында әз-мәз көмешкә йоткалаганын авыл халкы тыныч кына тыңласа, мәктәп директоры Алмаз Хәмзовичның башлангыч сыйныфларда укытучы яшь кыз белән кети-мети уйнавы авыл халкын бөтенләй аптыраштта калдырды. Чөнки директор, карап

торырга ни буе, ни чурты дигәндәй, йолкыш кына бер бәндә иде. Каравылчы Әптерәйнең фермадан фураж урлавы да, Бүдәнә Фатыймасының ялган аракы сатуы да авыл өчен артык яңалык булмады, аның каравы силсәвит Рашатның шифоньерга яшерелгән ике машина алырга җитәрлек акчасы булу халыкны шаккатырды, чөнки Рашат гел акча җитмәүлектән зарлана иде.

Коемы, кайтавазмы, беркемне дә аямады. Бу көнне күп гаиләләр таркалу юлына басты. Күрше белән күрше арасында кара мәче йөгерде. Бөтенесе диярлек коедан ишетелгәннәрне ялганга чыгарырга ашыкты, ләкин бар да эченнән генә кое сөйләгәннәрнең саф дөреслек икәнен аңлый иде. Халык, кара болыт кебек, кое тирәсендә кайнады. Монда сабый балалар һәм урында ятучы карт-карчыклар гына юк иде. Мал-туар, кош-корт онытылды...

Озын Улакта бер урында өчтән артык кеше җыелса, хәерле нәрсә чыкмаячагын белгән участковый Харис белән хуҗалык рәисе Салих Вафич, бу хәлне каяндыр ишетеп, көн төшкә авышкач килеп җиттеләр. Икесенең дә яхшы гына кызмача булуы күренеп тора иде.

Ләкин кое берсенең бил каешындагы пистолеты белән погоннарына, икенчесенең мичкә хәтле корсагына да карап тормады. Җыелган халык Харисның җинаятьче һәм аңгыра сарык, ә Салих Вафичның бур һәм бирән икәнен белде. Белде дип, боларын Озын Улак халкы үзе дә чамалый иде инде, тик участковыйның авылдагы күп кенә хатын белән аралары бик якын булуы һәм Салих Вафичның шәһәрдә инде өченче йорт салып ятуы еллар буе хезмәт хакы күрмәгән халыкны чыгырыннан чыгара язды. Рәиснең вәгъдәләре, участковыйның пистолеты һәм алар арасында бөтерелгән мулла Мөнирнең вәгазе генә халыкны бераз тынычландырды.

Уйламаганда башланып киткән халык җыены озак дәвам итте. Ахырда Озын Улак халкы «җен иямәшкән» коены күмәргә дигән карар чыгарды. Карар бертавыштан диярлек кабул ителде. Бер гөнаһы да ачылмаган Алты-биш Касыймнан башка, коены күмүгә каршы чыгучы булмады. Шул ук көнне ферма янында силос базын таптап торучы куәтле бульдозер, коены күмеп, урынын җир белән тигезләп куйды.

Иртәгәдән халык суга чишмәгә йөри башлады. Суы тәмсез булса да, чишмә сөйләшә белми иде...

Кое бәласеннән котылган халык тиз генә тынычланмады. Моны сизенгән участковый Харис тиз генә күрше чуваш авылындагы сөяркәсенә ычкынды, ә силсәвит Рашат чираттагы запойга китте. Патша заманасыннан ук баш бирмәс саналган озынулаклыларның ни дә булса майтарып ыргытуыннан шикләнгән район җитәкчеләре Рашатны тиз арада эшеннән алдылар. Авыл бер генә көн, гомумән, җитәкчесез яшәде.

Силсәвит Рашатны ике атна буе айнымыйча эчеп ятканы өчен эшеннән куганның икенче көнендә авыл халкы җыенга җыелды. Беркем дә махсус дәшмичә, үзлегеннән җыелган иде халык авыл Советы бинасы каршына. Участковый Харис дөм исерек хәлдә күрше чуваш авылында ятканга, җыелган халыкны куып таратырга да кеше табылмады.

Рашатның «җылы» урыннан очып төшүе авылдашларының авыр замана белән басылган күңелләрен бераз күтәреп җибәрде. Аны авылда беркем дә яратмый иде. Өр-яңа машина алган, малаена өй салып яткан кешене кем яратсын ди инде?!

Халыкның җыенга җыелу сәбәбе дә шул, авылга яңа җитәкче сайлап кую иде. Бу юлы район-фәлән сүзенә карап тормыйча, авыл халкы рәис итеп үз кешесен куярга карар кылды.

Уттай эш өсте булмаганга, җыенга байтак кеше килде. Халык тыныч кына Чатан Мөнирне көтте, чөнки җыенны астыртын гына авыл мулласы вазифаларын башкарган шул Мөнир оештырды. Менә аскы урамнан җил-җил атлап килүче, башына кәләпүш кигән, кәҗә сакаллы бер бәндә күренде. Бу Мөнир үзе иде. Җыелган халык янына килеп җиткәч, ул көр тавыш белән: «Әссәламегаләйкем», – дип, халыкны сәламләде дә кем тарафыннандыр алдан ук әзерләп куелган буш аракы әрҗәсе өстенә менеп басты. Карчыганыкыдай күзләре белән халыкка бер карап алгач, мәчеттә вәгазь сөйләгәндәй, сүз башлады.

– Иптәшләр! – диде Мөнир ташларны эретердәй тавыш белән. – Безнең хәзер демократия чорында яшәвебезне барыгыз да беләсез булса кирәк.

– Беләбез, беләбез, – диеште халык.

– Шуңа күрә эшеннән алынган теге алкаш урынына, – Мөнир Рашатлар тора торган Югары оч ягына таба кулын селтәп алды, – авыл халкының аһ-зарын, кайгыларын аңлый торган үзебезнең кешене куярга кирәк. Барыбыз да бер сүздә булсак, шәт, район да берни әйтмәс. Мин силсәвит персидәтеле итеп Гыймадиев Дамирны сайларга тәкъдим итәм. Акыллы, инсафлы бала, үзебезнең авылда туып үсте, институт бетергән. Шуңардан да кулайрак кеше таба алмабыз, җәмәгать.

Фермада мал врачы булып эшләүче Дамир Мөнирнең кияве иде. Кулыннан юньләп бер эш тә килмәгән бу егетнең каяндыр килгән акчага яңа йорт торгызып ятуы, аның авылда башын бик югары күтәреп йөрүе дә озынулаклыларның күңеленә бер дә хуш килми иде, әлбәттә, шуңа күрә, Дамир исеме ишетелү белән, халык арасында берән-сәрән көлгән тавышлар ишетелде.

– Сыерның бозылган җиренә дару да сөртә белми бит ул, – диде кемдер.

– Мал хәленә керә белмәгән кеше авыл җитәкчесе була алмый инде, – диде Колга Җәмил.

– Ул аракы да эчми, ә эчмәгән кеше йә кара эчле, йә чирле була, ни чуртыма безгә андый рәис?

– Әнә Күке Раилен куярга кирәк.

Халык дәррәү көлеп җибәрде.

– Юк, җәмәгать, – диде Мөнир, сүзнең читкә китәргә чамалаганын сизенеп. – Авыл белән җитәкчелек итү, бушка мотоцикл алам дип, урманда күке куып йөрү түгел.

Халык тагын бер көлешеп алды, ләкин шулай да Раилне авыл Советы рәисе итәргә теләүчеләр дә юк түгел иде.

Авыл Советы рәислегенә Мөнир мулланың үзен, тарих укытучысы Исмәгыйльне, тагын әллә кемнәрне тәкъдим итүчеләр булды. Кинәт,

бөтенесенең тавышын басып, халык арасыннан тагын Колга Җәмилнең тавышы яңгырады:
– Көтүче Сабирҗан абзыйны сайлыйкмы әллә?
...Һәр авылның үзенә бер ата ялкавы, үз алкашы һәм үз диванасы була. Бу – табигать законы, күрәсең, чөнки соңгы елларда да әле мулласыз, участковыйсыз авыллар очраса да, югарыда аталып киткән кешеләрдән башка авыл чын авыл була алмый.
Озын Улакта ата ялкау, алкаш һәм авыл диванасы исемнәрен, барысын бергә элеккеге сарык көтүчесе Сабирҗан күтәрә иде. Ләкин эчәргә яраткан, тилемсәрәк Сабирҗанның үз гомерендә берәүгә дә зыян китергәне булмады. Кешеләрне, аннан да битәр сарыкларны ярата иде Сабирҗан. Ләкин колхозларда сарыклар бетүгә йөз тоткач, ул эшсез калды. Авызына беләк буе тәмәкесен кабып, капка төбендә утырудан башка эше булмаганга, «Бу халык кая җыела икән?» дип, бүген ул да җыенга килде...
Сабирҗан исеме чыккач, халык тагын бер кат гөрләшеп көлеп алды. Ләкин халык тавышын басып, тагын Җәмилнең көр тавышы яңгырады:
– Нәрсәсе килешми Сабирҗанның? Ялкау дисәгез, Рашат та үз гомерендә сыңар кадак та каккан кеше түгел иде – эшләде бит әле рәис булып; эчә дисәгез, әнә колхоз рәисе Сабирҗаннан да күбрәк эчә бит, әмма барыбер урында утыра. Баш ягына килсәк, – Җәмил як-ягына каранып алды, – безнең авыл белән йөз прансит нормальный кеше идарә итә дә алмый. Гомере буе берүзе сарык көтүен көткән кеше әллә авыл халкын гына тыя алмас дисезме? Аннары тагын бер ягы бар: Сабирҗан бит ул үз гомерендә сорамыйча кешенең энәсенә дә кагыла торган кеше түгел. Иманым камил: рәис булгач та урламаячак...
Халык тынып калды. Бар да Җәмил әйткәннәрне башларыннан үткәрәләр иде. Бераздан «булсын, Сабирҗан булсын», «тиле булса да, яхшы кеше ул» дигән тавышлар ишетелгәли башлады.
– Җәмәгать, саташмыйк инде. – Мөнир мулла тагын аракы әрҗәсе өстенә менеп басты. – Син дә, Җәмил, халык җыенын исерекләр мәҗлесенә

әйләндермә. Авылда Дамирдан да яхшырак кандидатура юк. Тиле кешене рәис итеп сайлый алмыйбыз бит инде.
«Ярар, сайлыйк Дамирны», – диде кемдер. «Күке Раиле лутчырак булыр», «Сабирҗанны сайлыйбыз» дигән тавышлар ишетелде. «Кире Рашатны гына сайлыйк» диючеләр дә булды. Халык арасында бәхәс купты. Берәүнең дә үз сүзен бирәсе килмәде.
Көтүче Сабирҗанга рәхәт иде. Ул акырышкан халык янында үзен нәкъ көтүдәге сарыклар арасында кебек хис итте. «Их, урап-урап берне чыбыркы шартлатасы иде монда. Рәис булмыйм, президент булам мин, – дип мыгырданды ул. – Нәрсә, тиле дигәч тә әллә?! Авыл хуҗалыгын беләм...» Исеме халык теленә эләккәч, Сабирҗанның борынына власть исе кергән иде.
Моңа кадәр янәшә торган Раил белән Дамир, аны-моны әйтми генә, икесе ике яккарак күчenделәр. Халык гөжләде дә гөжләде...
Озак кына тарткалашканнан соң, авыл Советы рәисе сайлауны җиренә җиткереп үткәрергә булды. Каяндыр картон тартма табылды, бөтен халыкка кәгазь кисәкләре таратылды. Барлыгы йөз дә утыз кеше сайлаучы итеп теркәлде, һәркем кешегә күрсәтмичә генә үзе рәис итеп күрергә тиешле кешенең исемен, кәгазьгә язып, шул тартмага ташларга тиеш булды. Җыелган халык арасында, тыз-быз килеп, Мөнир мулла йөренде. Халык уйга калды...
Бераздан аракы әрҗәсе өстендә торган тартмага бөгәрләнгән кәгазь кисәкләре төшә башлады. Соңгы кеше булып, Сәхипҗамал карчык та үз бөтиен тартмага салгач, санауга керештеләр.
Йөз егерме җиде тавыш белән, үзенә җитәкче итеп, халык көтүче Сабирҗанны сайлаган иде...

**Җыелыш**

Ходайның бер бирмеш көнендә дүшәмбедән алып якшәмбегә кадәр атна эченә тупланган көннәр кешеләр үрнәгендә җыелышка җыелырга булганнар. Башлап йөрүче кем булгандыр инде, анысы хәзер караңгы, тик башыннан ук

бу эшнең хәерле бетмәячәген чамалап була иде. Бәхәс җыелышны кем алып барырга тиеш дигән мәсьәләдә үк купты. Җидесенең дә баш буласы килү көннәрне тәмам ачуланыштырып бетерә язды. Җыелышка җыелуның сәбәбе атна көннәре арасында җитәкче сайлап кую булганлыктан, берәүнең дә баш бирәсе килмәде.

Иң беренче булып сүзне Дүшәмбе башлады:

– Мине кешеләр үзләре беренче итеп куйдылар. Миннән дә мөһимрәк көн юктыр арада, җәмәгать. Яллардан соң эшкә әйдәүче дә мин. Аннары кешеләр яңа тормышларын да миннән башларга тырышалар. Миндер инде сезнең җитәкчегез.

Дүшәмбенең шулай дип әйтеп бетерүе булды, Сишәмбе чәчрәп чыкты:

– Синнән нинди җитәкче чыксын инде, Дүшәмбе, – диде ул, күзләрен шардай түгәрәкләндереп. – Син бит гомергә махмырдан интегәсең, шуның өчен сине кешеләр дә яратмый. Бу дөньяда, җыен эшләмичә акча алып ятучылардан башка, кемнең атна башын яратканы бар. Менә миңа туры килгән көнне адәм балаларының чистый күзе ачыла. Миннән дә кулайрак җитәкче юк, минемчә.

– Син дәшми торсаң, яхшырак булмасмы, Сишәмбе брат, – дип, Чәршәмбе дә бәхәскә кушылды. – Беренчедән, синең исем дә бит Сишәмбе, бик матур яңгырамый. Аннары сине дә гомер-гомергә кешеләр яратмады. Син туры килгән көнне яңа эш тә башламыйлар, юлга да чыкмыйлар, тырнак кына да кисмиләр. Ә менә мин атнаның уртасы. Ходай үзе мине җитәкче булырга яраткан. Мин ике якны да бертигез күрергә сәләтле. Урыслар бит мине юкка гына Среда дип әйтмиләр. Миннән дә кулайрак кандидатура юк монда.

– Якшәмбе белән сезнең гел шул урыска табыну булыр инде, – дип, Пәнҗешәмбе дә салмак кына сүзгә кушылды. – Синең бит, Чәршәмбе туган, уртада булуың ни туды, ни сюды дигәнне генә аңлата. Синнән бер якка да юк ягъни мәсәлән. Ә менә мин үзебезнең төркилегебезне саклап кала алган бердәнбер көн. Минем үзебезчә Атнакич дигән исемем бар, ә сездә тик гарәп-фарсы исемнәре генә. Шуңа күрә җитәкчегез итеп мине сайларсыз дип уйлыйм.

Бу сүзләрдән соң башына чалма ураган Җомга калтыранган тавыш белән сүзгә кушылды:
– Мин сезнең бәхәсләшүегезне, гомумән, аңламыйм, җәмәгать. Мөселман өчен миннән дә изгерәк көн юк дөньяда. Миңа туры килгән көнне элек-электән кешеләр намазга йөргәннәр, изгелекләр кылганнар, ял иткәннәр, ниһаять. Үткәннәребезгә кире кайткан вакытта, миннән дә кулайрак җитәкче таба алуыгызга мин шикләнәм. – Җомга, сизелер-сизелмәс кенә итеп, Пәнҗешәмбегә ым какты. Икешәр көн ял иткән заманда аларның бергәрәк булуы, ягъни мәсәлән Җомга җитәкче итеп сайланган очракта, Пәнҗешәмбе аның замы буласы көн кебек ачык иде.
– Сез нәрсә, җәмәгать? Кешеләрдән күреп, дәүләт переворуты ясарга уйлыйсызмы әллә? – Шимбә башкаларның алдына ук йөгереп чыкты. – Син, Җомга абзый, гүпчем дәшмә. Бәлки, элекке, кадими заманнарда син туры килгән көнне намазга йөргәннәрдер дә, хәзер андый гадәт юк инде. Сине хәзер, беләсең килсә, «шофёрлар көне» дип йөртәләр. Беләсеңме нигә? Чөнки сиңа бирелгән көнне бөтен шофёр, алай гына түгел, бөтен эшче лаякыл булганчы эчә. Хәзер син – алкаш, Җомга абзый, ә менә мине кешеләр көтеп ала. Без Якшәмбе туган белән икәү кешеләрнең иң яраткан көннәре. Без туры килгән көннәрне кешеләр гаиләләре белән бергәләп ял итә, ата-аналары белән күрешә, күпме файдалы эшләр эшли. – Шимбә Якшәмбегә күз ташлап алды да сүзен дәвам итте: – Мин җитәкчелеккә дәгъва итмим, булганына шөкер итеп яшәргә кирәк.
– Сез, сез икегез дә бер калыптан, – дип кычкырды, моңа түзмичә, Дүшәмбе. – Берегез – яһүд бәйрәме, икенчегез урысныкы. Сез туры килгән көнне кешеләр гомер күрмәгән кебек эчәләр-эчәләр дә, аннары мин гаепле. Сезнең икегезнең берегезне дә җитәкчелеккә якын китерәсе түгел.
– Дүшәмбе иптәш, сез болай да ил күләмендә киеренке булган милләтара мөнәсәбәтләргә тыгылмагыз, яме! – Моңарчы барысын да тыңлап, блокнотына нидер язгалап утырган Якшәмбе бәхәскә катнашмый булдыра алмады. – Бүгенгә әле монда мин нәчәлник. Кешеләр дә мине хөрмәт итә. Ә

электән килгән тәртипне бозарга мин сезгә не позволю. Җитәр акырышырга. Әнә кешеләр күпме революцияләр ясап карадылар, берәр тулкы булдымы? Юк! Нәрсә җитми сезгә? Һәрберегезнең үз урыны бар. Кешеләр инде шушы пәрдеккә өйрәнгән. Хәзер, урыннар алыштырып, аларның болай да буталган башларын тагы бутыйкмы? Менә мин атнаны төгәлләп торам. Киредән мине сайлагыз да, җитәкчегез итеп, и вәссәлам.
Җыелыш озак барды. Кышкы вакытка күчкәндә, берсеннән берсе урларга мәҗбүр булган бер сәгать турында да, кешеләр икешәр-өчәр көн ял иткәндә кемнәргәдер өстенлек бирелүе дә игътибардан читтә калмады. Ахырда атна көннәре тәртипне элеккечә калдырырга дигән тәкъдим белән килешергә булдылар, чөнки революцияләр ясап, үзгәртеп корулар үткәреп авызлары пешкән кешеләрнең хәлләреннән алар бик хәбәрдар иделәр.

**Комган белән самавыр**

Алар элек бер йортта тату гына яшәделәр, тик, заманалар буталгач, озак вакыт берсен берсе югалтып тордылар. Бүген исә аларга тагын очрашу насыйп булды. Кайда диген әле! Элекке кебек мич алдында да түгел бит, ярым җимерек трактор арбасында. Бу арбага аларның икесен берьюлы ыргыттылар. Бераз вакыт һушын югалтып торгач, Комган беренче булып аңга килде. «Их, заманалар! – дип уфтанды ул, үзенең келәт почмагында ятып каралып беткән җиз түшләренә карап. – Үтте шул, үтте безнең кадерне белгән заман». Шулчак аның күзе үзе белән янәшә яткан, борыны кыйшайган, яшькелтләнеп беткән самавырга төште. «Тукта, бу минем кордаш-чордаш түгелме соң? – дип уйлады Комган. – Шул бит, шул үзе. Кара, ничек ямьсезләнеп беткән. Ә бит өстәл түрендә кукраеп утырганда нинди чибәр иде. Безнең ише кара халыкка өстән генә карый иде бит ул чакта». Комган, ничек кирәк шулай кузгалып, җиз самавырның бөеренә төртте. Тегесенең аңы бар иде, ахры, – ыңгырашып куйды.
Бераздан Комган белән Самавыр, трактор гөрелтесен дә күмеп, чынлап сөйләшеп баралар иде инде. Самавыр, башта Комганны танымыйчарак торса

да, бераздан исенә төшерде. Ни дисәң дә, озак еллар бер йортта тордылар бит.

– Их, Комган туган! – диде самавыр, ямьшәйгән борынын турыларга маташып. – Бар иде безнең дә адәм башларына кирәк чаклар. Утыра идем бит мин өстәл түрендә. Көн саен юып, чистартып торалар иде үземне. Карт хуҗабикә исән чагында иде инде ул кызык тормыш. Җыелыр иде тирә-күрше карчык минем тирәли, тотынырлар иде шакмак шикәр белән чәй эчә-эчә гайбәт сатарга. Авылның бөтен яңалыгын белеп тора идем мин ул чакта. Корсагыма бер чиләк су сыя торган булса да, ул гына җитми иде карчыкларга. Тагын тутырып куялар иде. Бигрәк тәмле бу самавырның чәе дип эчәләр иде мин кайнаткан чәйне. Их, заманалар!

Комган да дәшми кала алмады. Ул да, борыныннан яшь тамызып, үткән елларны искә алды.

– Мин дә пачутта идем ул чакта, Самавыр туган. Җылы су салып, мич артында гына тотарлар иде үземне. Хуҗа карчык урамга чыга калса, мине гел диярлек үзе белән алыр иде, мәрхүмә. Кадеремне беләләр иде элек минем дә. Хәзер генә безнең кирәгебез калмады, күрәсең.

Бу сүзләрдән Самавыр да сулкылдап алды:

– Мине әнә шул газ белән электр харап итте лә. Хәзер бит чәйне калай чәйнектә кайнаталар. Соң, аның чәе чәйме инде – тфү! Юынтык су шунда. Бер чәшке эчкәнче суынып бетә үзе. Әле соңгы елларда, мода дип, миңа охшаган бер нәрсә алып кайтканнар хуҗаларыбыз. Электр самавыры диләр үзен. Күрдем инде: үзенең ни буе, ни зурлыгы. Чәйне дә тере утта кайната белми үзе. Ни пычагыма кирәккәндер ул хуҗаларга?

Самавыр авыр сулап куйды. Комганның да сөйлисе сүзләре күп иде, ахрысы.

– Ә мине халыкның денсезләнүе бетерде. Элек мөселман халкы миннән башка йомыш йомышларга бер дә йөрми иде бит. Хәзер генә бар да кяфергә әйләнеп беттеләр. Минем күптән хуҗаларның өенә кергәнем юк инде. Теге елны, шук оныгы эчемә кызыл борыч салгач, хуҗабикә, кызышуына түзә алмыйча, мине келәт почмагына атып бәргән иде, шуннан бирле өй эчен

күргәнем юк. Әле соңгы вакытта ишеттем: дин яңадан кайта башлагач минем дә кирәк чыккан булган да, ну, минем вазифаларны теге кибет катыгы тутырып сата торган шешә алган. Соң, аның ни матурлыгы, ни уңайлыгы юк бит инде.

Шулай, үткәннәрне искә төшереп, берсенә берсе зарланышып барганда, алар утырган арбаны таккан трактор кинәт туктап калды. Бераздан арба ничектер янтайды һәм Комган белән Самавыр башка тимер-томыр белән бергә, шалтырап, җиргә килеп төштеләр.

Бераздан аңнарына килгәч, Комган белән Самавыр телгә килделәр.

– Нинди җир икән бу, Самавыр туган? – диде Комган, як-ягына каранып. – Кайда китереп ыргыттылар икән безне?

– Ишеткәнем булды минем бу турыда, – диде тегесе, кәкрәйгән борынын рәтли-рәтли. – Металлолом дип аталабыз без синең белән хәзер. Безне озакламый утка тыгып эретәчәкләр, аннары бездән чыккан җиздән бүтән нәрсә ясаячаклар.

– И Ходаем, күрәселәребез бар икән әле, – Комганның тавышы дерелдәп кенә чыкты. – Теге, карчык-корчык сөйләгән тәмуг шул буладыр инде. Ни гөнаһларыбыз өчен икән соң, ә?

– Шулай инде. Бу адәм бабаларын аңламассың. Сине, үзләренә кирәк чагында, күкләргә чөеп мактыйлар, кирәгең беткәч, утка да ыргыта алар.

Әңгәмәдәшләр шулай сөйләшкән арада, тимер-томыр калдыклары янына ике үсмер малай килеп чыкты.

– Кара әле, җиз ватыклары, – диде сары чәчле, сипкелле йөзлесе. – Төсле металл калдыклары итеп тапшырсаң, ике-өч шешә лимонадлык акча бирәчәкләр.

Малайларның икенчесе – күзлек кигәне – якынрак килде:

– Син нәрсә, – диде ул, иптәшенә карап. – Бу бит самавыр белән комган. Боларны тарих укытучысы Искәндәр абыйга тапшырсак, ул безнең икебезгә дә бу чиректә бишле чыгарачак. Әйдә, ал комганны, мин самавырны тотам. Илтик боларны мәктәп музеена.

Берничә көннән мәктәпнең музейга бирелгән җылы гына бер бүлмәсендә яңарып, яшәреп киткән Комган белән Самавыр ялтырап утыралар иде инде.
– Бәхет бар безнең, брат, ә, – диде Самавыр, Комганга өстән карап. – Яшибез болай булгач.
– Аллага шөкер, Самавыр туган! Тәки кирәгебез чыкты бит адәм балаларына.
Комган да җиз борыны астыннан гына елмайды. Бу мизгелләрдә, җыен иске-москы – чабагач, киле, чабата ише әйберләр арасында булсалар да, алардан да бәхетле затлар дөнья йөзендә юк иде.

**«Көчләүче»**

Таулар арасына урнашкан кечкенә генә шәһәрчектә соңгы ун көн эчендә бер-бер артлы ике хатынны көчләделәр. Яшь кызларны түгел, ә менә нәкъ кырыкның теге ягына чыгып баручы хатыннарны. Ике очракта да эш полициягә барып җитмәде җитүен. Кеше сүзеннән куркыпмы яисә бүтән билгесез сәбәп беләнме, хатыннар эшне үзләре зурга җибәрмәде. Берсенең ире полициягә барырга булган да, имеш, хатыны: «Анда йөрсәң, синнән аерылам мин», – дигәч, сыкранып булса да, эшкә хут бирмәскә риза булган, ди. Ләкин кечкенә шәһәр авылдан әллә ни аерылмаганга, бу ике очрак, тиз арада фаш булып, халык телендә вакыйгаларда катнашучыларның үзләре дә белмәгән нечкәлекләрен тасвирлап сөйләнә иде.
Тагын шунысы кызыклы: билгесез булып калган кеше үз корбаннарына нигәдер иртән генә һөҗүм итә икән. Аннары халык теленә бу ир-атның озын буйлы, таза гәүдәле икәне дә кергән...
Шәһәрчек читендәге шифаханәдә пешекче булып эшләүче Нәҗия, иртәнге караңгы юлдан атлаганда, нигәдер гел шуның турында уйлады. Бүген ашханәгә беренче булып килеп иртәнге ашка әзерлек башларга аның чираты булганга, бик иртә чыкты ул юлга. Бу вакытта әле автобуслар йөри башламаганлыктан, читләре куе куаклык белән капланган юлдан җәяү атларга туры килә иде. «Ә менә шушы куаклар арасыннан теге явыз әзмәвер килеп чыкса... – дип уйлады Нәҗия, шомланып. – Качып та котыла

алмыйсың, билләһи». Иртә белән ире Фәндәс: «Әллә озатыйммы үзеңне», – дигән иде дә бит, Нәҗия кул гына селтәде. «Әле үзеңнең, гаражга менеп, машинаңны кабызасың бар, кем тисен миңа?» Җылы өйдә куркыныч тоелмаган икән дә бит, менә монда, караңгы көзге юлда бүтәнчәрәк.

Нәҗия юлның уртасыннанрак атларга тырышты. «Хәзер Фәндәс гараждадыр инде, – дип уйлады ул, адымын кызулата төшеп. – Озаттырасы калган икән. Өлгергән булыр идем әле эшемә. Ә теге кеше килеп чыкса менә хәзер?.. Тотып көчләсә, киемнәрне ерткалап бетерсә?.. Хурлыгын кая куярсың, Ходаем. Уф-ф, ничек тизрәк барып җитәргә соң? Әле атлыйсы да байтак бит...» Нәҗия нигәдер артына борылып карады. Шәһәрдән шактый гына читкә кителгән иде инде. Шулчак хатынның күзенә еракта бу якка таба кыймылдаучы шәүлә күренеп китте. Нәҗиянең йөрәге кинәт күкрәк читлегеннән атылып чыгардай булып тибә башлады. «Берәү бу якка таба килә түгелме соң?» Ул атлавын тагын да тизләтте. Азрак атлагач, ирексездән тагын артка борылып, юлга күз төшерде. Баягы шәүлә шактый гына якынлашкан иде инде. Нәҗиянең баш миен «минем арттан килә бит бу» дигән уй телгәләп үтте. Аркасына салкын тир бәреп чыкты. Кинәт кузгалган җил аша арттан ниндидер тавыш та ишетелгәч, Нәҗиянең бөтенләй хәле бетте. «Миңа кычкыра, туктарга куша инде», – дип уйлады хатын. – Шул көчләүче ир бу, бүтән беркем дә түгел. И Ходаем, мәсхәрә итсә, Фәндәскә ни дип әйтермен?» Ашыга-ашыга атлаган хатын, үзе дә сизмәстән, яулык астыннан чыккан чәчләрен төзәткәләде. Арттан инде кызу-кызу атлап килгән кешенең аяк тавышларына хәтле ишетелә башлаган кебек иде. «Чукынды, көчли хәзер». Хатынның башына кинәт кайдандыр «Үзең әйтмәсәң, ирең каян белсен аны?» дигән уй керде. Юк-юк, кырыгын тутырган, әле пешкән алма кебек түгәрәк хатынның уйлары түгел иде бу, ниндидер ят уйлар иде.

Аяк тавышлары, ярсып мышнаган тавыш үз янында ук ишетелгәч, Нәҗия кинәт кенә юл читенә тайпылды да, лып итеп, бер куак төбенә утырды. «Көчләсәң көчлә, кыйнама да кешегә генә сөйләмә», – диде ул йөгереп диярлек аның янына килгән иргә. «Нәрсә сөйләнәсең, миңгерәү? Гараж

ачкычы синең кесәдә киткән бит», – дип сукранып дәшкән тавыш аны айнытып җибәргәндәй булды. Наҗия башын күтәреп караса, каршында ачуы йөзенә чыккан ире Фәндәс басып тора иде...

**Үкенеч**

Үз авыллары ягына кайта торган автобуска кереп утыргач, Гөлчәчәк шатланып куйды: автобус, гадәттәгечә, тулы түгел иде. «Атна арасы шул, – дип уйлады кыз, арткы урыннарның берсенә уңайлап урнаша-урнаша. – Авылдан базарга килүчеләр дә аз, авылда, маллар сую вакыты булмаганга, шәһәрдән иткә кайтучылар да күренми».

Әле быел гына институт тәмамлап, диплом алып чыккан Гөлчәчәк үзе авылдан «бурычка» акча алып килергә дип кайта иде. Эш урыны да тапты ул табуын, тик бит әле, беренче хезмәт хакы алганчы, күпме көтәсе бар. Аннары укытучы акчасына артык симереп тә булмас. «Берәрсенә кияүгә чыкмый булмас, күрәсең, – дип уйлады кыз, кечкенә көзгегә карап иреннәрен төзәткәли-төзәткәли. – Барлы-юклы ул акчага гына яшәргә калсаң, ачка үләрсең, билләһи».

Гөлчәчәк, тәрәзәгә карап, кияүгә чыгу перспективасын төрле яклап тикшерә башлады: «Фатирлы, машиналы кияү тапсаң, начар булмас иде. Хәер, машинасын гына алдырырбыз, фатиры булса, шул җитәр». Бай кияү якын арада гына күренмәгәнгә, Гөлчәчәк автобуста утырган халыкны күзәтә башлады, ләкин автобуста аның игътибарын җәлеп итәрдәй кеше табылмады. Кыз, иренеп кенә, тәрәзәдән юл кырыен күзәтеп бара башлады. Инде шәһәрне чыгып барганда, уңай гына тәгәрәгән автобус кинәт сөрлеккәндәй туктап калды. Ачылган ишектән эш киеменә киенгән, олы гына сумка аскан утыз-утыз биш яшьләрдәге бер ир-ат керде. Керде дә, сөрлегә язып, алдагы бер утыргычка утырды. Аның салмыш икәне үз гомерендә бер исерекне дә күрмәгән кешегә дә аңлашылырлык иде. Ир томанланган күзләре белән автобусны сөзеп чыкты да, сумкасын ачып, аннан бер шешә кызыл аракы

чыгарды. Шешәнең бөкесен теше белән генә каерып ыргыткач, саллы гына итеп бер йотып куйды. Шешә яртылаш диярлек бушап калды.

– Кем эчә? – дип сорады ир, тагын бер кат күзе белән автобус эчен айкап чыгып.

Ләкин, бушка булса да, шәраб эчәргә теләүче табылмады.

– Нәрсә, берегез дә эчмиме әллә? – диде шәраб хуҗасы.

Бу юлы да сорау җавапсыз калды. Шулчак ирнең күзе арткы утыргычта утырган Гөлчәчәккә төште. Ул, бер кулына шәрабын, икенчесенә сумкасын тотып, сөрлегә-сөрлегә, кыз янына килде һәм янәшәдәге буш урынга утырды. «Бигрәк ямьсез кешеләр бар инде», – дип уйлады Гөлчәчәк.

– Ну чибәр дә инде сезнең якта кызлар, ә?! – диде ир, кызны баштанаяк күздән кичергәч. – Менә безнең авылда андыйлар юк бит. Кайсысына карама, кәкре аяклы, сары чәчле.

Ирдән шәраб, тәмәке һәм бензин исе бергә катышканнан хасил була торган үтергеч ис килә иде. Гөлчәчәк башын читкә борды да читкәрәк шуышты. Ләкин кәкре аяклы кызлар авылы егете дә аның артыннан ук шуышып куйды.

– Чибәркәем, борма инде йөзләреңне читкә, – диде ир шигъри юллар белән диярлек.

– Бәйләнмәгез әле миңа, зинһар, – Гөлчәчәк тагы әзрәк шуышты. Бәйләнүче дә аннан калмады. Бүтән шуышырга урын юк иде инде.

– Бәйләнмим бит мин, менә сыйларга гына килдем сине, – ир шешәне Гөлчәчәкнең борыны төбенә үк китерде. – Мә, әзрәк йотып җиффәр. Канга файдалы бу нәстә.

Кыз бәйләнчек дигәндәй уфтанып куйды:

– Эчмим мин.

– Нүжәли эчми торган кызлар да бар хәзер, ә? – шешә хуҗасы, гаҗәпләнгәндәй, кара кашларын югары күтәрде. – Тартмыйсың дамы?

– Тартмыйм да.

– Да-а, – дип сузды ир, шешәсеннән тагын бер саллы гына йотым ясап.

– Ә, теге... ни... егетләр мәсьәләсендә ничегрәк?

– И-и, хәзер егетләр бармыни? – Гөлчәчәк, үзе дә сизмәстән, бәйләнчеккә таба борылды. – Кайсын карама, йә алкаш, йә наркоман, йә хәерче.
Ир шаркылдап көлеп җибәрде.
– Тучны әйттегез, – диде, көлеп туйгач. – Йә хәерче. Ә менә мин хәерче түгел. – Ул кисәк кенә кесәсенә тыгылды да аннан бер уч акча чыгарды. – Менә кара, күпме акча монда. Сумка тулы аракы. Мин хәерче дә, наркоман да түгел. Ну, салгалыйм инде салгалавын...
Гөлчәчәк ирнең кулындагы акчаларга күз төшереп алды. «Кара инде, исеректә никадәр акча, – дип уйлады ул. – Нефтьче-мазардыр инде».
– Әйдә киттек минем белән, – диде кинәт җитдиләнгән ир. – Бер төн и бу ун мең синеке.
Кыз кинәт кызарып чыкты. Ул кызулык белән ирнең яңагына да бер чәпәргә уйлаган иде дә, аның киң җилкәләренә, калын беләкләренә күз төшергәч, бу уеннан кире кайтты.
– Дивана, – диде ул, башын тагын тәрәзәгә таба борып. – Вәт дивана.
– Соң, нәрсәсе бар аның? Әнә шәһәр кызларын бу акчага ярты автобус җыеп була. Ә монда берүзеңә. Аннары мин бит малай-шалай түгел. Алар бушка гына җиләк ашарга яраталар. Әйдә дим, үкенмәссең. Хәзер безнең авыл була. Төшәбез дә калабыз...
– Кит әле моннан, – Гөлчәчәк үзе өстенә иелгән ирне читкәрәк этте дә алгарак барып утырды.
Тегесе исә бушаган шешәсен утыргыч астына тәгәрәтте, сумкасын җилкәсенә элеп торып басты. Автобус авылга кереп бара иде инде. Ир, Гөлчәчәк янына килеп, кызга таба иелде:
– Әйдә, – диде ул ап-айнык тавыш белән. – Алдамыйм мин сине. Мунча яккан. Мине чабындырып-чабындырып мунча кертсәң, мин бөтенләй үк ярамаслык түгел үзем. Иртән озатып җибәрермен. Ун мең юлда аунап ятмый бит ул.
Гөлчәчәк кире үз урынына күчте. Акчалы ир җилкәсен җыерып алды да алга таба атлады. Авыл уртасындагы юл чатында ул автобустан төшеп калды.

Арткы тәрәзәгә борылып караган кыз аның юл уртасында басып торганын күрде.
«Кара син аны, – дип уйлады Гөлчәчәк. – Кем дип белә ул мине?! Оятсыз нәрсә. Акча дигән була бит әле. Беләбез без андыйларны. Ярты автобус кыз җыеп була, имеш».
Гөлчәчәкнең кәефе төшкән иде. Ул, автобуста утыручыларның үзенә таба борылгалап караштыруына да игътибар итмичә, үз уйларына чумып бара башлады. «Бүген эш хакы алгандыр, – дип уйлады ул төшеп калган ир турында. – Юкса андый акчаны гел үзе белән йөртмидер инде. Хәер, хәзер кешене белеп булмый шул. Кара, ун мең бит, ә!»
Гөлчәчәк ирексездән ун меңгә нәрсәләр алып булганын исәпли башлады. Бу акча аңа бик күп булып тоелды. «Эх, кышкы итекләр дә кирәк быел, – дип уйлады ул, үзенең булачак эш хакын күз алдына китереп. Чыннан да, ун мең алыр өчен, аңа айдан артык эшләргә кирәк иде. – Кара син аны, бер төн өчен, ди бит».
Кызның күңеле кузгалган иде. Ул автобусның үз авылларына кереп килгәнен дә абайламады. «...Ә миңа аның өчен айдан артык чиләнергә кирәк җыен аңгыра белән. – Гөлчәчәк тагын артка таба борылып карады. – Мунча да кертәм, дигән булды үзе, озатып та куям, диде. Ун мең бит, ә. Кара син аны. Соң, үзе артык ямьсез дә түгел иде бит ул...»
Ләкин автобус ир төшеп калган авылдан ерак киткән иде шул инде...

**Армиягә хатлар**

**Беренче хат**

Фәриткә армиядәге абыйсы Ринаттан бүген дә хат килде. Еш яза иде хатларны Ринат авылга. Әниләренә аерым, энесенә аерым язган хатлары атнага икешәр килә аның. «Сагынадыр инде, – дип уйлады Фәрит, хатны укып чыккач. – Әле кайтырга да шактый вакыт бар шул». Абыйсы бу юлы да авыл хәлләрен, исәнлек-саулык сорашкан, үзен армиягә озаткан Гөлназның

ниләр эшләвен бик тәфсилләп язуны үтенгән иде. Ә үзе турында «Әлегә исән-сау, хезмәт бара, көннәр үтә әкрен генә» диюдән башка берни юк.
«Ярар, моңарга тиз генә бирәр хат әтмәлләп ыргытырга кирәк», – дип уйлады Фәрит, кәгазь, авторучка алып өстәл артына утыргач. «Исәнме, абый, – дип башлады ул хатын. – Синең хатыңны алдым. Онытмыйча язганың өчен рәхмәт. Үзем әлегә исән-сау яшәп ятам шунда». Фәрит каләмен авызына кабып уйга калды: тагын нәрсә язарга икән? Бераз уйланып торгач, ул хатын дәвам итте: «Авылда тормышлар бер көе бара. Артык яңалык юк кебек. Ә, язарга онытып торам икән, узган атнада кечкенә генә «ЧП» булып алды бездә. Шайтан очы Рәшидә апаның шәһәрдән кайткан оныгы абзарларында бәрәңге пешергән. Ул көнне җил бик каты иде. Хәзер безнең авылда Шайтан очы дигән урам юк инде. Йортлары булмагач, кешеләре кайсы кая таралып бетте.
Өченчекөн калхуз рәисе Әгъдәс абый исерек килеш үзенең машинасы белән Хәерниса әбиләрнең өенә кергән. Машинасы пәрәмәч булган – үзенең тырналган урыны да юк. Калхузның төзелеш бригадасы хәзер Хәерниса әбигә яңа өй күтәреп маташа. Аннары безнең күрше Гамил абый белән Резидә апа аерылыштылар. Резидә апа Гамил абыйның каяндыр алып кайткан өч литр самагунын тиреслеккә чыгарып түккән икән. Хәзер аерым торалар: берсе өйләрендә, икенчесе мунчада. Аларның мунчалары зур бит.
Хәтерлисеңме: Хәерниса карчыкларга кайта торган симез кыз белән син үзең дә анда өч төн кунып яткан идең. Ул кыз хәзер Рәшит абый малаенда кияүдә, бик яхшы торалар. Бүген калхузда былтырның январь ае өчен акча бирергә тиешләр, ди. Әни иртән борчылып тора иде. «И Ходаем, бу юлы ниләр булып бетәр инде, акча бирсәләр?» – дип. Кибеттә аракы тулып ята. Ну бездә күбрәк әче бал эчәләр. Теге сине яратмый торган участковый Хариска белый горячка булды. Ниндидер ярамаган нәстә эчеп, пистолетыннан шарт-шорт атып, ферма буенча йөгереп йөргән җиреннән алып киттеләр үзен. Хәзер безнең авыл гүпчем милициясез калды.

Калхуз умартачысы Салих әле күптән түгел өр-яңа машина алган иде. Беркөнне аның ишегалдыннан шул машинаны урлап чыгып киткәннәр. Җитмәсә, келәтеннән өч бидон балын да эләктергәннәр, ди. Салих абый бик боек йөри хәзер. Олылар әйтүенә карасаң, имеш, хатынын күршесе Хәмит абый белән тоткач та, болай ук кайгырмаган булган икән. Үз-үзен харап итмәсә генә ярар иде, ди авыл халкы.

Быел бездә бик коры булды. Печән аз. Калхузныкын урлармын дияр идең – калхуз кырында да печән юк. Әти әйтә, малны ачка үтереп булмый, ди. Сатса, акчасын бер айда эчеп бетерә инде ул.

Син «Мотоцикл ни хәлдә?» дигәнсең. Мин беркөннәрдә аның белән су керергә барган идем. Мотоцикл хәзер буа төбендә. Чумып-чумып карадык, алырлык түгел. Иске иде бит инде ул. Үзең, кайткач, яңаны алырсың әле.

Теге сине армиягә озаткан Гөлназның кеше белән йөргәне күренми. Ничек күренсен ди инде, ул бит бер ун көн элек безнең авылда мәчет салып яткан әрмәннәргә ияреп чыгып киткән иде. Шуннан бирле кайтып күренгәне юк әле.

Ну, ярар, абый, шуның белән хатымны тәмамлыйм. Исән-сау гына хезмәт ит. Безнең өчен кайгырма.

Сәлам белән энең Фәрит».

Хатны конвертка салып абыйсының адресын язгач, Фәрит бермәл өстәл янында утырды. «Авылдагы бөтен хәлләрне язсам, абыйның йөрәге түзмәс, – дип уйлады ул. – Менә миңа кем шундый хатлар язып торыр икән?» Солдат хезмәтенә алынырга Фәритнең үзенә дә бер генә ел калып бара иде.

**Икенче хат**

Абыйсы Ринатка армиядән туган авылына кайтырга санаулы гына көннәр калгач, Фәритне дә солдат хезмәтенә алдылар. «Монысы да артык жәл түгел, ну, абый кайткач, «мырык» булганчы бер эчеп булмады...» – дип уйлады Фәрит Хәрби комиссариат янында, иректә соңгы минутларын басып торганда.

Авылга кайтып, атна-ун көн нәрсә Яна, шуны эчеп, кем риза, шуның белән «күңел бушатып», кеше рәтенә кергәч, Ринат армиядәге энесеннән килгән хатка җавап язарга утырды.

«Ну, дух, хәлләр ничек? – дип башлады ул хатын. – Инәйнең бәлешләре исеңә төшә башладымы әле? Хезмәт ничек бара? Ничек авыр булса да, Фәрит энем, син түз инде. Бераз хезмәт иткәч күнегелә инде ул. Главный, үзеңнең кеше икәнеңне онытырга кирәк. Аннары ишәк кебек тик йөрисең шунда, селкенеп. – Энесенә ничек хезмәт итәргә кирәклеге турында үгет-нәсыйхәтләрне биргәч, Ринат авыл хәлләренә күчте: – Авылда тормыш шул көе бара үзе. Аерым язарлык хәл булганы юк. Теге мин армиядә чакта янып беткән Шайтан очына җан керә башлады. Хәзер анда калхуз рәисе Әгъдәс абый белән Хәерниса әбинең шәһәрдән кайтып йөри торган оныгы кирпечтән өйләр салып ята. Хәерниса карчыкның оныгын син хәтерлисеңдер әле? Башлангыч сыйныфларда сезнең белән укыган иде бит ул. Беренче сыйныфта өч ел утыргач, аны теге «җитешеп бетми» торган балалар укый торган мәктәпкә җибәргәннәр иде. Хәзер аның Казанда үз фирмасы бар, диләр. Ә Әгъдәс абыйның хәзер тән сакчыларына хәтле бар. Катыржан Сафа «суям» дигәч, специәлне шәһәрдән кайтарткан ул аларны. Икесе дә нәсел үгезе хәтлеләр. Калхуз тагын берәр ел акча бирмәсә, Әгъдәс абый вертолёт та алыр әле. Исерек килеш үзе шулай сөйләнгән.

Күрше Гамил абый белән Резидә апа урыннарын алыштылар. Гамил абый, үзенә яңа хатын итеп, Мишәр Гасимәсен алып кайткач, Резидә апа Гамил абый урынына мунчага яшәргә күчте. Гасимә, мин аны әле мунчадан да куалап чыгарам, дип әйтә, ди.

Мин армиядән кайтырга өч кенә көн калгач, калхуз кибетендә эш хакы хисабына аракы бирә башлаган булганнар. Үзе андый-мондый асубый хәл булмаган авылда. Ну, шул өч электр баганасы ауган, тракторист Вил тегермәнне ишкән, и калхузның сыерлары өч көн ач яткан. Әллә ачлыктан, әллә көнләүдән нәкъ шул көннәрдә нәсел үгезе ассиминатор Хәйдәр абыйны

сөзеп имгәткән. Врачлар әйткән инде, бу кеше, айнык булса, өч тапкыр үлгән булыр иде, исерек булганга гына исән калган, дип.

Участковый Хариска белый горячка булып, больницага алып киткәннәрен хәтерлисеңдер. Тәк вот, аңарда бернинди дә белый горячка булмаган икән. Шәһәр врачлары, моны тикшереп карагач, бу кеше тумыштан дивана булган, дигәннәр. Дөрес булса, аның баш мие этнеке хәтле генә икән. Кара әле, мин сиңа әйтим, егерме ел, пистолет тотып, авыл халкының җанын ашап яшәде бит шул тиле.

Умартачы Салих абыйның урланган машинасының ике ишеге белән бер тәгәрмәчен авыл читендәге урманнан таптылар. Җитмәсә, ул нәкъ шул көнне хатынын тагын күршесе Хәмит абый белән тоткан. Шуннан соң ул умарталыкны ташлады. Хәзер Салих абый урам буйлап: «Яшәсен иптәш Берия!» – дип кычкырынып йөри.

Буага барып, мотоциклны эзләп карадык беркөнне. Ниндидер чит ил марка машина таптык, ә мотоцикл юк. Мужыт син аны бүтән җирдә югалткансыңдыр. Исеңә төшсә яз, яме. Сине армиягә озаткан элеккеге Шайтан очы Әмиренең кызы Ләйсән укытучы Варис абыйдан корсаклы икән. Хәзер өйләнешергә йөриләр, ди.

Авылда, ниһаять, мәчет ачылды. Ачылу тантанасында азан әйтергә генә кеше булмады. Түбән оч Мөнир абзый алдагы көнне күршеләрендә туйда гүләйт иткән булган, шуңа күрә сүзләрен оныткан. «Юлдаш» гәҗитенә карап, азанны Бур Вәлиәхмәт әйтергә җыенган иде дә, манарага менгәч, аның башы әйләнә икән. Шулай итеп, азан әйтмичә генә, мәчет ачтылар бездә. Әле моңа кадәр анда каравылчы Сәхип абзыйдан башка йөрүче дә юк иде. Авыл яшьләре: «Җимерелә башлаган клуб урынына мәчетне генә бирегез безгә», – дип сөйләнгәч кенә йөри башладылар.

Ну, ярар, энем. Без әлегә исән-сау. Син үзеңне генә кара. Әбигә пенсия акчасы килү белән, сиңа да әзрәк җибәрербез. Яхшы гына хезмәт ит. Служи, сынок, как дед служил. Ну, в общем, син мине аңладың инде. Давай, Фәрит, безне падбадить итмә.

Сәлам белән абыең Ринат».

Хатны язып бетергәч, нәрсәдер исенә төшкән кебек, үзалдына елмаеп куйды да, конвертка энесенең адресын язып, хатны почта тартмасына ташларга дип, урамга чыгып китте.

**Сугымчы һәм укытучы**

Авылда иң оста мал суючы буларак танылган Күке Рәшите гәүдәсе белән генә түгел, аң үсеше ягыннан да үзе чала торган маллар белән бер тирәдәрәк торса да, гомумән алганда, начар кеше түгел иде. Мал сую осталыгы аларның нәселеннән килеп, Рәшит тә бу эшкә җиде-сигез яшьлек малай чагыннан ук катнаша башлаганга, яше кырыкка якынлашкан сугымчы хәзерге көндә, әгәр кушсалар, вак-төяк операцияне килде-китте хирурглардан ким ясамаслык дәрәҗәдә остарган иде. Чыннан да, яхшылабрак карасаң, сыер-сарык белән кешенең тән төзелеше арасында әллә ни аерма юк бит, бары тик берләрендә йон белән мөгез булып, икенчеләре бу яктан Тәңре тарафыннан мәхрүм ителгән. Хәер, бу мәсьәлә дә бәхәсле әле.

Елның унбер аенда авызына хәмернең тамчысын да капмаган Рәшитнең, көч кулланып, беркемгә дә зыян салганы булмыйча, шул калган бер айда, ягъни авылда маллар сую вакыты җиткәч «ычкынып» китеп, кайбер «шуклыклар» эшләве дә аның авылдашларына бик мәгълүм иде. «Шуклыклар»ның сәбәбе дә билгеле. Кемдә дә булса мал суелган көннәрдә, Рәшит, гомумән, айнымыйча эчә, сугым бетеп, киләсе елга кадәр сугымчының кирәге калмагач, аңа салып бирүчеләр дә бетә. Шуңа күрә дә Рәшиткә, зәмзәм суы табып баш төзәтү өчен, әллә нинди юлларга басарга туры килә.

Быел да ул шулай булды. Салкын гына бер кичтә башы авыртуга түзә алмаган Рәшит нәрсә булса да табарга дигән ният белән урамга атлады...

...Китапханәдән бер кочак китап төяп кайтып килүче Күзлек Гамиры, уйлары белән дөнья яшәешенә, кешелекнең киләчәгенә кагылган сорауларга җавап эзли-эзли тын авыл урамыннан атлап килгән җиреннән, кинәт сөрлегеп китте.

Аның каршында, тау хәтле гәүдәсен бераз чайкалдырып, Күке Рәшите басып тора иде.
– Исәнме, күрше, – диде Рәшит, урамны яңгыратып, һәм бүрәнәдәй кулы белән Гамирның җилкәсенә кагылып куйды.
Үз гомерендә китаптан авыр нәрсә күтәрмәгән укытучы Гамир бу кагылудан сыртына күсәк төшкән язгы бозау кебек чүгеп куйды.
– Исән әле, – дип пышылдады ул, Рәшитнең күзләренә буар елан күзенә текәлгән куян баласы кебек текәлеп.
Рәшит сәер генә елмаеп куйды. Бу елмаю Гамирның котын алды. Аның тез буыннары йомшап китте.
– Тәк, егет, – дип дәвам итте Рәшит, тавышын әкренәйтә төшеп. – Мин спициәлне сине көтеп тора идем монда.
Әллә ни аң белән мактана алмаса да, махмыр Рәшит башын үзенә кирәк якка таба бик яхшы эшләтә башлады. Сугымчы укытучыдан берәр ярты кысу хәйләсен мизгел эчендә уйлап тапты. Ул тагын Гамирның котын алып елмайды да:
– Син нәрсә, Күзлек, минем хатын янына йөри башладыңмыни? Әллә сиңа авылда бүтән кыз-кыркын беттеме? – Рәшит Гамирга якынрак килде: – Башыңны муеныңа сугып кертәм бит хәзер күзлегең-чуртың белән...
Гамирның кинәт күз аллары караңгыланды. Рәшит Гамирга башын күзлеге-чурты белән гәүдәсенә сугып кертүдән башка тагын бик күп куркыныч җәзалар вәгъдә итсә дә, укытучы егет аларын ишетмәде диярлек. Рәшит, көрәктәй куллары белән җилкәсеннән тотып, җирдән аергач кына аңга килгәндәй булды ул.
– Йә, ярар, алай ук дерелдәмә, – диде Рәшит, Гамирның агарып каткан йөзенә текәлеп. – Җыен өстерәлчек өчен җан кыя торган кеше түгел мин. Кайтып, хатынның үзенең иманын укытырмын әле. – Рәшит бертын дәшми торды. – Ә синнән егет, – диде ул бераздан, – хәзер үк бер литр и вәссәлам. Ну, чтубыты бүтән андый эшеңне сизмим. Юкса беләсең...

«Юкса белгәнгә», Гамир, метеор тизлеге белән барып, кичләрен өендә аракы сатучы Фатыйма ападан ике ярты алып килде һәм Рәшиткә тоттырды. Дөресен генә әйткәндә, бу мизгелләрдә бернәрсә дә уйларлык хәлдә түгел иде ул.

Ике яртыны ике кесәсенә тыккан Рәшит капкасыннан кереп китеп, кечкенә өенең тәрәзәләрендә ут кабынгач кына, Гамир Рәшитнең беркайчан да өйләнмәгән булуын гына түгел, гомумән, хатын-кыз заты белән чуалмаганын исенә төшерде...

Бераз басып торгач, Гамир, тиле кеше кебек, күзлек астыннан гына үзалдына елмайды да өенә юл тотты.

**Елгалар... елгалар**

– Исәнмесез, балалар! Утырыгыз. Кем анда «түзсәң чыдарлык» диде? Синме, Вәлиев. Сиңа түгел, ә миңа түзәргә кирәк синең ише аңгыралар белән, аңладыңмы? Ну, ярар, нәселдән килгәнне мин генә төзәтә алмыйм инде аны. Тә-әк, дәресне башлыйбыз. Үткән дәрестә без... Хөснуллина, нәрсә ашыйсың анда? Күкәй? Нинди күкәй ашау ди ул дәрестә? Тавык күкәемени? Кем сиңа, Хөснуллина, география дәресендә тавык күкәе ашап утырырга рөхсәт бирде, ә? Ашыйсың килә? Хе, хәзерге заманда кемнең ашыйсы килми ди. Соң, ярар инде, ярар, елама шулкадәр. Аша дим, аша күкәеңне. Кабыгын гына идәнгә ыргытма. Вәлиев, урыныңа утыр. Ашыйсың килсә, үзең күкәй алып килергә идең өеңнән. Нәрсә мыгырданасың әле син анда? Ну, ярар, мин моны ишетмәдем. Аңладыңмы, Вәлиев, ишетмәдем мин моны. Күкәйләр турында әйткән сүзеңне дим.

Балалар, үткән дәрестә без илебез киңлекләрендә аккан елгаларны өйрәнгән идек. Хәзер шуны кабатлап узарбыз. Тә-әк, бүген кем безнең сыйныфта дежур? Вәлиев, синмени? Ә нигә такта сөртелмәгән? Язгалап бетергән тактада эшли алмыйм бит инде мин. Тукта, тукта, Вәлиев, нәрсә дип язган анда? Бу нинди әшәкелек? Нинди оятсызлык бу? Кем язды ул сүзләрне? Кем язды, шул сөртсен әле тактаны. Сөртә бит инде, дисезме? Вәлиев, каян

ишеттең син андый сүзләрне? Миннән? Кайчан ишеттең? Көтү куганда таеп егылгач, дисеңме? Әле тагын әйттем? Ярар, ярар, яп авызыңны, Вәлиев. Кирәкмәгәнне ишетәсез дә хәтерләп тә каласыз шул сез. Тә-әк, Хөснуллина, күкәеңне ашап бетердеңме әле? Бетерсәң, әйдә, чык такта янына. Әйт әле безгә, Хөснуллина, нинди елгалар беләсең син? Нигә дәшмисең? Әзерләнмәдеңмени дәрескә?! Ни сәбәпле? Әтиең исерек иде? Өйдә кунмадыгызмыни? Ну, ярар, утыр, Хөснуллина. Тә-әк, кем җавап бирә инде безгә хәзер?.. Безгә, безгә, әйдә, Галиев, син җавап бир әле. Әзерләндеңме дәрескә? Юк! Утыр, икеле. Нинди сәбәп ул тагын? Сыер бозаулады, дисеңме? Соң, шул сәбәп буламы? Сыер бозаулаган саен, дәрескә әзерләнмәсәң, бер дә укып торырга кирәк түгел аннары, синеңчә. Елга бер генә тапкырмыни? Беләм, Вәлиев, беләм, синнән башка да сыерның елга бер генә бозаулаганын беләм. Ә менә син, Вәлиев, үзең әзерләндеңме дәрескә? Йә, әйт әле, нинди елгалар беләсең? Ә син нишләп әзерләнмәдең? Киресенчә, дисеңме? Нәрсә, киресенчә? Ә-ә, сыерыгызны үгезгә алып бардыгызмыни?! Кысыр калган иде? Соң, булдымы соң? Ярый, ярый, дәшмә, Вәлиев, аңладым. Дәшмә, дим, утыр.

Тә-әк, кем җавап бирә инде безгә? Әһә, әйдә әле, Җәләев, җавап бир әле син безгә, нинди елгалар беләсең? Белмисең?! Соң, хет дәфтәреңнән булса да укы. Яздык бит узган дәрестә. Нәрсә? Дәфтәрем юк, дисеңме? Кая куйдың соң син дәфтәреңне? Ә-ә, әбиең мич кабызганмыни?! Соң, синең дәфтәреңнән башка бүтән кәгазь таба алмаганмы ул? Сукыр? Ә-ә, чыннан да, Хөснурый абыстай сукыр бит әле. Ну, ярар. Безгә хәзер җавап бирер... Җавап бирер... Әйдә әле, Кәримов. Тәк, нинди елгалар беләсең син? Менә кара, Кәримов. Тыгыл әле кесәңә. Нәрсә бар анда? Әйдә, әйдә, курыкма, чыгар. Нәрсә бу? Дөрес, тәмәке. Кабына нәрсә дип язылган? Дөрес, «Идел» дип. Менә сиңа булды бер елга. Тагын беләсеңме? Ну, ярар, утыр, өчле.

Безнең илебездә елгалар бик күп, балалар, Иделдән башка Урал, Кама, Агыйдел, Енисей, Ангара һәм башка исемдәге бик күп елгалар бар. Елгалар саны буенча безнең ил... Хөснуллина, нәрсә ашыйсың син тагын? Бәрәңге

бөккәне, дисеңме? Соң, Хөснуллина, әллә бер дә ашамыйча тора алмыйсың инде син, балакаем?! Вәлиев, утыр урыныңа. Нәрсә, өеңдә ашатмыйлармы әллә сине? Ә-ә, сезгә шәһәрдән кунаклар кайткан идемени?! Булган нәрсәне төяп киттеләр? Соң, бәрәңгегез калгандыр бит. Аңлыйм, Вәлиев, аңлыйм. Ә сезнең, Вәлиев, көтү чиратыгыз кайчан әле? Иртәгә? Чукынчык, безгә дә килеп җитә икән инде. Тә-әк, елгалар... елгалар... Җәләев, нәрсә күрдең тәрәзәдә? Директор абый исерек, дисеңме? Кем әйтте сиңа аны исерек дип. Машинага күтәреп чыгып салдылар? Салсалар бит, мужыт ул арыган гынадыр. Исерек, имеш. Сезгә белем бирүе, беләсеңме, ничек авыр? Шуңа арый директор абыегыз. Көн дә? Соң, көн дә арыйдыр инде. Нәрсә көләсең, Җәләев? Этләр? Нинди этләр? Ә-ә, урамдамыни?! Соң этләрнең ни кызыгы бар инде? Вәт оятсыз син, Җәләев. Соң урам этләренең нишләгәнен караганчы, дәресеңне кара. Ә син кая үреләсең, Хөснуллина? Иртәрәк әле сиңа этләрнең нишләгәнен карарга, иртәрәк. Өлгерерсең. Тә-әк, елгалар... елгалар... Вәлиев, ә көтү чиратына сез ничәү чыгасыз? Әтиең белән икәү? Яңгыр яумас микән бу арада? Елгалар... елгалар... Хөснуллина, тагын нәрсә чәйнисең инде анда? Ә-ә, бу юлы сагызмыни... Ярар, чәйнә инде, чәйнә. Кара әле, балалар, нинди төтен бу? Кәримов, чукынчык, әллә тәмәке тарта инде? Соң, бер дә түзә алмыйсыңмыни, ә? Тәнәфескә күп калмады бит инде. Сүндер, сүндер, дим. Соң, Хөснуллинаның аркасына түгел, идәнгә сүндерәләр тәмәкене. Вәт Кәримов, ә. Тә-әк, елгалар... Нәрсә дисең, Вәлиев? Кем әйтте, бүген колхоз икмәк бирә дип? Чынлап, радиодан әйттеләрме? Сез аласызмы соң? Әһә... әһә... Елгалар... Вәлиев, ә ындыр табагыннан бодаегызны нәрсә белән алып төшәсез? Ат белән? Ни, Вәлиев, безнекен дә алып төшеп булмасмы икән? Бер ярты? Ну-у, Вәлиев, шулай булмый бит инде. Ярар, ярар, карарбыз... Тә-әк, елгалар. Әһә, бетте дәрес, балалар, Аллага шөкер, бетте. Шулкадәр дөбердәмәсәгез дә була. Сау булыгыз, сау булыгыз. ...Вәлиев, мине онытма. Бодайга, дим... Елгалар... Әй, заразы, көтү чираты да җитте бит, җитмәсә...

**Саулыгым – байлыгым**

Менә сез минем турыда әллә нәрсәләр уйлыйсыздыр инде. Өрлек кебек ир, шундый укымышлы, шундый чибәр, зифа буйлы, беренче хатыны белән тора алмады дисездер инде. Дөрес, торып булмады шул аның белән. Үзе бик уңган, бик булган хатын иде дә бит...

Юк, юк. Сез уйлаганча, андый-мондый кырын эшләре дә сизелмәде хатынның. Үземнең дә исәнлек мир үгезенеке кебек иде, өйләнгәндә. Безнең аерылышуга хатынның китап уку белән артык мавыгуы гына сәбәп булды. Каюм Насыйри оныгы диярсең, аз гына буш вакыты булса, китап укый иде ул. Ә бөтен укыган нәрсәсе – сәламәтлек саклау турындагы китаплар. Хәләл җефетемнең шул сәламәтлекне кайгыртуы аркасында харап булды да инде безнең тормыш. Ничекме? Хәзер, мишәр әйтмешли, сүлим.

Туй мәшәкатьләреннән айнып беткәч тә әйтә бу миңа: «Рашитик, без булачак балабызның исәнлеге турында хәзердән үк уйларга тиеш, шуның өчен син эчүеңне нимидленно туктат», – ди. Имеш, мондый авыр заманда без дөньяга сау-сәламәт бала тудырырга тиеш. И, һәм дә шуның өчен хәзергә безгә бергә йокларга ярамый икән. Нишлисең, яшь чак, тиле чак, тешләрне шыгырдатып булса да күндем мин моның сүзләренә. Өйләнгәнче, бер көтү дус-иш бар иде, эчүне ташлагач, бар да каядыр югалып бетте. Ну, яшь хатын белән йоклыйсы килү шундый көчле иде, түздем мин монысына да.

Берәр ай үткәч, янында сырпалана башладым хатынның. Мин әйтәм, аракы парлары канымнан чыгып бетте, киләчәк буын турында уйлый башласак та ярар. Хатын әзрәк уйланып торды да әйтә: «Эчми башлавың әйбәт синең, Рашитик, – ди, – тик син бит тәмәке тартасың, анысы да агу бит аның, балабыз исән булсын дисәң ташла тартуыңны», – ди. Әзрәк карышып маташсам да, барыбер бу юлы да хатын җиңде бит, малай. Җиңмәс иде дә, аның аталары алып биргән фатирда торабыз. Мин бит авыл малае, миңа башкача шәһәрдә фатирны кем бирсен?! Тартуны ташлау авыррак булды. Кәнфит тә суырдым, корсаклы хатыннар кебек, сагыз да чәйнәп карадым, барыбер тартасы килү басылмады. Төннәрен, ач бүре кебек, айга карап

улыйсылар килә иде, малай. Ну, нәселне дәвам итәсе килү хисе барыбер җиңде. Җиңми ни, өйлән дә, хатының белән бергә дә йоклама, имеш. Чалбар балакларыннан төтен чыга башлаган иде инде минем соңгы вакытта.
Ничек кирәк, шулай ташладым мин тәмәкене дә. Ләкин хатын миннән көн саен иртән зарядка ясата башлады. Салкын су белән коеныргa күнектерде. Боларның барысы да булачак балабыз исән-сау булсын өчен кирәклеге турында хатын миңа көн саен лекция укыды, ә урынны һаман аерым җәйде. Эчү-тартуны ташлагач, хезмәттәшләрем дә миңа сәерсенеп карый башлаганнар иде, тик мин түздем. Чибәр иде бит минем беренче хатын, зерәләр дә чибәр иде, шайтан алгыры.
Бердәнбер көнне гүзәлем өйгә ниндидер америка карты язган «Ач тору могҗизасы» дигән китап күтәреп кайтты. Шунда минем беренче тапкыр яшисе килми башлады, малай. Икенче көнне мин ач тору ярдәмендә йөз чирнең туксан тугызын җиңеп була икәнен белдем. Төрле агулар белән пычранган организмны да ач торып чистартып була икән. Сөйгәнем мине атнасына ике генә тапкыр ашата башлады. Ябыктым, күзләрем белән борыным гына торып калды битемдә, ләкин барыбер түздем әле мин. Күрәсең, ихтыяр көчем нык булган инде минем ул чакта. Менә сезгә кызык ул. Ә үзегез, яхшы гына яшәп ятканда, эчүегезне, тартуыгызны, ашавыгызны ташлап карагыз әле. Ашамый башлагач, хатын белән йоклыйсы килү теләге дә юкка чыкты. Үләксә кебек, эшкә сөйрәлеп барам, үләксә кебек кайтам. Аннан авам диванга. Озак интектерде мине мәхәббәт сандугачым шулай. Ә мин түздем, мондый тормыш үземә дә нәрсәсе беләндер ошый башлаган иде инде.
Көннәрдән бер көнне кайсыдыр каһәр сукканы хатынга яңа китап биргән. Анысы «Дөрес сулау серләре» дип атала иде. Әһә, минәйтәм. Бу аждаһа мине һавадан мәхрүм итәргә тели. Булган киемнәремне култык астына кыстырдым да чыгып сыздым мин бу хатын яныннан. Яшисе килү теләге нәсел дәвам итү инстинктын җиңгән иде инде.

Хәзер мин икенче хатын белән торам. Эчәм, тартам, ашыйсы килгәнчә ашыйм – исәнлек, Аллага шөкер, тагын ун хатынга җитәрлек. Күптән түгел игезәк малайларыбыз туды. Икесе дә тупырдап торалар – сау-сәламәт. Тормыш матур, дөнья киң! Вакыт-вакыт беренче хатын белән торган көннәр төшкә кереп кенә кәефне бозып куйгалый куйгалавын. Куркып уянгач, мин хәзерге хатынымны кысып бер кочаклыйм да тагын изрәп йокыга китәм.

**Хәйлә кирәк**

– Энем, каян кайтып киләсең әле, болай сөйрәлеп? Үзеңне, мукшы көтүчесе кебек, сакал-мыек та басып бетергән. Политсәдән, дисеңме? Соң, япь-яшь башың белән нишләп барып эләктең соң анда? Әллә калхуздан берәр нәрсә чәлдереп эләктеңме? Анда бит алар безнең ише хәерчене эләктерергә генә торалар. Әнә калхуз рәисе аларның нәчәлниге белән бергә эчкәч, урласа да, аңа берни юк. Ул бит өч сыерны үзе сата, дүртенчесен район нәчәлствосы белән бергә ашый.

Бернәрсә дә урламадым, хатын үзе, шалтыратып, алар кулына тапшырды, дисеңме? Булыр, булыр, ышанам, энем. Өйдә бер-бер нәрсә майтардыңмыни? Әллә хатыныңның анасын кыйнадыңмы? Эчкән өчен генә тапшырды, дисеңме? Да-а, малай. Алайса алар сиңа ныклап тотынганнар инде... Соң, хәзер нишләргә уйлыйсың? Син тагын, кызган баш белән кайтып, өеңдә ул-бу кузгата күрмә. Сизми дә калырсың: тагын участковыйга барып әйтәләр дә тагын озаталар үзеңне. Хәзер бит, энем, бездә хатыннар заманы. Нәрсә эшләсәләр дә, аларныкы дөрес. Әнә кара әле, элек җилдән бәбәй тапкан хатынны кем диләр иде? Дөрес, дөрес, шулай диләр иде. Ә хәзер андыйлар – мать-одиночка. Аларны хөрмәтле дәүләтебез ире белән торып бәбәйләгән хатыннарга караганда ныграк кадерли. Шулай, энем, ирек бирделәр хатыннарга, артык уйламыйча, ирек, шуңа күрә хәзер көч белән җиңә алмыйсың син аларны берничек тә. Монда хәйлә белән эш кылсаң гына.

Әнә минем баҗайның хатыны – шул минекенең апасы инде – бер елны тужы шулай гадәтсезгә әйләнеп киткән иде. Баҗай әз генә «йотып» кайтса, тота да,

политсиягә шалтыратып, моны озата икән бу. Ну, баҗай мишәр минем, моның башы калхуз бухалтеры Зәкинекеннән ким эшләми, малай. Хатыны шулай аптыраткач, уйлаган-уйлаган да тегене акылга утырту әмәлен тапкан бу. Кибеттән өч-дүрт кило кадак алып кайткан беркөнне. Елмаймыйча да: «Карчык, мә әле, менә бу кадакны ике-өч сәгать утта нык кына кайнатып ал, – дигән. – Әнә гәҗиттә, шулай итсәң, кадак йөз ел торса да күгәрми, дип язганнар, мунча түбәсен кадаклыйсы бар бит», – дигән. Ә хатыны моның үзе усал булса да, аң ягы теге... ниерәк инде, бөтен хатын-кызныкы кебек. Җитмәсә, гәҗит-фәлән дә укый торган нәстә түгел. Аннары акчаны да бик ярата. Кадак йөз ел күгәрмәсә, күпме иканум була бит. Салган бу кадакларны кәстрүлгә һәм плитәгә кайнатырга куйган. Ә баҗай, тәмәке тартып керәм дигән булып, урамга чыккан да теге эчеп саташканнар белән тумыштан тилеләр ята торган больниска шалтыраткан. «Шулай-шулай, хатыным күптән диваналанган иде дә инде, моңарчы түздем, ну хәзер түзәрлегем калмады, килеп алыгыз әле, пажалысты», – дигән. Тегеннән: «Нәрсә булды соң?» – дип сорыйлар икән. Баҗай әйткән: «Менә эштән кайтуыма йөз иллеле кадактан аш пешереп маташа плитәдә, – дигән. – Өйгә керергә дә куркам хәзер», – дип тә өстәгән.

Чынлап чирләгән кеше булса, алай тиз йөрмәсләр иде әле. Өйгә керсәләр, диствительны, плитәдә кәстрүл, ә кәстрүлдә өч кило кадак. Ай-ваена карамыйча, баҗайның хатынын алып та киткәннәр. Ә анда, безнең авыл Харис әйтмешли, эләгүе генә җиңел икән. Тегесе-монысы, эшнең нидә икәнен аңышканчы, атна-ун көн вакыт үткән. Акылыңда килеш бер атна тилеләр янында ятып кара әле син. Менә, малай, шуннан соң баҗайның хатыны үтүкләгән кебек инде. Баҗайга дәшкәнче дә, башта уйланып тора. Эчсә дә, сүз әйтми.

Шулай ул, энем, хатыннарны бер-бер хәйлә белән җиңсәң генә аларны. Ә көч белән мәңге дә алдыра алмыйсың. Үгезне йодрык белән бәреп үтерердәй ирләрне дә тезләндерә алар. Син дә, энем, кайт та өеңә, тыныч кына бер-бер нәрсә уйла. Бик аптырасаң, берәр «Бөгелмә малаен» тотып минем янга кил.

Табарбыз әмәлен. Бар-бар, кайтып кер әле, елмаеп, унсигез яшьлек кыз белән печән кибәнендә кунган кеше кебек. Аптырап торсыннар. Хатын-кызның иң курыккан нәрсәсе – иренең сәбәпсез елмаюы ул. Беләм инде, энем, мин андый нәрсәләрне: баштан үткәне бар...

**Үлмисең...**

– Әй, энем, энем, кая исәнләшмичә дә, агулы таракан ашаган күркә чебеше кебек, алдыңны-артыңны күрмичә китеп барасың? Кил әле, кил монда, әзрәк минем янда да утырып кит. Нәрсә булды шулхәтле? Бер-бер кайгың бармы әллә? Юк? Алайса, нишләп син мондый? Махмыр, дисеңме? Кит, тиле, сезнең яшьтә нинди махмыр булсын ди ул. Йокың гына туймагандыр прусты. Әнә каршыдагы чишмәдән ятып кына су эч тә, үтә ул. Эчтем инде, үтми шул, дисеңме? Ә, иркәм, алайса агулангансың син. Әллә Бүдәнә Фатыймасыннан алып эчкән идеңме? Әйтәм бит, шулайдыр дип аны. Соң, дивана, аңардан аракы алып эчкәнче, теге бәрәңге кортына сибә торган агуны эчүең яхшырак. Нигә, дисеңме? Анысы сразы үтерә, ә монысы үлемнән дә болайрак интектерә бит. Фатыйма бит ул теге ялган аракы сата. Аның шешәсен ачып, стаканга салу белән хәтта тирә-яктагы чебеннәр дә качып бетә. Да-а, энем, махмыр өшерә инде ул. Күзлек Гамиры әйтмешли, махмырга караганда, бала табу чүп кенә ул. Нәрсә дип эчтең соң шулкадәр? Кырт иткән хатының, игезәк балаларың бар. Тупырдашып торалар икесе дә. Кайгыдан, дисеңме? Нинди кайгы тагын? Әле генә кайгың юк дигән идең бит. Хатының аналарына кайтып китте? Кит, тиле, шул да булдымы кайгы? Шатлык кына бит бу. Карга Зәкиенең бөтен баласы шул булды инде аның. Әз генә челт итсә дә, аналарына йөгерәләр. Аналары үзе дә шундый иде. Зәки аз чапмады инде аның артыннан авыл буйлап.
Ә син, шагыйрь әйтмешли, кай тарафка юнәлгән идең соң әле? Хатынны алырга, дисеңме? И-и, энем, шулкадәр аңсыз булырга ярыймы инде безнең заманда?! Үзең ун класс бетергән баладыр әле. Менә миңа ышанмасаң, атаң Хафиздан кайтып сора, иеме, әгәр бер кат артыннан барсаң, аннан, минем

яшькә җиткәнче, шулай йөриячәксең. Хатын-кыз бит ул, энем, сыердан әз генә акыллырак. Сыерны бер алып кайтасың киткән җиреннән, ике алып кайтасың, аннары үзе кайта башлый ул өйгә. Ә хатын-кыз алай түгел. Бер барып ялынсаң – вчү. Кайта ул, үзе кайта, менә бу карт тиле әйткән иде диярсең. Бер көн торыр, ике көн. Аннары Зәки аны үзе куып чыгара. Аның кызлар үстерә-үстерә пеләшләнеп беткән башына синең игезәкләрең кирәкме әллә? Нигә йөзеңне сытасың әле? Ә-ә, махмыр бит әле синең. Тозлы кыяр суы эчеп карамадыңмы соң? Файдасы юкмыни? Бер-ике баш дару кап. Мин үзем дә бик интеккән чакта уйлый идем: соң, мин әйтәм, дөньяда күпме врач бар, нужәли махмырны сразы бетерә торган берәр дару таба алмыйлар? Шундый дару булса иде ул, мин әйтәм, берне каптың, и вчү. Баш та авыртмый, башка җир дә. Ә-ә, син дә шулай уйлыйсыңмыни? Соң, энем, бар икән бит бу дөньяда андый дару, бар икән. Кайда, дисеңме? Әйдә, кичә әбиеңә күрсәтмичә генә берне алып кайтып келәткә яшергән идем. Кереп кабыйк та икәү шул даруны, сразы рәткә кереп китәсең. Әйдә, әйдә, үтермибез инде синдәй егетне. Ату хатынын алырга бара, имеш. Вәт тиле!..

**Бәхет**

– Нәрсә елап утырасың, агай-эне? Ни булды? Бәхетсез мин, дисеңме? Әллә тиле инде син, туган? Япь-яшь кеше бәхетсез була димени? Нәрсә? Хатыным кеше белән йөри, дисеңме? И-и, дивана. Шул да булдымы кайгы? Син нәрсә, кеше белән йөрмәгән хатын-кыз бар дип уйлыйсыңмы әллә? Хатыны гүләйт итә, имеш. Синеңчә уйласаң, бөтен ир-ат бәхетсез булып чыга бит. Пүчтәк бу, туган. Әнә безнең авыл Хәсәннең өч баласы да үзенеке түгел. Моны бөтен авыл белә, Хәсән үзе генә белми. Шуңа карап кына, Хәсәнне бәхетсез дип булмый бит инде. Ә син “бәхетсез”, имеш. Соң, аңгыра, кеше күзе төшәрлек хатының булганына шатлан. Әнә безнең урам Әнисәгә беркем дә карамый, чөнки ул үзе сары, үзе нигырга охшаган. Вәт шундый хатының булса, булыр идең бәхетсез. Ә болай кеше белән йөрерлек хатының булганга шатланып кына торырга кирәк.

Ну, бәхет дигәнең шундый нәрсә инде ул, туган: бөтен кешегә дә бирелми. Бер килмәсә килми. Әнә безнең күрше Рәшит әйтә бит: «Бәхетең булмаса, балдызыңнан да начар чир эләктерәсең», – ди. Рәшит яхшы белә хатын-кызны. Ул бит, гомерендә бер тапкыр Казанга килеп, үтә күренмәле күлмәк кигән яшь кенә бер марҗаның могҗизаларына сокланып бара-бара, машина астында калып, аягын сындырган кеше. Соң, син менә кара, туган, берәү үзе пүчтәк кенә кеше була, ә аңа бәхет ишелеп килә. Андыйларга кунак та килми, сыерлары да елга икешәрне бозаулый, хатыны да мишәр була. Ә икенче берәү карап торырга кырт иткән кеше инде, ә бәхете юк. Аның хатыны да игезәкләр таба, сыеры да кысыр кала, бәрәңгесен дә корт ашап бетерә. Шуңа мин үзем уйлыйм инде: бәхетне, мин әйтәм, Ходай аны-моны карамыйча, өстән ыргытадыр да, кем эләктерә ала, шул бәхетле буладыр. Бәлки, шулай дөрестер дә ул. Чөнки син үзең уйлап кара, бөтен кеше бәхетле булса, нинди тормыш була ди? Имеш, мин дә бәхетле булыйм, теге каһәр суккыры безнең силсәвит Гомәр дә бәхетле булсынмы? Алай була алмый ул, туган. Берничек тә алай булырга не может. Чөнки Гомәрнең шатланып йөргәнен күрсәм, минем йокы кача, ә миңа берәр шатлык килсә, ул, тешен ашап, кеше белән сөйләшмәс була. Нигә алай, дисеңме? Без бит яшь чакта икебез дә бер кыз артыннан йөрдек. Шул кәкре аяклы нәрсә өчен атнага бер канга батып сугышмый калмый идек, малай. Минем сул кул шул чактан ук бөгелмәс булып калды бит инде. Ә Гомәрнең мин сугып имгәткән ияге хәзер дә урынына утыра алмый. Шулай булгач без Гомәр белән бер үк вакытта бәхетле була алмыйбыз бит инде. Ә теге кәкре аяклы кәнтәй кайсыбызны сайлады, дисеңме? Беребезне дә сайламады шул. Шәһәргә китеп, ниндидер бер алак-шалакка кияүгә чыкты. Бик яхшы торалар дип сөйлиләр.

Шулай, туган. Кара әле, агай-эне, син үзең кемнәргә кайттың соң? Кемнең кияве дисең? Кәлимулла абзыйныкы? Хатының Сания исемлеме әллә? Соң шул бит инде ул, безне яшь чакта Гомәр белән сугыштыра торган нәстә. Кара әле, туган, Гомәр белән йөрмиме икән соң ул? Белмим, дисеңме? Белмәсәң белмәссең, анысы вак нәрсә, әйдә минем белән. Кая дисеңме? Соң, аңгыра,

барып, шул Гомәрне бәргәләп кайтабыз. Йөрмәсен кеше хатыннарын аздырып. Әйдә, әйдә, әле Гомәрне соңгы вакытта машина алырга йөри дип тә ишеткән идем. Ул гына бәхетле булмасын әле. Миңа да бераз шатлык кирәк. Ату быел, минем сыер үлгәч, өч көн бәйрәм итте. Әйдә, тигезләп кайтыйк бәхетләрне. Синең дә күңелең булыр бераз. Елап утырып кына бәхетле булып булмый ул. Бәхетне аны эзләп ала белергә кирәк. Киттек, әйдә...

**Кунаклар**

Күрше Җәмил кичә сөйләп торды. Кайсыдыр бер шәһәр өстендә тагын теге оча торган тәлинкәләрне күргәннәр икән. Имеш, шул шәһәрнең барлык айнык халкы кич буе шуларны карап, күзәтеп торган. Галимнәр дә, бу гаҗәеп хәлне ачу өчен, бөтен көчләрен куялар, ди. Гаҗәп хәл, имеш. Кич буе оча торган тәлинкә күзәткәннәр, имеш. Соң, шул ук Җәмил үзе ул тәлинкәләрне эчкән саен күзәтә иде бит. Хатының мишәр булгач, күзәтми дә хәлең юк. Сервантларында ватылырлык савыт-саба бетеп, гаиләләре белән калай кәндидән ашауга күчкәч кенә бетте аның бу астрономик күзәтүләре. Ну, ярар, монысын шулай шаярам гына инде мин. Ә оча торган тәлинкәләр чыннан да бар, минемчә. Мин үзем аларны күргәнем булмады булуын. Ләкин кешеләр сөйләве буенча ул нәрсәләр безнең авылда да байтак кына эшләр майтаргалап торалар икән.

Хәтерлисезме: былтыр Чатан Гариф бер атна югалып торды. Каравыл өендә эчеп утырганда пес итәргә чыккан җиреннән юк булган иде бит ул. Күпме эзләдек без аны су буйларыннан, әрәмәлектән. Табып булмады. Ә Гарифны, бер атна дигәндә, Чумара Касыймы күрше авыл белән ике арада кырда йоклап яткан җиреннән табып кайтты. Тегесе югалганда да ләх исерек булган, табылганда да шулай ук. «Оча торган тәлинкә алып китте мине, экспиримент үткәрергә», – дип әйтә икән үзе. Хатыны уклау белән дә кыйнап караган, ну, сүзендә каты тора, ди. Хатыны: “Шигем бар барын: бу чатан тәре күрше авыл Нәчтүк янында яткандыр, самагун чөмереп», – дип шикләнсә дә,

үзең шәм тотып торган булмагач, тучны әйтеп булмый. Хәзер Гарифка Чатан дип түгел, ЭкспиримИнт Гариф дип йөриләр безнең авылда.
Ә теге чишмә очы Закирәнең кече кызы Галия нишләде? Чистый корсагы күренә башлагач: «Мине дә оча торган тәлинкәгә алып кереп, экспиримИнт үткәрделәр күктән төшкән затлар», – дип әйтә, ди бит. Аны кайда алып кереп, кем нинди экспиримИнт үткәргәндер, анысын белмим. Ну, Галия нәкъ менә Карга Гобәйдулласының теге фермада эшли торган Зөфәренә охшаган малай тапты. Зөфәрне алиментка да бирергә булган да икән үзе, ну, тегесе полициягә баргач әйткән Галиягә кемнәр экспиримИнт ясап йөргәнен. Шулай була ул безнең заманда, авызыңны күбрәк ачып йөрсәң. Хәзер экспиримИнт ясап китәләр үзеңә. Әнә Галия дә күктән алимент көтеп йөри хәзер.
Кыш көне колхузның өч сыерын да шул оча торган тәлинкәдәгеләр генә ычкындырган, имеш. Соң, шулардан башка кем булсын? Бәтәрәй Вазыйх абзый бик уяу каравыллый бит ул ферманы. Аңардан, персидәтел рөхсәтеннән башка, бер сәнәк салам да ала алмыйсың. Ә монда өч баш сыер! «Күрмәдем дә, белмим дә», – дип әйтә, ди, үзе. Ну, ярар, полиция юлында йөртмәделәр үзен. Колхуз рәисе яклап калды аны нигәдер. Теге оча торганнарны әйтәм, туйганнардыр Инде, җыен ясалма ризык ашый-ашый. Аларның да әзрәк итле шулпа ашыйсы килгәндер.
Аннары участкувый Камилне дә үткән айда шул оча торган тәлинкәдәгеләр тотып яргангa охшый. Безнең авылда тагын кемнең башына килсен инде шул тилегә капчык кидереп бәргәләү. Ике атна диярлек урамда күренмәде бит Камил, мескен, шул хәлләрдән соң. Урамга чыга башлагач та, холкы менә гел яхшы якка үзгәрде инде, мин сиңа әйтим. Хәзер ул беркайчан да юкка-барга бәйләнеп йөрми. Әйтәм бит, ул да шул оча торган тәлинкәдәгеләрнең экспиримИнтына эләккән булырга тиеш. Күрәсең, Камилнең башына капчык кидереп, теге затлар берәр төрле нурланыш белән баш миен төзәткәннәрдер аның.
Шулай, оча торган тәлинкәләр безнең авыл халкы өчен бер дә гаҗәп нәрсә түгел ул. Ә безгә ни? Әйдә очсыннар, рәхәтләнеп. Аллага шөкер, күк йөзе

киң. Прастуй кешеләргә зур зыян гына салмасыннар ул күктәге затлар. Ә вактөягенә түзәбез инде без аның.

**Исбатларга кирәк**

– Энем, исәнме! Әй, әй, тукта, кая чабасың шулкадәр? Нәрсә, ашыгам дип, абзаң белән исәнләшмичә дә китәр идеңме әллә? Әле синең шулай койрык чәнчеп йөрүеңне күргәч, уйлап куйдым, мин әйтәм, таң белән бу малай юкка чапмас, аракының бәясен төшергәннәр, йә берәр җирдә ут-мазар бардыр, дим. Тукта инде, тукта, кил яныма, утыр әле. Менә шулай. Соң, сөлә, мишәр әйтмешли, нәрсә булды? Әллә Карга Зәкиенең төпчек кызы, хатыныңны әйтәм инде, өйдән куып чыгардымы? Нәрсә? Кайтып кына барасың? Өйдә кунмадыңмыни? Да-а, энем. Нәрсә дигән сүз инде бу, ә? Соң, кайда кундың инде? Ярар, ярар, селтәмә кулыңны. Нәрсә, теге, шәһәрдән килгән укытучы янындамы әллә? Әйткәннәр иде шул аны шундыйрак дип. Юк, янына барганыңны аңлыйм да бит инде, энем, ну нигә кунып калдың соң? Йокланылган? Һе, уҗым бозавы, шундый хатын янына баргач йоклап яталар димени? Эх, йомшаграклар шул сез хәзерге яшьләр. Бер нәрсәне дә җиренә җиткерә алмыйсыз. Аллага шөкер, үз хатыннарыбызга да җитә иде, башкаларын да кыерсытмый идек. И-и, энем, бабайлар юкка гына «Авыл саен бер хатының булсын» димәгәннәр инде алар. Ә без бабайлар сүзен тыңлый идек. Ну, үзебезнекеләрен дә кимсеткән булмады. Әйе, энем, ир-ат өчен иң беренче урында үз хатыны торырга тиеш. Аннан калганы – башкаларга. Исәнлегең җитсә, кәнишне. Ә хатыннарны нәүмиз итеп калдырудан Ходай сакласын. Бер акыллы бәндә әйткән бит: «Син күпме читтә калдырасың, хатының шулкадәр үк читтән алыр», – дигән. Чү-чү, тукта, йөгермә, өлгерерсең. Әле бит синең башны бу бәладән ничек коткарырга икәнен дә уйлыйсы бар. Мин исән булганда, син кайгырма, табарбыз берәр җаен. Тә-әк, хатыннар дигәннән... Күңелен күрмәсәң, аждаһага әйләнә алар. Олы кеше сүзенә колак сал син, энем. Менә без яшь чакта, иеме, урман кистек бер елны. Ну, җиде-сигез ир инде. Безнең белән

Югары оч Хәниф тә бар. Соң, шул инде, хәзерге муллабыз. Менә шул көн дә зарлана безгә хатыныннан. Имеш, юньләп ашарга да пешерми, өй дә җыештырмый, маллар да аннан-моннан гына каралган. Арабызда мәрхүм Гәрәй абзый да бар иде. Шул сорый инде Хәнифтән: «Энем, син хатының белән ничек йоклыйсың соң?» – дип. Хәниф әйтә: «Мин кеше белән гүпчем йоклый алмыйм, җәелеп ятмасам, тәнем кычыта башлый», – ди. Ну, Гәрәй абзый сабыр гына аңлатты моңа ничек йокларга кирәген. Хатыны белән инде, ызначит. Икенче көнне Хәнифебез урман кисәргә үтүкләнгән ак күлмәк киеп килгән, малай. Ә аның әбәткә дип алган ризыгын күрсәң! Әллә нәрсәләр бар, малай. «Бүген хатын белән ниттек бит әле... бергә йокладык, – ди. – Күзне йомганда, таң беленә башлаган иде инде», – ди. Ә иртән торса, өй җыештырылган, маллар каралган, өс-баш үтүкләнгән, ашарга да пешкән икән. Хатыны, эшкә озатканда: «Җаныкаем, син минем белән кешечә булсаң, мин дә синең белән гел кешечә булырмын», – дип әйткән, ди. Менә шулай ул, энем. Ә син, алмадай хатыныңны калдырып, әллә кайларда кунып йөрисең. Ул да кеше баласы бит. Син юк дип, ул да берәрсе белән... Әй, тукта, тукта, ашыкма. Тыңлап бетер. Егет булсаң, син тегендә дә, монда да өлгерергә тиеш – аңладыңмы? Тә-әк, ә хәзер болай итәбез. Син хәзер башыңны иеп кенә кайт, иеме, өегезгә. Йомшак кына аңлат хәләл җефетеңә, шулай-шулай, диген, абзый белән кичә күбрәк кабылган да, шунда авып йоклаганмын, диген. Ышанмаса, безгә килеп сорасын. Мин монда әбиеңне дә җайлап куярмын. Кара аны, ялгыша күрмә. И ни... хатыныңны бәхилләт. Исбатлап күрсәт, дим, чынлап та бездә кунганыңны. Җайлангач, берәр «бөгелмәнекен» кыстырып безгә килерсең. Калганын шунда сөйләрмен. Бар, бар, өеңә йөгер! Асыл кошың көтәдер инде дүрт күз белән...

**Сәбәп...**

– Исәнмесез, иптәш директор, чакыргансыз икән...

– Кер, Гафиятов, дөрес, мин сине дәшкән идем, ләкин мин сиңа иптәш түгел. Сиңа иптәш булырга, минем синең белән утырып эчкәнем юк.

– И-и, директор әфәнде, ялгыш, ялгыш, билләһи, ничек инде безнең кебек кара халык сезгә иптәш булсын, ди.

– Йә, ярар, Гафиятов, башымны катырып торма әле монда. Менә кичә син эштә исерек булгансың.

– Кем, минме?

– Соң, син инде, тагын кем булсын. Мин түгел бит.

– Бәрәч, иптәш... гафу, директор әфәнде. Соң, сез кичә исерек түгел идегезмени?

– Нишләп мин кичә исерек булыйм ди, ахмак. Сәбәпсез эчәргә мин бит син түгел.

– Соң, белмим инде, аракысы булса, сәбәбе табыла инде аның. Ә сезнең сейфта аракының беткәне юк аның.

– Кара әле, Гафиятов, авызың нәрсә сөйләгәнне колагың ишетәме синең? Миндә аракы барын-югын тикшерергә кем соң әле син?

– Соң, иптәш... әй, гафу, директор әфәнде, кем дип... алтынчы разрядлы ташчы гына инде мин үзем. Ә бер ящик аракыны теге юлы, сез кушкач, кәбинитегезгә үзем кертеп куйган идем бит. Әле бер атна гына элек...

– Һм-м. Ярар, кертсәң. Монда сүз минем турыда бармый. Син менә миңа әйт: исерек идеңме син кичә, юкмы?

– Исерек?! Юк, директор әфәнде, кичә мин исерек түгел идем.

– Ә менә кайбер иптәшләр киресен раслыйлар.

– И-и, иптәш директор. Кеше өстеннән әләкләп йөрүчеләр сезгә кай арада иптәш булдылар соң әле? Сезнеке кебек затлы кәчтүмем булса, мин ул алак-шалакка таба борылып та карамас идем. Үз дәрәҗәгезне төшереп соң...

– Гафиятов, син монда минем сүзләргә бәйләнеп утырма, яме. Син бу айда гына бишенче тапкыр эшкә исерек килеш килдең бит инде. Ә хәзер заманның нинди икәнен үзең беләсең. Менә эштән куып чыгарсам, белерсең бәрәңге тәмен. Син бит базарда әрмәннәргә алма ташудан башка бер эшкә дә ярамыйсың.

– Беренчедән, иптәш... тфү, шайтан, директор әфәнде, мин биш тапкыр исерек килеш түгел, ә әз генә салган килеш килдем эшкә бу айда. Икенчедән, директор әфәнде, мин бит сәбәпсезгә эчмәдем бер тапкыр да. Менә, билләһи, әгәр...

– Соң, аңгыра, эчкән кеше исерек була бит инде ул.

– И-и, директор әфәнде, бер шешә аракы эчкән төзүче исерек буламыни инде? Аннары көненә ике кешегә бер ярты да салмаган кеше төзүче була аламы соң?.. Менә сез үзегез дә төзелештә утыз еллап бит...

– Тукта, Гафиятов, башымны катырма әле. Синең бит ни... сәбәпләрең дә җыен вак-төяк. Йә син күршеңнең мәчесе үлгән кайгыдан эчәсең, йә үлем түшәгендә яткан җиреннән синең хатыныңның анасы терелә, йә син телевизордан исерек күрәсең...

– Кара әле, иптәш... фу, чёрт, директор әфәнде, хатынның анасының үләм дигән җирдән терелүе сезнеңчә кайгы түгелмени? Берәү, аның белән бер йортта торса, әллә кайчан эчә-эчә саташып беткән булыр иде инде. Ярый әле мин авылда үскән малай, шуңа күрә минем нервлар нык.

– Кара әле, Гафиятов, чыннан да терелдемени хатыныңның анасы, ә?..

– Билләһи, директор әфәнде, ипи менә... Врачлар үлә дигәч, хәер таратырга акчаларга кадәр ваклатып куйган идем инде... Нишләптер кинәт кенә терелеп китте шул. Әллә үлемтеккә дип җыйган акчалары безгә кала дип курыкты шунда...

– Ну, ярар, монысы җитди сәбәп тә булсын, ә үткән атнада нигә исерек идең?

– Соң бит иптәш... тфү, директор әфәнде, хатын анасы белән кунакка китте. Теге Казандагы апаларына. Шундый шатлыктан ничек эчмисең ди инде?!

– Тә-әк, монысы да шулай булсын, ә менә кичә нигә эчтең?

– И-и, директор әфәнде, шундый кайгыдан ничек эчмисең ди инде?!

– Тукта әле, Гафиятов иптәш... фу, шайтан, Гафиятов әфәнде, ә-әй, Гафиятов. Елама әле син, тагы нинди кайгы инде? Нәрсә булды, аңлатып бир әле син миңа?

– Соң, директор әфәнде, өченчекөн телевизор карадым бит мин...

– Карасаң ни булган?

– И-и, иптәш директор, Африкада көн саен, беләсезме, күпме бала ачтан үлә икән? Йөрәгем йомшак бит минем. Шуларны күргәч, төне буе, менә беләсезме, җаным сызланып чыкты. Иртән инде әзрәк күңелем басылмасмы дип тоттым да бераз җиффәрдем. Чистый тынычланган идем инде, менә тагын искә төшердегез бит. Кеп-кечкенә балалар бит... Ачтан үләләр...

– Кара инде сине, ә, Гафиятов. Тукта әле, елама әле, елама әле син. Кеше әллә нәрсә уйлар.

– Уйласыннар. Нишлим соң инде, директор әфәнде, йөрәгем шундый булгач?

– Гафиятов, тукта, дим, елама... Уф-ф. Башым авырта башлады инде монда синең белән...

– Минеке дә... авырта, түзәр хәл юк прәме... Балалар... Ачтан...

– Кара әле, Гафиятов, әллә ниме?.. Әз генә салып биримме? Ни бит...

– Үзегез дә эчсәгез генә, иптәш директор. Берүзем баш төзәтеп утырырга, алкашмы әллә мин? И-и-и, үләм. Башым... Балалар...

– Тәк, мә, Гафиятов, җиффәр шушыны. Мужыт, җиңеләйтеп җибәрер. Ну, минем белән эчкәнеңне кешегә сөйләсәң, куам да чыгарам эштән – аңладыңмы?

– Аңладым, иптәш директор әфәнде. Моннан соң мин гел сезнең белән генә эчәрмен, яме...

– ?!

**Түзәргә кирәк**

– Энем, исәнме! Исәнме, дим, әллә ишетми дә башладың инде син соңгы вакытта? Өсләрең дә бик сәләмә, атлавын да көчкә атлыйсың. Ни эшләр бетереп йөрү әле? Ә-ә, теге кулак Рашатка өй саласызмы? Ишеткән идем кебек шул аны, өй салдыра дип. Калхуздан урлаган акчасын кая куеп бетерсен инде ул?! Әзрәк акчасын түлиме соң үзе? Ярар, ярар, әйтәсең килми икән әйтмә. Мин үзем дә яшь чакта чуваш авылларында дачурта мич чыгарып йөргән кеше, беләм аның җаен. Соң, энем, акча кирәк булдымыни

шулкадәр? Хатынга кышкы пәлтә кирәк, дисеңме? Хатыннарга, энем, кирәкмәгән нәрсә юк инде ул. Аннары хатын-кыз шундый бит ул: аңа бөтен нәрсә аз тоела. Шуларга җиткерәм дип, ир-ат башы күпме михнәт күрә.

Әнә Кәкре Гамилне беләсең бит, иеме. Хәзер генә шундый кырын муенлы ул. Яшь чагында бер дә андый түгел иде. Ул бит соңрак, яше утызга җиткәч кенә өйләнде. Как раз фермада эшли иде Гамил ул чакта. Өйләнеп берәр атна үткәч, кайсыдыр тилесе әйткән моңарга: «Гамил, хатының яшь, кайнардыр, сиңа көч күп кирәк, шуңа күрә көн дә каймак эч син», – дигән. Ә тегеләрнең үз сыерлары юк. Каян алсын Гамил каймакны? Соң, шул фермадан инде. Элегрәк бит сөтне, бидоннарга тутырып, суытыр өчен, салкын суга утырталар иде кич белән. Иртәнгә тегеләрнең өстенә каймак җыела. Гамил, көч кирәк булгач, җаен тапкан: көн саен, башын бидон авызына тыгып, каймак чөмерә икән. Шулай беркөн, бу төнгелеккә көч җыеп маташканда, кайсыдыр тилесе, арттан килеп, моны «персидәтел килә» дип куркыткан. Гамилнең башын беләсең бит инде, сөт чиләге хәтле. Соң, бу, куркып, башын уңайсызрак борган, күрәсең. Борган да, малай, башы-чурты белән бидонга кысылып калган. Төшкә кадәр шулай бөкрәеп торган, ди. Аннары сварка белән кисеп алганнар башын. Шуннан бирле Гамил каймакны гүпчем ашамый. Җитмәсә, муены да кәкрәеп калды. Менә бит ул хатын-кыз нәфесе нишләтә, энем.

Хатын-кызга бит аңарга менә бер капчык акча алып кайтып бир, иеме, син йоклагач, «Әзрәк яшереп калдырмадымы икән?» дип, тагын синең кесәне актарачак. Җиткерә алмыйсың, энем, аларга бернәрсә дә. Әнә теге сез өй сала торган кулак Рашаты сөйли бит. Язга таба болар көн саен сыерлары бозаулаганны көтәләр икән. Менә бер төнне бозаулаган боларның сыеры. Берне генә дә түгел, икене, ди. Рашат әйтә, хатынны абзарга алып чыгып бозауларны күрсәткән идем, «Их, өч булса тагын да яхшырак буласы икән», – дип әйтә, ди. Менә шулай ул, энем, хатын-кыз заты. Ходай Тәгалә настроениесез чакта яратылган нәрсәләр инде алар.

Менә син дә бөкреңне торгызып йөрисең инде эшләп, хатынга кышкы пәлтә алам дип. Пәлтәдән соң тагын берәр нәрсә сорый инде ул синнән, аннан тагын. Син шулай аңарга җиткерәм дип эшли-эшли исәнлегеңне бетерәсең, ә ул, бала карыйм дигән булып, өйдә ята, күрше хатыннары белән чәйләп-мәйләп, гайбәт сатып йөри. Аннары, исәнлегең беткәч, син аңарга чуртыма да кирәкми башлыйсың. Ә ул әле мукшы алашасы кебек таза була. Аннан беркөнне сине ә-әнә югары очка, теге кире кайтмый торган җиргә илтеп куялар, иеме. Хатының әле, мужыт, тагын кияүгә дә чыгып куяр. Ә сине авылда, эчеп үлде, дип сөйләп йөрер. Бездә шулай бит, хатыннар үлсә – авыр тормыштан, ирләр үлсә – эчеп ычкынды, диләр. Ә синең әнә хатынга кышкы пәлтәлек акча эшлим дип кулак Рашат өендә таш күтәргәнеңне беркем дә искә алмаячак...

Нәрсә дисең? Чукынсын пәлтәсе дә, Рашаты да, дисеңме? Тукта-тукта, энем, чү әз генә. Алай кызып кына булмый ул. Соң, аннары синең хатынны кем киендерә? Син инде, брат, раз аны үзеңә хатынлыкка алгансың икән киендерергә дә тиеш. Нишләп сиңа чәчәктәй яшьлеген бүләк иткән Карга Зәкие кызы кешедән ким булырга тиеш? Ни пайдют, урыс әйтмешли. Син тагы, бу абзый шулай өйрәтте дип, өеңә кайтып сөйләнә күрмә. Бетерәсең аннан башны. Ир-ат чыдарга тиеш инде ул тормыш авырлыкларына. Әйдә, минем әз генә теге балдан куйган бар, шуны авыз итеп китәрсең. Авыр эштән соң бә-әк шәп нәрсә ул. Буыннарыңны язып җибәрә торган. Кара син аны, эшләмим бүтән, имеш. Ир-ат булып тугансың икән инде, энем, түзәргә кирәк бу тормышта, түзәргә...

**Табылыр дүртенчесе дә**

– Тагын кайттым әле мин кияүдән. Өченче тапкыр булса соң, һаман-һаман бер мужик белән торып булмый бит инде. Мин кечкенәдән бер үк күлмәкне дә өч айдан артык кия алмый идем. Әле ярый, монысы белән бер ел диярлек тордым. Үзе тормаслык нәстә дә түгел иде дә бит, ну шул көнчелеге-е-е. Чистый чәчемне агарта язды. Мине әллә бер дә ир күрмәгән нәрсә дип белде.

Үзем көнләшергә артык сәбәп тә бирмәдем инде – бер ел эчендә аның шул ике иптәше белән очрашкаладым. Соң, аның өчен дә көнли башласаң... Аныңча, мин, юрган бөркәнеп, мич артында гына утырырга тиеш, имеш. Утырды ди менә. Туйдырып бетерде, билләһи. Бу түшеңне артык күрсәтмә, бу җиреңне артык ачкансың, монысы болай, тегесе тегеләй, монысын күрәләр, тегесен сизәләр. Һе, сизсәләр ни?! Нәрсә, кешегә күрсәтерлек җирем юкмы әллә?! Ходай биргән байлык бит ул, урлаган түгел.

Әле беркөннәрдә бәйләнеп тора: «Син юри бөтен эчке киемеңне, юып, күршеләрнең коймасына элгәнсең», – ди. «Соң, мин әйтәм, нәрсә, күрше кеше түгелме әллә? Болай да бөтен байлык синеке, аңа шул упаковкасын булса да карарга ярамыйммыни?» Китте шуннан котырып, малай. «Мин, – ди, – сине үзем өчен упаковкаң-чуртың белән алдым, – ди. – Син монда минем гомерлек күршене аздырма», – ди.

Соң, нәрсә дисен инде аңа?! Икенче көнне күршене аздыра торган нәрсәләрне юдым да, малай, урам коймасына элдем. Эштән кайткач, башта бер ярты сәгать дәшә алмыйча торды бу. Аннары келәткә кереп китте. Озак чыкмый торгач, әллә асылындымы бу дип, артыннан керсәм, пычак кайрап утыра бу. Инде: «Суялар!» – дип кычкырып чыгып чаба идем, ул тавык кына чалырга җыенган икән. «Безгә кунаклар килә бүген», – ди бу. «Кемнәр?» – мин әйтәм. «Бик кирәкле кешеләр, – ди бу. – Калхузның мал врачы белән лесник».

Ярар, әзерләдем табынны. Тавыгын да пешердем, бәлешен дә салдым. Караңгы төшәр алдыннан гына килеп керде ике мужик. И-и, аларның мужиклыгы да инде... Берсе пеләш, икенчесе өстәлдәге шешәдән чак кына биегрәк.

Бик кирәкле кешеләр, дигәч, иң кыска күлмәгемне киеп чыккан идем өстәл янына. Соң, ирләргә кемдер ашарга биреп торырга тиеш бит инде. Мин чыккач, иң беренче мал врачы закусить итеп утыра торган бәрәңгесе белән төелде, малай. Көчкә, аркасына каккалый-каккалый, үлемнән алып калдылар үзен. Ә леснигы бөтенләй усак яфраклары кебек калтырана башлады. Соң, ул, шул урманында ятып, хатын-кыз күргән бәндәмени?! Бер-бер артлы бер-

ике рюмка җиффәргәч кенә әзрәк тынычландылар болар. Миңа карый-карый, теге мал врачы дигәне чәенә тоз салды, белсәгез, үзе шуны сизмичә эчеп бетерде. «Чәегез бигрәк тәмле», – дия-дия, алты чынаяк эчте, малай, пеләше дә тирләмәде. Ә леснигы, мәҗлес беткәнче, башын, дивана кеше кебек, як-якка боргалап утырды. Мин плитә янына киләм – баш шул якка борыла, тастымал алырга дип барам – баш икенче якка. Идәнгә төшкән кашыкны алырга дип иелгән идем, лесник дигәнем урындыгыннан авып ук төште. Соң, мужиклар ыслабый бит хәзер.

Ну котырды, болар киткәч, мужик. «Син, – ди, – нигә шундый вәжний кешеләр алдында, мине хур итеп, бөтен могҗизаңны күрсәтеп йөрисең?» – ди. И-и, тагын әллә нәрсәләр әйтте әле, белсәгез. «Соң, мин әйтәм, алар күргәннән генә бернәрсәм дә кимеми дә, артмый да бит минем. Менә, мин әйтәм, хәзер син шул леснигыңа барып агач сорап кара – ярты урманын бушка биреп җибәрә. Ә үзем барып сорасам, үзе үк төяп кайтара да әле». И-и, ирләр аңгыра бит ул. Шул хатын-кыз булганга гына кеше рәтенә кереп йөриләр. Көчкә тынычландырып йоклаттым үзен ул көнне.

Ике-өч көн үттеме икән, өйдә тагын тавыш купты. Көн бик кызу булгач, авыл янындагы елгага су коенырга төшкән идем. Беренче ирем алып биргән купальникны киеп инде. Шунда ук калхузның иң алдынгы тракторчысы да малай-шалай арасында су кереп ята торган булган. Минем күлмәк салганны күргәч, шул батып үлә язды. Көчкә сөйрәп чыгардылар үзен. Соң, кем белгән аның шундый хисле кеше икәнен?! Бу шул ук көнне мужикка ишетелгән инде. Үземне чак кына кыйнамады, малай. Соң, нәрсә була инде бу? Имеш, кыска күлмәк кимә, кешегә күз кысма, су коенма. Нәрсә, мин аңарга теге рабыня Изаурамы әллә? Икенче көнне үк булган нәрсәләремне җыйдым да кайтып киттем үзебезнең авылга. Бетмәс әле мужик. Әле, Аллага шөкер, кияүгә алмаслык түгел мин үзем. Табылыр, язган булса, дүртенчесе дә табылыр...

**Йә үләрсез...**

– Кара әле, энем, кил әле мондарак. Кил, кил, курыкма, ашамыйм мин. Менә баядан бирле тәрәзәдән карап торам: безнең турыдан сигезенче тапкыр узып китәсең бит инде син. Әллә бер дә эшең юкмы синең, ә? Үзең һаман безнең якка таба карыйсың. Мин әйтәм, бу малай юньлегә йөрмидер. Нәрсә, бабаңны тагын эчерергә йөрисеңме әллә син, ә? Ничә тапкыр куып тараттым бит инде үзегезне. Минем карт тилене әйт син, үзенең пеләшендәге чәче хәтле дә аңы юк көенчә, синең кебек яшь кешегә акыл өйрәтергә ярата. Тукта, тукта, дәшми тор син апаң сөйләгәндә, беләм мин. Әле хатыннарны сүгәдер ул. Әйт: сүгәме? Әйсәнә, әйтмәсәң дә беләм инде. Үзе гомер буе мине әрләде, үзенең миннән башка, ачуым бер килмәгәе, әбрәкәйгә барырга да кыюлыгы җитмәде аның. Кеше алдында гына шундый ул. Өйдә, кирәксә, иманын укытам мин аның. И-и, энем, үзем сөйрәдем инде мин тормышны, үзем. Бабаң, дөресен генә әйткәндә, бозау бит ул, шуңа күрә барысына да башлап үзем йөгердем инде. Ул йөрде шунда, кеше саны булып. Яшь чагында да шундый иде, картайгач та шул. И-и, аңарга бит бернәрсә кирәкми. Шул аракы булсын да, берәрсе белән сөйләшеп утырырга булсын. Менә кырык ел торабыз, энем, иеме, кырык ел шулай. Әле менә ул урамда сөйләнеп йөри, «мин үз гомеремдә өч йорт салдым» дип. Мин булмасам салыр иде, ачуым бер килмәгәе. Соң, үзем ияреп килмәсәм, ул, бозау, мине кияүгә дә ала алмый иде бит. Үзем инде, үзем. Ну, башка нәрсәгә кыюлыгы булмаса да, аракы дигәндә, җәһәннәмеңә керә торган кеше иде ул яшь чакта.

Бер елны күрше Гарифларның мунчасына ут капты. Әле бит ул чакта хәзерге кебек пожар машиналары юк иде. Тирә-күрше кайсы – чиләк, кайсы көрәк тотып дигәндәй җыелганчы, мунча дөрләп яна инде, малай. Җитмәсә, халык арасында Гариф үзе дә күренми. Халык елаша башлады, малакаем, Гариф мунчада булып, янып үлә дип белеп. Беркем утка якын килми. Шунда минеке өстенә бер чиләк су койды да китте кереп мунчага. Җибәрмәскә дә маташып караган идем дә, мине дә селтәп кенә ыргытты, гомер булмаганны. Халык тагы да катырак елый башлады, малай, монысы да янып үлә дип. Бермәлне чыга бу мунчадан, нәрсәдер сөйрәп. Гарифның гәүдәсе дип уйлаган идек, ул

сөйрәгән нәрсә кырык литрлы бидон булып чыкты. Чәченнән, киеменнән төтен чыга, малай, ну сөйри бидонны. Аннары белдек: болар Гариф белән аларның мунчасына әче бал куйган булганнар, шуны коткарырга дип кергән икән ул, ә Гарифы, исереп, өйләрендә, караватастында йоклап яткан икән. Утны сүндереп бетергәндә уянып чыкты үзе. Анысы да, иманы беткере: «Әче балны коткардыгызмы?» – дип сорый иң беренче.

Гомер буе шулай икәү эчтеләр инде алар. Боларның эчкән аракыларын Шушмага агызсаң, елга ярларыннан чыгар иде, билләһи. Ярый әнә Гарифы хәзер, олыгайгач, мәчеткә йөри башлады. Әле ураза да тотып маташа, ди. Ә минекеннән булмады инде. Күпме кудым мәчеткә, түбәтәй дә алып кайттым, тәки бармады. «Андагы халык белән гомер буе бергә эчә-эчә дә туйдым инде мин», ди, малай. Шундый булды инде, гомере буе. Нәрсә кушсаң да, «ярар» диде үзе, ну үзенчә эшләде. Соң, әнә хәзер юньләп исәнлеге дә юк бит инде – һаман эчә. Пенсиясеннән, хет егылып үл, бер-ике яртылыкны яшереп калдыра. И-и, аның лыгырдаганын тыңларга менә синең кебекләре дә килә бит аның. Җитмәсә, килгән берсе берәрне кыстырып килә. Әле синдә дә бардыр. Ярар, ярар, боргалама башыңны тиле кеше кебек, беләм мин. Нәрсә, башыңны көзән җыерамы әллә синең дә? Бабаң да кичә пенсия акчасы алган иде шул. Уфылдап ята хәзер караватта. Әйдә, йортсыз еланнар кебек урамда утырмассың, өйгә кер. Йә үләрсез, имансызлар. Син яшь тә бит, бабаң хәзер олыгайды инде. И-и, энем, алай-болай булып үлеп кенә китә күрмәсен инде. Шул булмаса, өйдә бер дә ямь калмый бит. Әле беркөннәрдә, әзрәк авырып, бер өч көн бальниста ятып кайтты бит. Энем, үләм дип торам, өйдә бер эш каралмаган, үземнең дә эшлисе килми. Соң, бардым да, «Өйдә терелтәм мин сине» дип, алып кайттым үзен. Аңардан яшереп кенә куйган җимеш суым бар иде. Шуның белән терелде үзе тагын. Ярар, әйдә, керик өйгә, хәзер мин Югары очка менеп төшәм, утырырсыз иркенләп. Әйдә, әйдә, курыкма. Усал дигәч тә, минем усал булмаган чагым да була ул...

**Матур тормыш**

Запуйга китеп эчә белә торган кешенең, айнып килгән чагында, күңеле үтә дә йомшаручан була бит аның. Әнә, безнең колхоз рәисе Әгъзам да, берәр атна «югалып» торганнан соң эшкә чыккач, янына ни сорап керсәң дә, гаризаңа кул куеп чыгара. Шул күңеле йомшарган вакыты булганга күрә бит инде ул.

Менә нәкъ шундый халәттә чакта, дөресрәге айнып килгән бер сәгатьтә, калтыранган тәннәремне олы юрганга төреп, диванда ятып, телевизордан бер тапшыру карадым. Болай үзем телевизор карауны бик өнәп бетермим мин. Әзрәк салган баштан, хәрефләре җемелдәмәсен өчен, бер күзне кысып, китап укып ятуың лутчы. Ә ул көнне нишләптер каралды инде.

Теге тапшыруда җыен артист-мартистлар, язучылар, тагын әллә кемнәр утыралар ашарга-эчәргә куелган өстәлләр артында. Вакыт-вакыт берсе җырлый, берсе бии, өченчесе җыен юк-барны сөйли дигәндәй, бертөрле исерекләр мәҗлесе кебек нәрсә инде шунда. Аның ише бию-җырлауларны гына безнең авылда да булдыралар аны. Ну, малай, монда шунысы бар: телевизордан күрсәтелгән тапшырудагы мәҗлес халкы бер-берсе белән аралашып та куя инде. Телләреннән баллар тама прәме. «Ханым» да «әфәндем», «мөмкин булсачы» да «рәхим итегез». Шулхәтле матур сайрыйлар – исләрең китәр. Бездәге халык алай ук булдыра алмый. Хатын да нәрсәдер бәйли-бәйли карап утыра бит бу тапшыруны. Бермәлне карасам, мышык-мышык елап утыра бу. «Нәрсә булды, – мин әйтәм, – нигә балавыз сыгасың?» «Әй, – ди бу, миңа карамыйча гына, – эчкәнеңә-тартканыңа да түзәр идем, мәхәббәтем дә бермә-бер артыр иде, әгәр син дә минем белән шулай матур сөйләшсәң, – ди. – Синең бит миңа «яратам» дип әйткәнең генә дә юк», – ди.

Малай, әллә нишләп киттем шунда. Әйтәм бит: күңелнең дә йомшаган чагы. Ну, прәме йөрәкләр чеметеп куйды күкрәгемнең уң якларында. «Соң, мин әйтәм, тиле тәре, узган атнада гына әйттем бит, «яратам» дип. Теге махмырдан интеккәндә, күрше Харислардан бер ярты алып чыккач». Хатын миңа таба кулын гына селтәде дә елавын дәвам итте. «Минем дә матур

яшисем килә, – ди бу, елап туйгач. – Әнә телевизорда ирләр нинди матур киенгәннәр, матур сөйләшәләр».
Шуннан соң, җәмәгать, төн буе тиле кеше кебек уйланып чыктым. Икенче көннән яңача яшәргә карар кылдым. Беренчедән, каты гына итеп мунча ягып кердем. Сакал-мыекларымны кырдым, күрше Харистан чәчне кистердем. Кичтән чиста күлмәк, чалбар үтүкләп куйдым. Хатынга гел матур сүзләр әйтеп кенә сөйләшергә керештем. Дөрес, җиңел генә бирелмәде ул миңа. Шактый гына гәҗит-журналлар актарырга, телевизор карарга туры килде. Мал карау да онытыла язды, ишегаллары да себерелми башлады. Ну, зату авыздан гел матур сүзләр генә чыга. Беркөн, ишек төбендә хуҗасызлыктан аптырап аунап яткан тырмага баскач та, әйтәсе сүзләрне әйтү урынына: «Гафу итегез, ялгыш...» – дип мыгырданып кына куйдым. Фермага эшкә дә көн саен чиста оекбаш киям, өскә хатынның элек яшереп тоткан, култык астына сибә торган нәрсәсен генә сибеп йөри башладым. Хатынга адым саен «яратам» дим. Беркөн юри санап карадым: унсигез тапкыр әйтелде шул сүз. Эчүне дә үзгәртеп җибәрдем. Берәр шешә коньяк алып кайтам да элек шкафта тузан җыеп яткан уймак хәтле генә рюмка белән йотып-йотып кына куям. Күбрәк йотсаң башка китә икән үзе. Тәмәкене дә алыштырырга туры килде. Шундый культурный кеше «Идел» тартмас бит инде. Хәзер фильтрныйга күчтем.
Үземә дә ошый башлаган иде мондый тормыш, җәмәгать, хатын бозды бөтен эшне. Беркөн сарык суярга күрше Харисны дәшәргә кергән бу. Тегесе категорический отказ биргән. «Әфәндеҗ үзе суйсын», – дип әйтә, ди. Аннары: «Тагын одеколон сөртенеп, минем хатынга «ханым» дип дәшсә, вапше, өегезгә ут төртәм», – дигән. Имеш, мин шулай дигәч, Харисның хатыны төн буе йокламыйча, күз яше агызып чыккан. Анысы да: «Нигә Җәмил абый миңа шундый сүз әйтте?» – ди икән. Вәт аңгыра халык, ә! Бер дә культураны аңламыйлар. Ну, минем сөйгәнемә җитә калган. Китте, малай, тезеп беркөнне. Имеш, мин абзар тирәсендә дә эшләмим икән соңгы вакытта, коньяк белән тәмәкегә акча да күп китә икән, өс-башны юып өлгертеп

булмый, тагы әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр. Шулай дип мине сүгә-сүгә елады хатын. Мин мыштым гына биш тәңкәлек чит ил тәмәкесе суырып утырдым. Мине сүгеп арыгач, хатын каядыр чыгып китте.

«Сөембикә» журналыннан тагы да матуррак сүзләр өйрәнеп утыра идем – кайткан бу. Ике шешә «бөгелмәнекен», ун кап «Идел» алган. Хатын кыстагач эчмичә дә булмый бит инде. Салдым мин бу бер литрны. Икенче көнне баш төзәтергә дә калды. Баш бит ул шундый, каһәр: бер төзәттеңме, тагын сорый.

Хәзер без элеккечә яшибез. Аллага шөкер, маллар да каралган, башка эшләр дә бара. Хатынга күптән «яратам» дип әйткән булмаса да, пачти нормальный торабыз үзебез. Вакыт-вакыт, озаграк салмый торсаң, йә, киресенчә, ныграк җиффәрелеп айный алмый интеккәндә, теге телевизордагы кебек матур тормыш сагындырып куя куюын. Хатын да кайчак сәер генә итеп карап куйгалый минем якка, күзләрен яшьләндереп. Ну, хатын яшенә карап кына, бик йомшамый минем күңел хәзер.

**Яратмыйлар мине...**

Кайсы яклап карасаң да, начар кеше түгел инде мин үзем. Ике аягым, ике кулым, башым, гәүдәм бар. Башка кирәкле әгъзаларым да үз урынында, Ходайга шөкер. Үзем пачти уңган да әле. Тәмәке тартмыйм, аракыны чамасын белеп кенә җиффәрәм. Тагын балалар яратам (алар миндә бишәү), кеше хатыннары белән йөрмим (үземнеке ун хатынга тора). Ну, менә прәме, канат куярга да фәрештә итеп очырырга инде. Шул бөтен яхшы сыйфатларым арасында минем берсенә берсе бәйләнгән ике гадәтем бар. Шулар аркасында яратмыйлар мине кешеләр. Беренчедән, минем телем тик тормый. Икенчедән, мин дөреслек яратам. Берәр җирдә хаксызлык күрсәм, дәшми тора алмыйм. Дәшмәсәм, телемне көзән җыера башлый. Бәләкәйдән шундый идем мин. Әби янына күрше карчыгы көн дә чәй эчәргә керә иде. Ә үзенең әбиебезне бер дә чәйгә чакырганы юк. Бер тапкыр, теге кергәч, әйттем мин моңа: «Син, Гыйльмениса әби, безгә кереп көн дә ашап чыгасың, шикәрне дә чынаягыңа өчәр шакмак саласың, бөтенесен санап карасаң, бер

бозау алырлык акчаны ашагансыңдыр син безнең. Булды, хәзер безнең әби көн дә сезгә кереп чәй эчсен, гаделлек кирәк бу тормышта», – дидем. Шуннан соң күрше карчыгы безгә бүтән кермәде. Үземнең әби дә нигәдер аларда чәй эчмәде. Шунда әби әйтте миңа: «Син, бала, үз үлемең белән үлмәссең, – диде. – Сине телеңнән асып куярлар бервакыт». Ачуы да килгән булгандыр инде әбинең, чөнки шуннан алда гына мин безгә авыз ачарга килгән кодагый әбигә безнең әбинең көндез мунчада чәй эчеп йөргәнен әйткән идем.

Мәктәптә сикәлтәле узды минем гомер. Беренче укытучым дәрескә күз төбе кара янган килеш килгәч, бер генә сорау бирдем инде югыйсә: «Нәрсә, – мин әйтәм, – ирегез белән талашкан идегезме әллә, Гөлия апа? Ну, шәп кундырган...» И бетте. Өченче сыйныфны бетергәнче, өчледән югарырак билге куймады ул миңа.

Мин кечкенә чакта олыларны аңламый идем. Үзләре дәрес саен безгә дөресен генә сөйләргә кирәк дип такылдыйлар, үзләре дөреслекне яратмыйлар. Бер тапкыр мине, безгә математика укытучы яшь кенә хатынны дәрестә ниндидер сорау биреп елаткан өчен, ата-аналар җыелышына чакырып китерделәр. Мәктәп директорына шулхәтле кеше алдында теңкәгә тия башлагач әйттем: «Сез, Илһам Исламыч, математика укытучысын яратасыз, мәктәп бакчасында үбешеп торганыгызны да күргәнем бар, ә менә мин аны яратмыйм, чөнки аның керфекләре бозау керфегенә охшаган», – дидем. Шуннан куды мине бу мәктәптән. Чөнки директорның хатыны да укытучы иде. Математика укытучысы да нигәдер китте безнең авылдан.

Ә минем армиядә дөреслек яратуым аркасында күргәннәрем! Җиде йөз утыз көн солдат хезмәтенең дүрт йөз утызын мин гаупвахтада утырдым. Өйрәнеп беткән идем инде мин анда, ну кайтырга вакыт җитте.

Солдат хезмәтеннән кайтканның икенче көнендә үк күрше Халидә апа чиргә сабышты. Кичтән, мине күрергә дип, безгә кергән иде ул. «Солдат хезмәте авырмы, минем малайга да киләсе елга китәргә бит инде», – дип сорашып утыра башлагач әйттем мин моңа: «Синең ул маңкасы агып йөри торган малаеңның аннан исән кайтуы бик шикле. Исән кайтса да, йә гарипләнеп, йә

акылга саегып кайта ул». Шуннан соң Халидә апа уколлар белән генә тора башлады.
Калхузга эшкә кергән идем, армиядән кайткач. Анда да озак эшләп булмады. Шул телем аркасында инде. Гаркум секретаре безнең авылга килгәч, янына барып: «Сез бер дә ана эткә охшамагансыз үзегез», – дигән идем, сорый бу миннән йомшак кына тавыш белән: «Нишләп әле мин ана эткә охшарга тиеш?» – ди. Мин әйтәм: «Калхуз рәисе склад мөдиренә бүген иртән сөйләнеп тора иде, тагын шәһәрдән теге ана эт килә бүген, ит белән бал әзерләп куй, дигән иде. Бәлки, ул сезнең турыда әйтмәгән булгандыр», – дидем. Икенче көнне киттек без калхуздан. Мин дә, калхуз рәисе дә.
Шәһәргә барып бер оешмага эшкә урнаштык. Сигез генә ай эшләдем мин анда. Шулвакыт эчендә ике начальник алышынды, сигез гаилә таркалды. Аннары аннан да кудылар. Шәһәргә килгәннән бирле, егермеләп эш алыштырдым инде мин. Беркайда да сигез айдан артык эшләгән булмады.
Әле менә соңгы вакытта, каравылчы булып, эшкә урнашкан идем дә бу арада больничныйда йөрим. Бер танышлар туйга дәшкәч, килен буласы кешегә: «Бу хәтле кәкре аяклар белән ничек йөри аласың син, сеңлем?» – дигән идем, кияү егете, урындык белән бәреп, аякны сындырды. Чыннан да, кәкре иде бит тегенең аяклары. Шулай. Яратмыйлар дөреслекне бу дөньяда. Нишләргә тиештер инде мин, шундый булып тугач?!

**Үзгәрде халык, мин сиңа әйтим**

Мин үзем баштан ук үзгәртеп коруга каршы булмадым. Базар икътисадына күчүне дә кул чабып диярлек каршы алдым. Булсын әйдә базар да, чурт та, акча эшли алган кеше эшләсен акчасын, урлый ала торган кеше урласын. Ләкин күңелгә мәңге төзәлмәс яра ясаган бернәрсә килеп чыкты соңгы елларда: халык әллә нишләде. Юк, мин теге нәчәлникләрне, коммунист түрәләрне әйтмим. Алар, Аллага шөкер, бар да үз урынында калды. Эшли торган урыннарының исемнәре генә алмашынды. Ә менә безнең ише кара

халык үзгәрде соңгы елларда, нык үзгәрде. Оныттык без, җәмәгать, күршелек, туганлык, дус-ишлек кебек нәрсәләрне.
Элек бит ничек иде?! Пример, бакча сөрергә, ди. Тракторист Җәүдәт белән бер шешә «сәмигулла»ны бөклисең дә кичтән, иртән бакчаң сөрелгән була. Кайгы да юк, хәсрәт тә. Ә хәзер ничек? Машина алам дип тилерә башлаган Җәүдәт эчми. Ну, менә йотмый да инде. Бакчаңны сөргән өчен, ул хәзер утыз тәңкә акча сорый. Бирәсең инде, бирми хәлең юк. Бәрәңге чәчмичә булмый бит инде. Язын-көзен Җәүдәт авылда патша кебек йөри, чөнки бар да аңарга ялына. Аны хәзер авылда беркем дә яратмый. Эчмәгән кешене кем яратсын ди? Менә яңа заман нишләтте кешене?!
Аннан Хрущёв вакытыннан бирле айнымаган мичче Харис та, хатыннар теге тирли торган җирләренә сибә торган сыекчаны эчеп агулангач, эчүен ташлады. Җитмәсә, авылга газ кертә башлаган чакта гына бит, иманы коргыры. Элек, лыкынганчы эчерсәң, әллә нинди мичләр чыгара иде, хәзер акча сорый. Газсыз тужы торып булмый бит инде. Түлисең, ыңгыраша-ыңгыраша булса да. Аны да авыл халкы хәзер яратмый. Газ миче өчен шулхәтле акча да түлә, ярат та, имеш.
Ярат дигәннән, бу базар икътисады безне тәмам илтеп җиткерә, ахры. Теге күрше авылдан Нәчтүк тә, янында кунып чыккан өчен, акча сорый башлаган, имеш. «Миңа теш куйдырырга фәлән мең акча кирәк», – дип әйтә икән. Тешләрен аның бер елны безнең авыл Рәшите койган булган, шуңа күрә безнекеләрдән күбрәк тә сорый, ди. Элек, хатын булмаганда, күңелне бушатып кайтырга бер урын бар иде, мин әйтәм, анысы да бетте хәзер. Бөтенесенә кайдан акча җиткерәсең?! Акчаны аны хатын да ярата. Ә калхузда инде җиденче ай акча күрсәткәннәре юк. Калхуз рәисе шәһәрдәге йортын салып бетермичә күрсәтмәсләр дә.
Аннан элекке тарих укытучысы Гомәр абыйны ал. Элек бөтен авылга коммунистлар партиясенең сәясәтен аңлатып торучы кеше иде бит. Тавышы да зәһәр иде аның. Калхуз радиосыннан чыгыш ясаган чагында, ну, менә прәме Левитан кебек ишетелә иде. Хәзер мулла булырга йөри. Урамда

очраганда да: «Әссәламегаләйкем», – дип кенә күрешә. Үзе теге Левитанныкы кебек тавыш белән мәчет манарасыннан азан кычкыра. Бернинди көчәйткечсез дә күрше чуваш авылына хәтле ишетелә бездә әйткән азан. Шулай барса, чувашлар да мөселманлыкка күчеп бетәрләр инде. Кызык: янәшәдәге урыс авылында даң-доң чаң кагалар, бездә азан әйтәләр. Үзеңне әллә кая эләккәндәй хис итәсең.

Үзгәрде халык хәзер, нык үзгәрде. Элек, калхузда акча түләп торганда, пенсионерларны кешегә дә санамыйлар иде, хәзер авылда алардан да кадерле кеше юк. Пенсияне вакытында бирәләр бит. Картлар хәзер авылда иң бай кеше санала. Кая барып чыгарбыз инде, болай барса бу дөнья? Акчага көйләнгән тормыш та начар түгел түгелен, ну, теге чаклар барыбер сагындыра. Их, бар иде бит, бар иде...

**Кирәкми**

Гомере буе хатын-кыздан да рәхәт тормыш кичерүче юк дип уйлаган Гали, быел Сигезенче мартта хәләл җефете эшли торган бөтен эшне үзе эшләргә булды. «Әйдә, күңеле булсын, шуның өстенә хатын булуның бер дә авыр түгел икәнен дә аңлар, – дип уйлады ул, бәйрәм иртәсендә шыпырт кына торып киенә-киенә. – Хәзер тиз генә кибеткә барып кайтырга да аннары тиз генә ашарга пешереп алырга булыр. Ә өйне җыештырып алу – совсем пүчтәк эш ул».

Ләкин кибеттән тиз генә әйләнеп кайтып булмады. Бөтен җирдә әйбер тулып ятса да, нәкъ менә кирәклесен эзләп җаны чыкты Галинең. Алдан уйланылган бар әйберне дә алып бетергәч, ул кибетләрне дә, кибетчеләрне дә күралмас дәрәҗәгә җиткән иде инде. Гали кайтканда, хатын йокыдан тормаган иде әле. «Ярар, йокласын, – дип уйлады ул. – Ашарга пешереп алырга кирәк».

Бәйрәм табыны әзерләү алай җиңел генә булмады. Кишер тураганда, Гали бармагын өзеп чыгара язды, җитмәсә, камыр басып изаланганда, тозлап-борычлап плитәгә куелган зәңгәр тавык, гомумән, каралып китте. Өстәлгә куелырга тиешле ризыклар пешерелеп беткәндә, Гали кечкенә генә сугыштан

исән чыккан кешене хәтерләтә иде. Эченнән генә ул мартны, хатын-кызларны һәм Газпромны сүкте. Хатын исә йоклады да йоклады. «Ярар, – дип уйлады кикриге шиңгән Гали. – Бер генә көн».
Өйне җыештыру бик авыр бирелде. «Каян шулкадәр чүп-чар җыела икән?» – Гали тыныч кына телевизор карап утыручы хатынына кырын-кырын карап алгалады. Ләкин ничек булса да, ул кайбер эшләрне үзе эшләргә омтылган хатынын бу көнне эш тирәсенә якын җибәрмәде.
Өстәл әзерләү, балаларны ашату, савыт-саба юу кебек вак-төяк белән мәшәкатьләнеп, Гали көннең ничек үткәнен сизми дә калды. Хатын бүтән эшкә тыгыласы итмәде – газета укыды, телевизор карады.
Ниһаять, кич җитте. Көч-хәл белән ир балаларны йокларга яткырды. Хәлдән тайган Гали, бераз телевизор карарга дип, кәнәфигә чумды. Аның кыл кыймылдатырга да теләге юк иде инде. Шулчак күзе матур күлмәген киеп күрше кәнәфидә утырган хатынына төште. Хатыны аңа, нәрсәдер өмет иткән күз карашын төбәп, ничектер сәер елмаеп тора иде. Бу караштан Галинең башындагы сирәк чәчләре кузгалып куйды. «Йә Ходай, әле бүген моның белән йоклыйсы да бар бит», – дип уйлады Гали һәм, күзләрен йомып, ниндидер караңгылыкка очты...

**Койрык**

Ни дисәң дә, авыл авыл инде ул. Авылда яңа хәбәр яшен тизлеге белән тарала. Көтү озатып кайтканда, чишмә буйларында су алганда, авыл хатыннары, бер-берсе белән мәгълүмат алмаша-алмаша, кем? кемне? кайчан? кайда? ничек? дигән сорауларга җавапларны бик тиз табалар, шуңа күрә авылда кеше ишетмәслек итеп төчкереп тә булмый.
«Җәмилгә койрык үсә башлаган икән» дигән хәбәр авыл эчендә космик тизлек белән таралды. Аны мунчада Җәмилнең үз хатыны гына күргән булса да, монда бер гаҗәп хәл дә юк, авыл авыл инде ул.
Бу галәмәт нәрсә Җәмилнең артына бер атнада үсеп чыкты. Авыл халкы мондый хәлне төрлечә юрады. Берәүләр, чамасын белмичә эчкәннәрдер, дисә,

икенчеләр, берәр зәхмәт-мазарга эләккәндер, диеште. Китап укый-укый сукраеп беткән Күзлек Гамиры, бу хәбәрне ишеткәч, авылда беркем дә аңламаган бер сүз әйтте: «атавизм». Гамир әйткәннәргә берсүзсез ышана торган авыл халкы, нәрсә икәнен чамаламаса да, бу сүзнең юньле әйбер аңлатмавына төшенде.

Ә койрыкка килсәк, әзрәк утырырга комачаулавын һәм арт яктан ямьсез булып кабарып торуын исәпкә алмаганда, ул хуҗасына артык уңайсызлык тудырмый иде. Ләкин адәм баласы койрык белән яши алмый бит инде. Мунча кергәндә Җәмилнең койрыгын күргәч, хатыны башта бот чабып көлде. Аннан, койрыкны капшаштырып карагач, үзалдына: «Саллы гына нәрсә үзе, тик кирәк урында үсмәгән», – дип куйды. Бу хәлдән болай да гаҗиз булган Җәмил аты-юлы белән бер сүгенде дә, тиз генә чалбарын эләктереп, мунчадан чыгып шылды.

Койрыкның нидән үскәнен ул белә иде. Атна-ун көннәр элек, үләр дәрәҗәгә җитеп махмырдан интеккәндә, Җәмил: «Берәр яна торган нәрсәң юкмы?» – дип, ветврач Гата янына керде. Тегесе бүлмәсенең әллә ниткән шешәләр, башка савытлар белән тулы почмагында бераз кайнашкач, бер чиләк сыешлы пыяла савыт табып чыгарды. «Менә монда бер нәрсә бар инде барын, – диде ул, кызгылт көрән төстәге сыеклыкны шешәдә буташтырып. –Яшь бозаулар сәбәпсез үсә алмый интеккәндә, шуларга бирә торган. Эчеп караган нәрсә түгел дә, ну, үзеннән спирт исе килгән кебек. Курыкмасаң, мә, салып бирәм». Җәмил, аз гына уйланып торганнан соң, өстәлдәге калай кружканы Гатага таба этәрде: «Сал әзрәк». «Моны эчеп үлмәсәм, махмырдан ычкынуым бар», – дип уйлады ул, савыттагы сыекчаны иснәп карагач. Бераз су кушкач, Җәмил бу нәрсәнең Бөгелмә аракысыннан бер дә начар түгел икәнен аңлады. Тәмәке тарткач, ул Гатадан тагын берне салдырып эчте. Тегесе исә дүрт күз белән, үлмәсме бу дигәндәй, Җәмилне күзәтте. Җәмил үлмәде. Алай гына да түгел, аның йөзләре алсуланып, күзләре ачылып китте. Башы төзәлгәнгә шик калмагач, Җәмил маллары янына китте. Икенче көнне аның аркадан түбәнрәк бер җире чеметеп-чеметеп кычыта башлады.

Җәмил шуларны исенә төшереп утырды. «Маллар өлешенә кергәнгәдер», – диде ул, койрыгын капшап карап. – Коткарса, бу бәладән шул Гата гына коткара инде». Мондый нәрсә белән врачка баруны Җәмил күз алдына да китерә алмый иде. «Сыерларны дәвалаганны, мине генә дәвалар әле».

Гата аны күңелле генә каршылады.

– Ишеттем, брат, ишеттем синең хәлләрне, – диде ул, көлемсерәп. – Нишләтик икән соң ул нәрсәкәеңне?

– Кис, – диде Җәмил кырт кына. – Имгәнгән сыер койрыгын кисәсең бит.

Гата баш кына какты да шалтыр-шолтыр ниндидер тимер-томыр белән кайнаша башлады.

– Мә, авырттырмасын өчен, әзрәк тотып куй, укол-фәләнем юк, – диде ул бераздан, калай кружкага теге хәерсез сыекчаны коеп.

«Беткән баш беткән, – дип уйлады Җәмил, бер сулышта савыттагыны эчеп бетергәч. – Тагын бер койрык үсмәс әле».

– Синекен кисәрбез анысы, – дип сөйләнде Гата, Җәмил чалбарын төшереп, сәкегә менеп яткач. – Бигрәк матур нәрсә килеп чыккан синең монда.

– Кис тизрәк! – дип ырылдады теге сыекча башына киткән койрык хуҗасы.

Операция авыртусыз узды диярлек. Эш беткәч, билдән түбән өлеше саллы гына марля катламы белән капланган Җәмил бу юлы Гата белән чәкештереп эчте. Дәшмичә генә берәрне тәмәке көйрәтеп алдылар. Кинәт Гата, янәшәсендә утырган Җәмилнең җилкәсенә башын салып, мышык-мышык елап җибәрде.

– Нәрсә булды инде тагын, – диде тегесе, Гатаны читкәрәк этәреп. – Нәрсә балавыз сыгасың?

– Син котылдың, ә менә миңа нишләргә? – Гата, кинәт талпынып, аягындагы резин итекләрен салып ыргытты. Аның аяклары урынында йонлач тояклар тырпаеп тора иде. – Мин дә бер атна интегәм бит инде.

– Да-а, – дип сузды Җәмил. – Синең хәлләр минекеннән хөртирәк икән.

Тагын берәрне тотып куйдылар. Бераздан Гата үзенең күн сумкасына тагын ниндидер тимер-томыр тутыра башлады. Нәрсәгәдер аның кәефе бераз яхшырган иде.

– Әйдә, брат, – диде ул, Җәмилгә күз кысып. – Наилнең өенә төшәбез. Бүген иртән: «Мөгез кисә торган нәрсәләреңне тотып, безгә төш», – дигән иде. Син башыңны төзәтеп киткәч, теге көнне ул да минем янга кереп чыккан иде бит.

Ике дус, чайкала-чайкала, авыл буйлап китеп барды. Фермадагы яшь бозаулар, моңсу мөгрәп, аларны күз карашлары белән озатып калдылар...

**Күбрәк кирәк**

– Энем, тукта әле, кил әле, тәмәке тартып утырыйк икәүләп. Әйдә, әйдә, олы кеше белән сөйләшеп утыру синең кебекләргә файдага гына китә ул.

Кара әле, синең хатының бәбәйләгән дип ишеттем. Дөресме шул? Игезәкләр тапты, дисеңме? Әстәгъфирулла! Бу ач заманада кем игезәкләр таба инде? Бу илдә хәерче болай да җитәрлек бит. Ул гаепле түгел, дисеңме. Шулай энем, шулай, хатын-кыз беркайчан да гаепле булмый инде ул.

Син аларны бу заманда нәрсә ашатып үстерергә уйлыйсың? Әнә бәрәңгене корт ашап бетереп бара, соңгы елларда мал асрыйм дисәң, печәннең дә юньләп булганы юк. Ә аларга бит көн дә витамин кирәк. Хәзерге бала-чага безнең кебек кычыткан, балтырган ашамый. Да-а, эшләр хөрти синең, малай...

Ярар, алай бик бетеренмә әле син, бала ризыгы белән туа ул. Кемнәр соң игезәкләрең? Малай да кызмыни? И-и, Ходаның хикмәте, бигрәк яхшы булган икән. Менә икесе дә малай булса, бик үк яхшы булмаган булыр иде. Нигә дисеңме? Әнә Хәлфә Салихны кара. Аның дүртесе дә малай бит. Эчәләр дә сугышалар көн саен, эчәләр дә сугышалар. Бәләкәе, Салихның пеләшенә тәмәке төпчеге сүндереп, атасыннан пенсия акчасы талый, ди. Хәзерге заманда ир бала үстерүе ай-һай авыр ул, малай. Тәпи йөри башлау белән башта сәпит, аннары матай сорый башлый ир бала. Әзрәк үскәч, кайчан моны

утыртып куярлар икән инде дип кайгырасың... И-и, ир бала белән азапланасың инде ул, энем.

Кыз бала белән, урыс әйтмешли, ещё хуже... Тәпи йөри башлаганчы ук, аллы-гөлле күлмәк, матур туфли, тагы әллә нәрсәләр кирәк була аңа. Ә үсә башлагач... Чәчләрең үрә торыр инде. Хатын-кызның башындагы чәченә генә күпме кирәк бит аның. Чәч киптергеч, тагы әллә нинди ата җәһәннәмнәр. Кыз балага кирәкле кием-салымны әйтеп тә торасы юк инде. Саташтыра ул кыз бала ата-ананы. Ә кызың буй җиткәч кайгырулар? Унбиш яше тулу белән тотынасың инде уйларга, кайчан моны бирәр тилесе кияүгә алыр инде дип. Әнә Карга Зәкиен ал. Чем-кара бөдрә чәчле кеше иде элек, дүрт кызын кияүгә биргәнче, башында бер бөртек чәче калмады. Хәзер бит кияүгә бармыйча гына бәбәй табу мудыда. Вәт көтәсең инде, кайсы хәерсезеннән итәктә бала алып кайтыр дип.

Шулай ул бала үстерүләр... Ә синдә малай да, кыз да бар дисең инде. Да, малай, синең, болай булса, чәчең генә түгел, әллә нәрсәләрең коелып бетәр әле. Бу заманда, дим.

Ярар, ярар, алай бик борыныңны салма. Исәнлегең булса, ике бала үстерүгә генә чыдарлык әле син. Мин әнә җидене үстердем, үлмәдем бит. Ятсаң торып, торсаң ятып кына булмый хәзер. Бар да кырт итеп яшәп, эшләп торалар. Пенсия алыр көн җиткәч, алтысы тезелешеп кайтып җитә. Җиденчесе дә кайтыр иде, ну анысы ерак Себердә. Тиз генә кайта алмый. Шулай, энем, бала үстерү җиңел түгел. Ну, бер дөньяга килгәч, адәм баласы үсә инде ул. Тагын бер-икене алып кайтсагыз, бөтенләй тормышыгыз түгәрәкләнәчәк. Нәрсә? Кирәкми бүтән, дисеңме. И-и, энем, тиле дә инде син. Үзеңә картайган көнеңдә ярдәмче булачаклар бит алар. Юк-юк, бала-чага күбрәк кирәк ул. Дөньяның бөтен яме шуларда бит. Их, яшь шул әле син – аңламыйсың...

**Өйрәнгәнчә**

Соңгы вакытта Фәрит белән Алия бик матур яши башладылар. Әллә егерме елдан артык «Кем кемне җиңәр?» дигән мәсьәләне хәл итү буенча алып барылган астыртын сугыш икесен дә туйдырып җибәрде, әллә балаларның берәм-берәм үсеп аякка басуы үзенекен итте – тынычланды аларның тормышы. Талаш юк, кычкырыш юк, китапларда язганча, «Хәерле иртә!», «Тыныч йокы!», «Ашың тәмле булган, кадерлем» ягъни мәсәлән.

Баштагы мәлне Алиянең кирәксә-кирәкмәсә чәрелдәве туктауга, үзен ничектер ятим калгандай сизгән Фәрит соңгы вакытта аракыдан да бизә башлады. Ә элегрәк иренең атнага бер булса да дуңгыз булып мыркылдаганчы эчүен инде тормыш расписаниесенә керткән Алия үзенең нишләптер чәрелдисе килмәвенә аптырады.

Йортка таң алдыннан таллар арасыннан бормаланып аккан елгаларда гына була торган тынычлык иңде.

Шундый сабырлык рухы белән сугарылган көннәрнең берсендә, тынычлап, тәмләп кенә чәй эчкән мәлдә, үз уйларына чумып утырган Алия мышный-мышный чәй шопыручы Фәриткә карап әйтеп куйды:

– Түбән оч Гамир кичә, базарга барып, хатынына егерме җиде канәфер чәчәге алып кайткан. Тегесенә егерме җиде генә яшь икән әле.

Фәрит бушаган чынаягын хатынына таба сузды.

– Аңгыраның аңгыра инде. Барлы-юклы акчасын да шуның ише юк-барга әрәм итеп бетерә, – диде ул, яңадан чәйгә тотынып.

Алия нигәдер сискәнеп китте.

– Ә менә синең миңа үз гомереңдә бер генә тапкыр да чәчәк бүләк иткәнең юк, Фәрит, – диде ул, тәрәзәгә карап. – Егерме елдан артык торсак та...

Фәрит чынаягын читкәрәк алып куйды:

– Ә синең үз гомереңдә миңа махмырдан, бер илле грамм булса да, аракы салып биргәнең бармы соң? Гамир үзе аңгырарак булса да, аны хатыны ачы балдан өзми, ичмасам. Андый хатынга чәчәк кенә түгел, әллә нәрсә дә алып кайтып тоттырырсың.

– Әйсәнә, – диде Алия, кулын селтәп. – Сиңа әйткән мин тиле...

– Кара әле, Алия, – диде Фәрит, тавышын күтәрмәскә тырышып. – Хәтерлисеңме: теге сыер икене бозаулаган елны мин сиңа нинди тәмле исле хушбуй бүләк иткән идем?

– Иткән идең, иткән идең. Аннары шул игезәк бозауларны юганда, аракы җитеп бетмәгәч, Җәмил белән шуны үзегез үк суга бутап эчкән идегез. Өч көн йөрдең аннары, киемнән, бөтен җирдән хушбуй исе килә дип.

Алия кинәт сулкылдап куйды. Фәрит, авыр итеп, бер сулыш алды.

– Син бигрәк инде, Алия, – диде ул, аз гына күзен йомып торгач. – Ә хәтерлисеңме: мин сине шәһәргә концертка алып барган идем? Әллә театргамы әле?..

– Менә, менә, – Алия ничектер җанланыбрак китте. – Үзең хәтерләмисең дә шул, чөнки анда баргач та, син шул шәһәр хатыннарының ботларыннан күзеңне ала алмадың. И-и, гомер буе кадеремне белмәдең инде-е. Йә эчтең, йә читкә карадың.

Кинәт Фәритнең күзләре әллә нәрсә эшләп китте. Ул әкрен генә утырган урыныннан торып басты да хатынына таба иелде.

– Ә син минем кадерне белдеңме соң? – диде ул ниндидер ят тавыш белән. – Мин бу йортны салдым, гомер буе калхузда эшләдем. Миндә чәчәк кайгысы булды дип уйлыйсыңмы әллә?

Алия нигәдер урындыгын читкәрәк шудырып куйды.

– Син эшләсәң, мин балалар үстердем, – диде ул еламсырак тавыш белән. – Өйдә дә тик ятканым булмады. Ашсыз тотмадым берегезне дә.

Фәрит, гомердә булмаганны, өйдә үк тәмәкесен кабызды.

– Балалар кемдә дә үсә ул, – диде ул, хатынына нәфрәтле карап. – Әнә көтүче Сабирҗан абзый, хатыны булмаса да, ачтан үлми. Әле корсагы минекеннән дә зуррак, битләре дә елкылдап тора. Ашарга пешердем, имеш... Пешермәскә иде. Йөрергә иде әнә, артыңны сузып, сыер саварга.

Алия дә урындыгыннан торып басты. Аның күзләреннән дә ут бөркелә иде.

– Нәрсә, өйне үзем генә салдым диясең киләме әллә? Ә минекеләр күпме булышты?! Әле ул эчүләрең белән ничек эшеңдә асрадылар үзеңне?..

Фәрит тәмәкесен өстәлдәге чынаякка тыгып сүндерде дә идәнгә үк атып бәрде.

– Синекеләрнең булышуы шул эчкәндә генә булышу иде бит ул, – диде ир, хатынына якынрак килеп. – Алар эчкән аракыны шул ук Җәмилләргә эчергән булсаммы?!

...Бераздан беренче чынаяк идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде. Аннары урындыклар ауды, өстәлдәге савыт-саба эскәтер белән бергә идәнгә төшеп тапталды. Тәрәзәләр арасына эленгән күкеле сәгать кыйшайды. Аннары елтыравык электр самавыры тәрәзәдән тышка очты. Алия гомердә булмаганча чәрелдәде, ә Фәрит, яланаякка галош өстерәп, аракы эзләргә чыгып китте.

Ир белән хатын арасында озакка бармаган тынычлык чоры, ниһаять, ничек башланса, шулай бетеп, алар өйрәнгәнчә яши башладылар...

Гамирның бер бәйләм чәчәге бөтен эшне харап итте.

## Акка кара белән

Повесть

I

Сәхап Әминәсе төш күрде.

Төш шулчаклы ачык, шулчаклы җете иде ки, озын сары чәчләренә буталып йоклап яткан хатын рәхәтлектән өнендә дә ыңгырашып куйды.

...Имеш, ул кош икән. Кош икән дә туган авылы Озын Улак өстеннән очып бара икән. Ә аның ике ягында ике лачын: берсе ак, берсе кара төстә. Алар икесе дә Әминәне саклап бара, имеш. Астан, авылдан, ниндидер тавыш ишетелә. Әминә бу тавышның азан тавышы икәнен аңлый, ләкин азан ничектер сәеррәк яңгырый. Менә Әминә-кошны озатып очучы лачыннар аңа табарак елыша. Алар икесе дә шундый матурлар, алар белән бергә очу шундый рәхәт!..

Үзенең ләззәтләнеп ыңгырашуыннан сискәнеп, хатын уянып китте. Кайда икән мин дигәндәй, як-ягына күз салгач, ул өендә икәнен төшенде. Әле генә күргән төш шундый матур иде ки, хатын ник уянуына үкенеп куйды. «Кара әле, – дип уйлады Әминә, салкынча идәнгә торып баскач, – нәрсәгә булыр икән бу?»

Ул көзге янына барып басты, тузгыган чәчләрен рәтләде. Көзгедән аңа калку күкрәкле, зәңгәр күзле ярыйсы ук чибәр хатын карап тора иде. «Кияүгә, яхшы кияүгә булырга тиеш бу, – дип, төшен юрады Әминә. – Ә нәрсә, кияүгә чыкмаслыкмы әллә мин? Моңа кадәр юньле ирләр генә эләккәне юк. Җәмил әйтмешли, обкатка үтмәгән нәстә түгел инде түгелен дә бит, ну, ярамаслык та түгел әле үзем».

Җәмилне искә төшергәч, Әминә авыр сулап куйды. Ул аның таза беләкләрен, кәефенә карап төсләрен үзгәртә торган күзләрен, шадрарак битен күз алдына китерде. «Эх, Җәмил! – дип уйлады ул. – Синең кебек кәттә ир миңа эләксәме-е... Ну, үз кәнтәең бар шул».

Әминә, ләззәтләнеп, бер киерелеп алды. «Кара әле, бүген шәһәргә барып кайтасым бар бит минем. Сәрия дә вак-төякләргә заказ биргән иде».

Хатын кулъюгычка барып юынып килде дә ашыга-ашыга киенә башлады. Шәһәргә бара торган автобус кузгалганчы, мәчет янындагы тукталышка

өлгерергә кирәк иде. «Тукталышы тора, мәчете генә юк», – дип уйлады Әминә.

Колга Җәмил күрше чуваш авылында чөгендер көмешкәсен кирәгеннән артыграк эчеп һәм, үзе әйтмешли, «настояший» исереп, авыл халкын «Хак дингә кертермен мин сезне» дип өркетеп йөргән көнне Озын Улакта мәчет манарасы авып төште. Җитмәсә, ауганда, манара янәшәдәге электр чыбыкларына эләгеп, аннан чыккан очкыннардан кайчандыр колхоз рәисләре өчен салынган йорттан үзгәртеп корган мәчеткә ут та капты. Кипкән нарат бүрәнәләренә ут тиз үрләде. Бәхеткә, авыл мулласы Хәниф бу көннәрдә төпчек кызын район үзәгенә кияүгә биреп йөргәнгә, кичке намаз вакытында мәчеттә кеше булмады. Югыйсә, һичшиксез, бу афәттә корбаннар булмый калмас иде.

Кешеләр йөгereште, этләр өрде. Янгын машинасы килгәнче, бар да, кулыннан килгәнчә, утны тыярга тырыштылар. Салкынча булуга карамастан, яланөс кенә ут сүндерүдә катнашкан Карга Зәкие исә чын мәгънәсендә геройлык үрнәге күрсәтте, чөнки аның каралты-курасы мәчеттән санаулы гына адымда урнашкан иде. Хатыннар елашты, ирләр сүгенде. Кайсыдыр «Ур-ра, хөррият килә!» дип кычкырып торучы тиле Сабирҗанның ипи шүрлегенә менеп төште.

Мәчетнең, кем әйтмешли, янасы янгач, олы юлдан ямьсез кычкыртып килүче янгын машиналары күренде. Заман техникасы эшне тиз тотты, мәчетне ялмап алган явыз ут, су һәм күбек ташкынына бирешми булдыра алмады. Ләкин, ут җиңелсә дә, авыл уртасында кукраеп утырган мәчет бинасы урынында кара көйгән диварлары белән күңелгә шом салып торучы шыксыз бер хәрабә генә калган иде инде. Бары тик янгын чыгуның сәбәпчесе – калай белән тышланган айлы манара очы гына уттан исән калды.

Бераздан янган мәчет янында беркем дә калмады. Үз каралтылары тирәсендә очкын-мазар юкмы икән дип каранып йөргән Карга Зәкие дә өенә кереп киткәч, тирә-якка тынлык урнашты.

Күрше авылдан туйганчы бәйрәм итеп һәм «запаска» дип кесәсенә бер шешә «сәмигулла» тыгып кайтучы Җәмилнең, Озын Улакка кергәндә, авызы кипте. Ул караңгылыкка чумган авыл башында шып туктады да шешәдән бер йотым эчеп куйды. Җәмил өчен уртача гына булган бу йотымнан чисталыгы шиклерәк шешә яртылаш бушап калды. Җәмил, бер күзен кысып, авыл өстенә бөркеттәй караш ташлады да, үз өйләре урнашкан якны якынча чамалап, атом бозваткычы кебек, алга омтылды. Бәхетсезлеккә, ул сайлаган юл янган мәчет яныннан уза иде. Мәчетнең янганмы-юкмы икәнен белерлек хәлдә булмаганлыктан һәм юнәлешне чак кына дөрес алмау сәбәпле, Колга Җәмил туп-туры янган диварлар арасына килеп керде. Керде дә, комганга охшаган калай кисәгенә абынып, үзе дымлы, үзе җылы күмерле җиргә ауды. Бер мизгелдән ул сабый бала йокысы белән йоклый иде инде.

Бер төнгә дә йортын хуҗасыз калдыруны җене сөймәгән Хәниф мулла авылга, төн таңга авышкач та, үз машинасы белән кайтып төште. Машинаны ишегалдына куеп өйгә керергә җыенганда гына, ишек төпләрендә басып торучы кешене күреп алды.

– Кайсы йөри төн уртасында? – диде ул.

– Мәчет... мәчет янды Хәниф абый, – диде теге еламсырак тавыш белән. Бу – Сабирҗан иде. – Син киткәнне генә көтеп торган, күрәсең. – Шулай диде дә Сабирҗан лаштыр-лоштыр аякларын сөйрәп чыгып та китте.

Хәниф мулланың кинәт күз аллары караңгыланды, аяк буыннары йомшарды.

– Ничек янды? – дип пышылдады ул авырлык белән генә. – Ничек... янды?

Ләкин аңа җавап бирүче булмады.

Бер минуттан Хәниф мулла мәчеткә таба йөгерә иде инде. «Акчалар, сейф» дигән уй аның аякларына яшь куян тизлеге бирде. Чыннан да, мәчет михрабының идәне астындагы кечкенә генә тимер тартмада Хәниф мулланың байтак кына акчасы саклана иде.

«Харап булдым, харап булдым, чукынгыры», – дип мыгырданды Хәниф мулла, күмерләнгән диварлар арасына килеп кергәч.

Ул, караңгыда абына-сөртенә, мәчетнең михраб өлешенә йөгереп барды. Аннан авыр итеп бер сулады да, шашкан кеше кебек, тимер тартма яшерелгән почмактагы чүп-чар өемен казый башлады.

...Өшеп уянып киткән Җәмил күмер өеменә торып утырды. Күзләре ачылып беткәнче, ул, куен кесәсенә тыгылып, шешәне алды да тагын бер йотып куйды, аннан бушаган шешәне читкә ыргытты. Кайда ятам икән мин дигәндәй, як-ягына каранды. Каяндыр төшкән сүрән генә яктылыкны исәпләмәгәндә, тирә-як дөм караңгы иде. Шунда Җәмилнең колагына читтәнрәк килгән ниндидер тавыш керде. Кемдер, мышный-мышный, ерак та түгел нидер эшли иде. «Кайда икән соң мин? – дип уйлады Җәмил, торып басып. – Бер дә таныш җиргә охшамаган бу».

Җәмил, чайкала-чайкала, почмактан килә торган тавышка таба юнәлде.

Никадәр тырышып эшләсә дә, Хәниф мулла кинәт артында кемдер басып торуын тоеп алды. Чемердәп киткән тәне аны күмер арасында казынуыннан туктарга мәҗбүр итте. Болай да ярсып типкән йөрәге, урыныннан кузгалып, бугазына таба менә башлады. Ул әкрен генә артына таба борылды һәм һавадан төшкән сүрән ай яктысында озын буйлы кап-кара куркыныч бер затның үзенең бугазына үрелүен күрде. Хәниф мулланың чәчләре үрә торды, тыны кысылды.

– Җен... – дип пышылдады ул, кинәт хәле бетеп, – җен... – Хәниф мулла, ухылдап, күмерле идәнгә егылды.

Озын Улак, мәчете яну өстенә, мулласыз да калган иде...

Мәчет яну вакыйгасы йөзгә якын хуҗалыклы Озын Улак халкын Бер мәлгә аптыраашта калдырды. «Мәчете чукынсын, мулласыз нишләрбез? – диеште картлар. – Үлә-нитә калсаң ясин чыгарга да кеше юк бит». Ләкин изге урын буш булмый дигәндәй, озакламый авыл имамы урынына Чатан Мөнир менеп утырды.

Мәчет яну авыл өчен эзсез генә үтмәде. Озын Улакта берсеннән-берсе гаҗәп һәм сәер хәлләр була башлады.

II

Әле яңа гына өченче иреннән аерылып кайткан Сәхап Әминәсе, шәһәргә базарга баргач, негр күреп кайтты. Озын буйлы, бөдрә чәчле, ләкин мескенрәк кыяфәтле бу кара ир Әминәнең нечкә күңелен шулкадәр тетрәтте ки, ул базарга нәрсә алырга килгәнен дә онытып, авылга буш кул белән кайтты. Өйдә ашык-пошык кына чәй эчкәч, җан дусты Сәрияләргә кереп чыгарга булды. Әле ике генә тапкыр кияүгә барып кайткан Сәрия, ул кергәндә, көзге алдында керфекләрен буяп маташа иде.

– Кара әле, кызый, – диде Әминә, керә-керешкә. – Шәһәрдә мин беләсеңме нәрсә күрдем? Вәт күрдем...

– Нәрсә күрдең? – Сәрия, ялт итеп, ахирәтенә таба борылды.

– Нигыр күрдем, кызый.

Әминә, лап итеп, урындыкка утырды.

– Вәт, менә монысы мужик дисәң дә мужик. Ул буе, ул чәчләре. Бездәгеләр ише генә түгел инде.

– Нәрсә, таныштың дамы әллә? – Сәрия Әминәгә көнләшүле караш ташлады.

– Ул якка бик өлгер бит син.

– Юк, кызый, курыктым. Ну, шә-әп нәрсә күренә үзе. – Әминәнең күз карашлары томанланып куйды.

– Һи, куркытырсың сине ир белән. Артык бер нәрсәсе дә юктыр әле. Күргән-күргән танытып та кайталар аны. Кием-мазар кигәнме соң үзе, нигырларны бит гүпчем шәрә йөри диләр.

– Кызый, чалбары тучны бар иде! – Әминә, күзен йомып, шәһәрдә күргән кара ирне күз алдына китерде. – Күлмәге дә бар иде бугай.

– Әле кичәге гәҗиттән укып утырдым, – Сәрия, ашыкмыйча гына, чәй әзерли башлады, – безнең илдә бит хатыннар ирләргә караганда дачуртага күп икән.

– Соң, шулай булмыйча. – Әминә өстәл янына күчеп утырды. – Әнә авылны гына кара син. Кая карама хатын-кыз, шул Җәмилне санамасаң, бер юньле ир-ат юк.

– Да-а, эчә торган булса да, әле дә шул Җәмил бар. – Сәрия чынаякларга чәй агызды. – Ул да булмаса, саргаеп үләсең бу авылда.

Хатыннар, дәшми генә, һәркайсы үз уйларына чумып, чәй эчтеләр.

– Кара әле, кызый, – диде Әминә, чынаягын каплап куйгач, – ул нигырлар үзләрендә чыннан да гел ялангач йөриләрме икән?

– Чын инде, чын! – Сәрия дустына табарак иелде. – Беркөннәрдә телевизордан үзем күрдем. Бөтенесе анадан тума, кызый.

Ике ахирәт тагын әзрәк дәшми тордылар.

– Вәт кешеләр яши диген, ә, – дип, тынлыкны бүлде Әминә. – Кием дә кирәкми, газга түлисе дә юк. Банан, әфлисун ише нәрсәне дә агачтан гына өзеп алырга. Без ятабыз инде монда, интегеп. Бернәрсә күргән юк.

– Кара әле, кызый, – Сәрия җанланыбрак китте. – Вәт шул нигырны авылга алып кайтырга, иеме.

– Шәп булыр иде ул, – диде Әминә дә, үзенең ниндидер уйларыннан көлемсерәп. – Андый гәүдә булгач, печәнне дә шәп чабадыр ул.

– И-и, син бигрәк инде, кызый. Кем инде андый ирдән печән чаптыра? Аннары алар, гел теге банан гына ашарга өйрәнгән булгач, гүпчем печән чапмыйлардыр. Әллә филләргә дә печән әзерлиләрме икән?

Сәрия филгә күпме печән кирәклеген күз алдына китерде дә башын чайкап куйды. «Әле дә бездә сыер гына асрыйлар, Ходайның рәхмәте», – дип уйлады ул.

– Сәрия, – диде Әминә кинәттән генә, – иртәгә шәһәргә барам да алып кайтам мин аны үзебезгә.

– Кит әле моннан, – Сәрия кулын гына селтәде. – Синең белән безнең ишегә карыймы инде шундый шәп мужик?!

– И-и, сине тыңласаң... – Әминә көзге янына барып чәчләрен рәтләштерде. – Син гел шулай дисең инде. Рафаилне дә карата алмыйсың дигән идең дә бит... Карады бит әле. Пачти бер ел тордык, ир белән хатын булып. Ир-ат дивана бит ул: кирәкле кылларын чиертә белсәң, бөтенләй акылын югалта. Ир-ат затыннан булгач, бу кара нәрсә дә шундыйдыр әле...

– Соң, ә авыл халкы нәрсә әйтер? – диде Сәрия, күзләрен шардай ясап. – Син бигрәк Инде. – Кап-кара бит ул...
– И-и, кара булса соң, – Әминә көлеп куйды. – Бездәгеләр әнә эчә-эчә зәңгәрләнеп беткән дә бит... Кара түгел җәһәннәм төсле булсын, чын ир генә булсын ул. Барам да алып кайтам. Өем зур, бакчам бар – торырбыз әле. Бигрәк кыяфәте мескен иде бит. Ике дә уйламыйм, алам да кайтам үзен. Өйдә өченче мужиктан калган кием җитәрлек, үзебездә барыбер юньле ир табып булмый...
Икенче көнне иртәнге автобус белән Әминә тагын шәһәргә китеп барды. Ә бер көннән алагаем буйлы, бөдрә чәчле чем-кара бер ир Әминәләрнең ишегалдында нидер майтарып йөри иде инде...

**III**

«Сәхап Әминәсе кияүгә чыккан икән» дигән гаҗәеп хәбәр авылга тиз таралды. Берәүләр гаҗәпләнде, икенчеләр көлде, ләкин, тулаем алганда, Озын Улак халкы артык шаккатмады. Авыл халкының гомуми фикерен Гариф әйтте: «Әминә зәһәр хатын ул. Нигырга түгел, шайтанга чыкса да гаҗәпләнәсе юк монда».
Нәрсә булса да табып баш төзәтергә исәпләп кибет янына чыккан Җәмилгә дә бу хәбәрне Гариф җиткерде.
– Чынлапмы? – диде Җәмил, Гариф бурычка алып чыккан яртының төбендә генә калган сыеклыкка моңсу караш ташлап.
– Халык шулай сөйли инде, – Гариф калганын бүлеп бетерде. Шешәнең бушап калуы Җәмилнең баш миенә гадәттәгечә тәэсир итте: ул, бер күзен кысып, «Тагын кайдан алып кабарга соң?» дигән уйга чумды.
– Әйдә, киттек, – диде ул бераздан, чүгәләгән урыныннан торып. Җәмилнең кая барасын белмәсә дә, Гариф берсүзсез дустына иярде. «Башы булгач, ахырын Җәмил таба инде аның», – дип уйлады ул, атлый-атлый.

– Кая барабыз соң әле без? – диде Гариф, Югары очка таба борылгач. – Фатыймага булса, мин бармыйм. Әле аңа, теге юлы алган өчен дә, фураж китермәгән. Бирмәячәк ул.

– Әминәләргә барабыз, – диде Җәмил кырт кына. – Кияү балакайны күрергә тиештер бит инде без. Бәлки, Әминә минем беренче мәхәббәттер һәм дә минем йөрәгем янадыр.

Башы төзәлеп җитмәсә, Җәмилнең шулай китапчарак сөйләү гадәте бар иде.

– Әминә – синең мәхәббәт? – башы төзәлгән Гариф көлеп куйды. – Син, ни, бигрәк инде. Кара әле, Җәмил, соң ул нигыр татарча беләме икән соң? Белмәсә уңайсыздыр бит инде Әминәгә.

– Син нәрсә, әллә Әминәгә тел белгече кирәк дип уйлыйсыңмы? – Җәмил, көлемсерәп, дустына карады. – Кирәксә өйрәтер.

– Чыннан да, – диде Гариф, нидер исенә төшкән кешедәй. – Чуртынамы Әминәгә аның теле... Кара әле, килеп җиттек.

Алар чыннан да Әминәләрнең капка төбендә басып торалар иде.

– Хәзер мин керәм, – диде Җәмил Гарифка. – Бер биш минуттан син дә керерсең...

Ләкин керергә насыйп булмады. Аларны тәрәзәдән күреп өлгергән Әминә үзе капка төбенә чыкты.

– Нәрсә бар? – диде ул, тузыбрак торган чәчләрен рәтли-рәтли. Аның иреннәре кызарган, битләре алсуланган иде.

Җәмил игътибарлы караш белән Әминәне баштанаяк карап чыкты.

– Да-а, кызый, – диде ул бераздан. – Сиңа әллә кайчан шул нигыр гына кирәк булган икән шул.

Әминә, оялгандай, башын иде.

– Ярар инде, Җәмил, – диде ул. – Бигрәк кызгандым бит үзен. Казанга укырга дип килгән булган да дакументларын югалткан. Ул арада туган илендә сугыш чыккан. Хәзер кире кайтырлык та түгел, ди. Аптырап йөргән җиреннән алып кайттым инде. Һаман ялгыз да яшәп булмый бит...

– Син ялгыз тора алмыйсың шул, – диде Җәмил җитди генә. – Эш анда түгел, торсын нигырың, бер сүзем дә юк. Ну, без кияүне күрергә тиештер бит инде. Туй-мазар булмый дип аңлыйм мин, ну, никах фурмысын китерик әйдә. Үзем укырмын...
– Юк-юк, – диде Әминә, йөзенә курыккан кыяфәт чыгарып. – Ул бит мөселман кешесе. Көненә биш намазын калдырмый. Әбрәкәйгә дә комган белән йөри. Исеме дә безнеңчә: Мөхәммәт Вәлиулла. Шуңа күрә никахны Мөнир абзыйдан укытырмын дип торам. Тәмәке, аракы кебек нәрсәне гомерендә дә авызына алганы булмаган. Аларда эчкән кешене, ботыннан тотып, агачка асып куялар икән.
– И Ходаем, әле ярый без анда тумаганбыз, иеме, Җәмил, – диде моңа кадәр дәшми торган Гариф. – Коргаксып үләр идең шунда.
– Син аның белән ничек сөйләшәсең соң? – диде Җәмил, Әминәгә карап.
– Соң, аңлашабыз инде шунда, – Әминә тагын башын аска иде. – Инде татарча да өйрәтә башладым үзен.
– Өйрәнәме соң?
– Өйрәнә инде. Тик сүзләре генә мишәрчәрәк чыга...
Шулчак Әминәнең капкасы шыгырдап ачылды, һәм аннан яшь кияү үзе күренде. Үз гомерендә каравылчы Рәшиттән да карарак кеше күрмәгән Гариф артына утыра язды. Җәмил исә селкенмәде дә, киресенчә, ул, гомере буе Африкада яшәгән кеше кебек, нигырга киң итеп елмайды да, беренче булып аның янына барып, ике куллап күреште:
– Әссәламегаләйкем, баҗа, – диде ул, күптәнге танышын очраткандай.
Ни гаҗәп, нигыр да «Вәгаләйкемәссәлам» дип җавап бирде. Тик ул «баҗа» сүзен генә аңлап бетермәде бугай, сораулы карашын Әминәгә юнәлтте. Гариф, ул-бу була калса дигәндәй, арткарак чигенде. Ул «кияү»нең калын беләкләренә бәя биреп өлгергән иде инде. «Ну, берне сыпырса, аз тоелмас», – дип уйлады ул. Ләкин гәүдә ягыннан Җәмил дә нигырдан калышырлык түгел иде.

– Тә-әк, Әминә, – диде Җәмил, күзен кыса төшеп, – киявеңне сручны юарга кирәк – сүзем шул. Бөтенләй каралып китүе бар. Йөгер бер литрга. Баҗа белән танышу хөрмәтенә дә кирәк...

Әминә авыр итеп бер сулады да акча алырга кереп китте.

– Әйдә, Вәлиулла туган, Әминә кибеттән әйләнгәнче, без керә торыйк, – дип, Җәмил дә капкадан атлады. Мөхәммәт Вәлиулла, бернәрсә аңламаса да, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды да Җәмилгә иярде. Әзрәк шикләнсә дә, Гариф та керергә булды. «Бу нигыр эчмәгәч, Җәмилнең берүзенә күп булыр, – дип уйлады ул. – И Ходаем, кеше күрсә ни әйтер икән?..»

Әминә кибеттән бик тиз әйләнде. Нигәдер яшь кияве белән Җәмилне үзләрен генә калдырырга курка иде ул. Хатын кайтканда, ирләр өчәүләп йорт баскычында утыралар иде. Әминә сумкасын Җәмилгә тоттырды да тиз генә аның колагына иелде.

– Мөхәммәткә күрсәтмәгез инде, яме, – диде ул, пышылдап кына. – Аларда йортка аракы кертү дә гөнаһ икән. Кичә Сәрия белән кич утырганнан калган шешәбезне дә бакча башына илтеп томырды. Аннан аның намаз вакыты да җитеп килә.

Әминәнең күз карашы ялварулы иде.

– Син бар, – диде Җәмил әкрен генә, – йә Сәрияләргә менеп төш шунда. Мөселман гаиләсендә хатыннар ирләр арасында буталмаска тиеш.

Әминә баш кына какты да урамга таба атлады. Җәмилне күргәннән бирле, күңеле нигәдер тыныч түгел иде аның, ләкин яшьтән үк Җәмилнең сүзен тыңламый булдыра алмады ул...

...Авыл өстендә, халыкны кичке намазга дәшеп, Мөнир мулланың азан кычкырган тавышы таралды. Азан тынарга да өлгермәде, Озын Улакны җыр тавышы яңгыратты. Югары очтан Түбән очка таба юнәлүче өч ир «Күбәләк»не әйттерәләр иде. Эссе Африканың бер почмагында туган ярым кыргый кабилә малае Мөхәммәт Вәлиулла үзенең ике җан дусты белән яңа тормышка аяк басты. Яшь килен Әминә, кулына акчасын учлап, тагын кибеткә йөгерде. «Махмырдан холкы ниндидер бит, белеп булмый, – дип

уйлады ул үзенең кап-кара сөйгәне турында. – Берне алып куярга кирәк. Их, дөньясы...»

**IV**

Участковый Харис авылга кич белән кайтып төште. Казаннан Озын Улакка кадәр ара, әллә махмырдан интеккәнгә, әллә чынлап та туган яклар сагындырганга, бу юлы бик ерак тоелды аңа. Хәер, сагындыруы да бардыр, ни дисәң дә, бер ай – шактый вакыт ул.

«Йөртәләр инде картаеп беткәч, укытабыз дип, – машинадан төшеп авылга таба атлаган Харис төкереп куйды. – Ай буе җыелып эчеп яту булды укытулары. Әллә шушы яшьтә болай да миңгерәп беткән башка белем керә?!»

Ниһаять, Озын Улакка кайтып төшүенә Харис чыннан да бик шат иде. Шат булмыйча соң, монда бит аның үз җире, үз биләмәсе. Кем каршы төшә ала монда участковыйга. «Теләсә кайсына статья табам, кирәк булса, – дип уйлады Харис, үзалдына елмаеп. – Тиле Сабирҗаннан алып персидәтеленә хәтле минем кулда».

Яшьрәк чакта, әле полициягә эшкә кергәнче, Харисны авылда кешегә дә санаучы юк иде. Әллә егет булып җиткәнче анасының итәгенә тагылып йөргәнгә, әллә мәктәптән үк үтә дә әләкче булганга, аны яшьтәшләре дә үзләренә ияртмәде, авыл кызлары да аңа көлеп кенә карады. Алай гына да түгел, солдат хезмәтеннән, ни гаҗәп, исән-имин кайткан егетне колхозга эшкә дә алмадылар.

«Иркә, синең кем икәнеңне беләм, – диде ул чактагы колхоз рәисе Нургаян абзый. – Сиңа ышанып тапшырырдай эш юк миндә. Сарык көтүен бирер идем, анда әнә Сабирҗан абзыең бар. Мужыт шәһәр тирәсендә берәр эш табарсың...»

Шулай итеп, Харис полициягә эшкә керде. Керде генә түгел, монда ул чистый кешегә әйләнде, һәм, бер җирдән бер җиргә күчеп йөри торгач, көннәрдән бер көнне аны үз туган авылына участковый итеп куйдылар.

Яшьрәк чагында үз шәүләсеннән дә өркеп йөргән Харис хәзер Озын Улакта бернәрсәдән дә курыкмый иде инде. Форма бар, пистолет бар – нигә куркырга? Аннары бу авылда яшәү аны шактый чыныктырды. И-и, нәрсә генә күрсәтмәде инде аңа авылдашлары. Хәер, хәзер авылда шикләнерлек бер Колга Җәмиле генә калды диярлек. Башкалары кайсы утыра, кайсы шәһәргә китеп тайды.

Харис авылга кергәнче караңгы да төшеп өлгерде. Бу юлы караңгы авыл ничектер шиклерәк тоела иде. «Әнә теге тирәк артыннан берәрсе чыгып башыңа тондырса», – дип уйлады Харис һәм, гадәттә, пистолеты эленеп тора торган җирне капшады. Шулчак ул чайкала-чайкала үзенә таба атлаучы шәүләне абайлады. «Кем булыр бу?» Харис адымнарын әкренәйтте, як-ягына карап алды. Ул нәкъ күптән түгел янган мәчет янына килеп җиткән иде. Шәүлә якынлашты.

Харис җиңел сулап куйды. Нидер мыгырдана-мыгырдана атлаучы авылдашы Гариф иде.

– Кайда эчтең болай, ылкынганчы? – диде Харис, үзе янына килеп җиткәч кисәктән генә җиргә таба ава башлаган Гарифны җилкәсеннән тотып.

Тегесе авырайган башын Харискa таба күтәрде.

– Кайда булсын, туйда инде, – диде ул, бераз дәшмичә торгач. Гарифтан үкертеп самогон исе килә.

– Нинди туй тагын? – Харис маңгаен җыерды. – Сишәмбе көнне кем туй үткәрә ди?!

– Әминә кияүгә чыкты. – Гарифның башы тагын салынып төште. – Кияү мировой егет, үзе чиб-бә-ә-әр... – Гариф хырлый башлады.

Харис әллә нишләп китте. «Чукынчык хатын тагын кияүгә чыккан. Әйттем бит мин аңарга, бүтән ир алып кайтасы булма дип». Харис тешләрен шыгырдатты. Киң күңелле Әминә аны вакыт-вакыт ятагына яткыручы авыл хатыннарының берсе иде, шуңа күрә дә Харис Әминәнең бер ирен фермадан дуңгыз урлаганы өчен утыртты, икенчесе, яшәр әмәле калмагач, Әминәне дә, авылны да ташлап, үзе чыгып качты.

«Ну, ярар, – дип мыгырданды ир, инде рәхәтләнеп йоклаучы Гарифны җиргә яткырып. – Монысы да озак тормас. Табарбыз берәр әмәлен. Хәзер пистолетны гына кереп алам да өйләренә барып киләм. Баштан ук авылда кемнең кем икәнен күрсәтергә кирәк яшь кияүгә...
...Әминә чын мәгънәсендә бәхетле иде. Соң, янында шундый ир булсын да, бәхетле дә булма, имеш. Хатын-кызга тагын нәрсә кирәк?! «Мөхәммәтемне эшкә дә җибәрмим, исән генә булсын», – дип уйлады хатын, көзге алдында юеш чәчләрен тарый-тарый. Яшь пар әле генә мунчадан кайткан, һәм биленә ап-ак сөлге генә ураган кияү чәй эчә иде. «Чистый татарча да аңлый башлады үзе». Әминә Мөхәммәтне баштанаяк күздән кичерде. «Шулхәтле мунча чабынып, шулхәтле юынып та агармады бит», – дип уйлады ул. Хатынның үзенә караганын сизгәндәй, тегесе дә Әминәгә таба борылды. Борылды да ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды.
Бүген алар кечкенә генә туй мәҗлесе сыман нәрсә ясадылар. Теге көнне Җәмилләр белән эчкәннән соң, чак кына үлемнән калган Мөхәммәт Вәлиулла үз туенда эчмәде. Хәер, туй дип, Әминә, шул Сәрияне, Җәмилне, Гарифны, Зәйтүнәне генә җыеп, шыпырт кына ясады бу мәҗлесне. Нигырга кияүгә чыкканын кешегә артык ишеттерәсе килмәде дә бит, нишлисең, авыл авыл инде. Җитмәсә, Мөнир мулла никах укудан да баш тартты. «Сеңлем, киявеңне күргәч тә, тәһарәтем бозылды – юньлегә булмас бу», – диде ул.
«Әйсәнә, – дип уйлады Әминә, – миңа никах кирәкмени?! Әнә Җәмил каршы килмәде кияүгә чыгуыма, шул җиткән. Алар Гариф белән икәү бүген дә дөм булдылар...
Әминә тагын Мөхәммәт Вәлиуллага карады.
– Кара әле, Мөхәммәтчик, – диде ул, ирнең таза гәүдәсенә сокланып. – Ә синең илдә, чыннан да, гел шәрә йөриләрме?
Ир елмаеп баш какты. Әминә аны анадан тума килеш учак янында сикереп-сикереп биегән итеп күз алдына китерде. Менә учак яна, аның тирәсендә әле генә уңышлы аудан кайткан ирләр. Барысы да шәп-шәрә, бар да Мөхәммәт

кебек матур гәүдәлеләр. Йөрәкләргә дәрт өстәп, барабан тавышы яңгырый... Хисләргә бирелгән хатын тирән итеп сулап куйды.

– Мөхәммәт, җаным, – дип пышылдады ул, күзләрен йомып, – миңа үзегезчә биеп күрсәт әле, ә!

Мөхәммәт Вәлиулла җилкәләрен сикертеп куйды. Ә нигә биемәскә?! Бу ак тәнле сәер хатын аңа торган саен ныграк ошый иде. Ә мунчасы-ы...

Ул, үрелеп, аш өстәленнән зур гына аш кәстрүлен кулына алды, аның төбенә суккалап карады. Мөхәммәт күзләрен йомды. Аяк астында туган джунглиның җылы җире урынына – сыгылмалы такта идән, кулында «там-там» барабаны урынына тирән аш кәстрүле булса да, ул кинәт үзен туган илендә дип хис итте. Ул кәстрүл төбенә суккалап, борын астыннан үз ыруының яраткан көен көйли-көйли, башта әкрен генә, аннан тизләнә-тизләнә бии башлады. Менә маймыллар сикерешә, менә ач шакал улый, менә джунгли хуҗасы юлбарыс, ырлап, корбанына ташлана...

...«Әле туй һаман бара икән, – дип уйлады Харис, Әминәнең ишек төбенә килеп җиткәч. – Әнә ничек дөбердәтеп биилəр. Үзләре «Күбәләк»не әйттерә бугай. Ну, ничава, хәзер тәртип урнаштырабыз аны. Белсеннәр авылга кем хуҗа икәнен».

Өенә пистолетын алырга кергәч, Харис бер йөз илле грамм капкан иде. Ул, батыраеп, киң итеп, өй ишеген ачып җибәрде. Аның ачулы күзләре өй түрендә чәчләрен тузгытып басып торучы Әминәгә төшеп өлгергән мәлдә генә, ул үзенең өстенә анадан тума шәрә, кап-кара бер кешенең ямьсез ырлап сикергәнен күрде. Ул «суйдылар» дип уйларга да өлгермәде, аңын югалтып, идәнгә авып төште...

**V**

Озын Улакта нигыр яшәве турында күрше авылларда гына түгел, район үзәгендә дә ишетелде, әлбәттә. Тирә-як авыллардагы халык артык гаҗәпләнмәде: Озын Улакта гомер-гомергә ниндидер гайре табигый хәлләр булып торуына өйрәнгән иде ул. Район үзәгендә исә аз гына селкенеп

алдылар бугай – яңа силсәвит рәисе Сабирҗан абзыйны шәһәргә чакырттылар. Моны ишеткән Әминә, силсәвит рәисе кичен районнан кайтканчы, үз-үзенә урын таба алмый интекте, ләкин борчылулар юкка булган икән: Сабирҗан абзый авылга бик кәефле кайтып керде.

«Нинди нигыр булсын, Аксубай ягы мишәре бит ул, хатыны кеше белән йөри башлагач, йортын ташлап, безнең якка килеп чыккан, дидем районалашларга, – дип тынычландырды ул кич белән үзләренә килгән Әминәне. – Сразы фермы мөдире итеп урнашуын әйткәч ышандылар Мөхәммәтнең мишәр икәненә».

Шуның белән әлегә Мөхәммәт Вәлиулла тынычлап Озын Улакта яшәргә мөмкинлек алды. Көн артыннан көн үтте, көннәр кышка авышты. Кышның бер көнендә авылда тагын бер көтелмәгән хәл булып алды. Инде иркенләп авыл урамында йөрергә күнеккән Мөхәммәт Вәлиулла, үзе дә уйламастан, Бәдәр Җиһанының икенче тапкыр теле ачылуга сәбәпче булды. Хәер, башта Бәдәр Җиһанының ничек телсез калуын, аннан, теле ачылып, яңадан ябылуын сөйләп китәргә кирәктер.

Кышның аяз, суык бер көнендә Озын Улак халкын тетрәндергән вакыйга булды: җиде елдан артык телсез булып торган Бәдәр Җиһаны телгә килде. Халык Җиһанның нидән телсез калуын юньләп хәтерләми дә инде, ләкин аның телле чагын күпләр хәтерли, һай, яхшы хәтерли иде. Җыен булыр-булмас сүз сөйләп, озынулаклыларның канына аз тоз салмады үз вакытында бу хатын.

Бәдәр Җиһанының теле аркасында бозылышкан гаиләләр, чиргә сабышкан ир, хатыннар авылның яртысын тәшкил итә дисәк, һич тә ялгыш булмас иде кебек. Җиһан телсез калгач, халык арасында: «Теге яшенләп яңгыр яуган көнне аны яшен суккан икән», – диючеләр дә, «Кассадагы акчасы янганын белгәч телдән язган икән», – диючеләр дә булды. Чыннан да, нәкъ шул көннәрдә Бәдәр Җиһанының гомере буе иреннән яшереп җыйган акчалары чүпкә әйләнде. Ләкин, икенче яклап карасаң, телдән язарга бер генә көн калгач, Җиһан кибеттә мәңге айнымас Озын Җәмилне: «Адикалун эчеп

йөрисең, заразы, кибеттә аяк сыларлык нәстә дә калмады бит», – дип сүккәч, Җәмил: «Яшен суксын иде шул телеңне», – дип каргаган иде. Ничек булса булды, шул көннән соң Озын Улакта тормышлар шактый җайланды. Хәзер авыл кызлары тынычлап кияүгә чыга, егетләр шул кызларга ышанып өйләнә башладылар, эчкән кеше рәхәтләнеп эчте, урлаганы иркенләп урлады. Телле чакта Җиһанны чакрымнан әйләнеп узучы халык бәлагә тарыган хатыннан бер дә шикләнми башлады. Каршы дәшә алмаган хатынга әйтәсе килгәннәр әйтелде, ишеттерәсе килгәннәр ишеттерелде. Тагын шуны әйтергә кирәк: телле чакта Җиһан үзен бер дә начар кеше итеп санамады. Үзенең әче теле, туры сүзе белән кешеләрнең күзләрен генә ачам, дөреслекне белгертәм дип инанган иде ул...

Җиһанның яңадан хәрәкәткә килгән телен беренче булып почта таратучы Халидә татыды. Телсез калганнан бирле Озын Улакның үзәк урамындагы йортының капка төбендә күзләрен генә елтыратып утырырга өйрәнгән Җиһан янынннан баш кагып кына исәнләшеп китеп бара иде ул. Кинәт калын шәлгә төренеп утырган телсез Җиһанның тавышы ишетелде:

– Пенсияне кайчан китерәсең, чатан тәре? Өч ай акча күрсәткәнең юк бит инде. Син дә урларга өйрәнеп беттең. Нәрсә, мине берни белми дип уйлыйсыңмы әллә?

Газеталар тутырган сумкасын күтәреп, җай гына атлап барган Халидә бу тавыштан кинәт сөрлегеп китте. Нигәдер аның күз аллары караңгыланды. Ул, нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачкан гына иде, Җиһанның тавышы тагын ишетелде:

– Бүген үк бөтен акчамны китереп кулыма тоттырмасаң, уртанчы малаеңның Карга Зәкиеннән икәнен бөтен авылга җиткерәм.

Үзе дә сизмәстән, Халидә баскан урынында сикереп куйды да өйләренә таба йөгерде...

Ферма мөдире Закир, каладан килгән «дусларга» соңгы вакытта болай да бик азайган сарыклар арасыннан дүртесен озатып, иркенләп кенә өенә кайтып килә иде. Сарыкларның калага «киткәнен» беркем дә күрмәгәнлектән, һәм аз

гына шайтан суы да йотканлыктан, Закирның кәефе начар булмыйча, башында «Артыгын күрмәсен өчен, участковый Харисны сыйларга кирәк» дигән уй гына бөтерелгәнлектән, ул капка төбендә утыручы Җиһанны абайламады да. Җиһанның кинәт яңгыраган тавышыннан аты өркеп куйгач кына, телсез исәпләнгән хатынга игътибар итте ул. Җиһанның яңадан эшли башлаган «тәмле теле» озак көттермәде:

– Тагын сарык саттыңмы, мир үгезе?– Фирмыны сатып бетерәсең бит инде, йөзең кара нәстә. Тагын бер машина алырга келисеңме әллә?

Сарык сатуының беленүеннән бигрәк, Җиһанның теле кабат ачылудан коты очкан Закир, чанада яткан озын чыбыгын алып, атына кизәнде. Әллә чыбыктан, әллә Җиһан тавышыннан өреккән ат кинәт алга ыргылды. Закир чанадан мәтәлеп төшеп калды. Ул җирдәге бүреген эләктерде дә аты артыннан элдерде...

Җиһанның күршесе Сәкинә, олы кызын шәһәргә озатырга дип аның белән бергә урамга чыккач, капка төбендә шәленә уранып утырган телсезгә игътибар да итмәде. Кызы киләсе атнада кияүгә чыгарга тиеш булганлыктан, ул аңа шәһәр кибетләреннән нәрсәләр алырга кирәклеге турында кат-кат «инструкция» бирә иде. Инде дүртенче тапкыр азык-төлек саналып бетеп, кием-салымга күчкәч кенә, Җиһан утырган яктан мыскыллы көлү ишетелде:

– Нәрсә, күрше, синең бу җиде тапкыр хатын-кыз врачына барган кызыңа да кияү табылдымы әллә? Кайсы диванасы ризалашты?

Сәкинә дә, кыз да телсез калдылар. Аннан, бер сүз дә дәшмичә, икесе ике якка: кыз – авыл үзәгенә, Сәкинә өйләренә таба атылды...

Бу көнне авыл гөж килде. Ирләр хатыннарын кыйнады, мәңге айнымаслар айныды, караклар урлаудан туктады. Җиһаннар урамыннан кеше йөрми башлады. Тик кичкә таба кайдадыр яхшы гына «салып» чыккан Җәмил урам башыннан күренде. Ул Җиһан янына җитәр-җитмәс туктады да бөтен гәүдәсе белән аңа таба борылды. Нәрсәдер әйтергә дип авызын ачкан хатын берәр нәрсә дәшкәнче, Җәмил үзенең күк күкрәведәй тавышы белән сөйли дә башлады:

– Нәрсә, аждаһа, телең ачылдымы әллә? – диде ул, очкылык тота-тота. – Тагын халыкның канына тоз сала башладыңмы? Син нәрсә, дөреслек сөйләп, барысын да куркытып торам дип уйлыйсыңмы әллә? Соң, аңгыра, син сөйләгән әйберләрне бөтен авыл халкы синнән башка да бик яхшы белә бит. Кемнең эчкәне, кемнең урлаганы, кемнең кеше белән йөргәне синнән башка да бөтенесенә билгеле. Әйе-әйе, беләбез дә, яшибез дә, кем әйтмешли. Курыкмый синнән кешеләр, сүзләреңнән генә ояла синең, кәнтәй. Үзең дә яшь чагыңнан юньле хатын булмадың бит син... Хе... Теле ачылган, имеш, авыл тормышын җайлый, кешеләрнең күзен ача, имеш.

Җәмил күзләрен шардай ачып утырган Җиһанга карап торды-торды да китапка язу түгел, телдән әйтергә дә бик авырлык белән генә мөмкин булган бер сүз әйтте. Бу сүздән янындагы агач башында утырган каргаларга кадәр, дәррәү кубып, каядыр очтылар, җир өстенә яткан ак кар сарылангандай булды.

Шул сүзне әйтте дә Җәмил, чайкала-чайкала, үз юлыннан атлады. Аның артыннан нәрсәдер әйтергә дип авыз ачкан Бәдәр Җиһанының авызыннан бер сүз дә чыкмады.

Ул тагын телсезләнгән иде...

**VI**

Әминәнең үзе шәһәрдән ияртеп кайткан Мөхәммәт Вәлиулла исемле нигыр мужигына кияүгә чыгу тарихы еллар томанына төренгән Озын Улак авылы халкын азрак тетрәндереп алса да, аларның яшәешенә артык йогынты ясамады. Шулай ук көтүләр куылды, сыерлар савылды, шулай ук ирләр эчте, аларны хатыннары сүкте, кыскасы, авыл үзенчә яши бирде.

Үз гомерендә беренче тапкыр нигыр күрүдән болай да зәгыйфьрәк акылына зыян килгән участковый Харисны Казанга тиләләр больнисына озаттылар. Авыл буйлап «Ул анда, «Яшәсен иптәш Гитлер әфәнде!» дип кычкырынып, бөтен мескен тиләләрнең котын алып йөри икән» дигән имеш-мимешләр йөрде. Соңгы вакытта авылны дерелдәтеп алган тагын бер генә яңалык

булды: Җәмил эчүеннән аз гына туктап торды. Ләкин бу аңлаешсызлык та авыл халкы өчен уңай хәл ителде: ул тагын эчә башлады.
Хәер, гади кешене суламый торган итеп күз алдына китерү мөмкин булмаган кебек үк, Җәмилне дә эчми торган итеп күз алдына китерү мөмкин түгел иде.
Әминәне бер мәсьәлә борчыды: бер генә документы да булмаган Мөхәммәт Вәлиулланы ничектер рәсми итеп теркәү, ягъни мәсәлән пропискага кертү, паспорт алу. Үзе әйтмешли, сыер койрыгына карап үскән авыл хатыны гына булса да, ул үзенең янган коймак төсле ирен, телендә ят чалымнар булуына карамастан, берничек тә Арслантау чувашы итеп тә, Аксубай мишәре итеп тә күрсәтеп булмаганын аңлый иде. Чит ил кешесенең законсыз рәвештә Озын Улакта торып ятуына иртәме-соңмы кемнең дә булса игътибар итүе дә бар. Ләкин участковый Харис вакытлыча «иптәш Гитлер»га әйләнгәнгә, ә яңа силсәвит рәисе Сабирҗан абзый авырып ятканга, бу мәсьәләгә тотыну мөмкин түгел иде. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китәргә кирәк: авылда Әминәнең кара бәхетеннән көнләшүчеләр булмады түгел. Чыннан да, атналар буе эчмичә тора алган ат кебек таза ирне эләктерүче хатыннан көнләшерлек тә иде шул. Әминә үзе дә соңгы вакытта яшәреп, матураеп китте. «Бу себеркегә шул нигыр гына җитмәгән булган икән», – диеште авыл хатыннарының усалраклары.
...Көннәрдән бер көнне Мөхәммәт Вәлиулла чираттагы кайнар мунчадан соң Әминәгә: «Эшлисем килә», – диде. Хәер, мондыйрак сүзне аның моңа кадәр дә кузгатканы булды, ләкин Әминә яшь ирен кайда да булса эшләтү турында уйлап та карамады. «Син бер эшне җиренә җиткереп эшлисең инде, шул да бик җиткән, җаныкаем», – дип, ул бу юлы да котылмакчы иде дә, Мөхәммәт каты торды: «Эш тап миңа». Әминә уйга чумды. Озын Улакта шул ел саен алышынып тора торган мишәр рәисләр таратып бетерә алмаган колхоздан башка эш табуы мөмкин түгел иде. Ә колхозда нинди эш бар? Әминә колхоз идарәсенә китте. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлаткач, колхоз рәисе Салих Вафич озак уйлап та тормыйча бер генә сүз әйтте: «Фермага».

Беренче көнне Мөхәммәтне фермага эшкә Әминә үзе озатып төште. Алар кайчандыр Мөхәммәттән чак кына аграк шабашниклар салып киткән сыер абзарына килеп кергәч, бер сәбәпсезгә үзалдына мөгрәшеп торучы сыерлар кинәт кенә тынып калдылар. Мөхәммәт, башын боргалап, үзенә ят бу хайваннарны күздән йөртеп чыкты.

– Амина-а, – диде ул, хатынына карап, – нигә алар шундый нәзекләр?

Сөйгәненең сөйләменә өйрәнеп өлгергән хатын шаркылдап көлеп җибәрде.

– Нәзекләр түгел, ябыклар алар, Мөхәммәтчик, – диде ул, көлеп туйгач.

– Ә нишләп?

– Нишләп булсын, юньләп ашатмаганга. Черек саламнан башка ризык күргәннәре юк бит аларның. Ач булгач, әнә нәсел үгезенең дә хәле юк.

Мөхәммәт Вәлиулла муенына чылбыр тагылган үгезгә карады. Аның күзләре сагыш белән тулы иде. Африка малаена сыерлар бик кызганыч тоелды.

– Ә нишләп ашарларына юк соң аларның? – Мөхәммәт үгез янына барып басты.

– Һе, нишләп, имеш, – Әминә иреннәрен бөрде. – Урлап бетергәнгә юк. Фуражны скутниклар сатып эчә, печән белән силосны авыл халкы үз малларына ташый. И-и, мескенкәйләрем. Карале, Мөхәммәт, әйдә фермы мөдирен табыйк, аңлатсын эшне сиңа...

Шулай итеп, Мөхәммәт Вәлиулла Озын Улак фермасында терлекче булып эшли башлады.

Авыл халкы башта «бу корымга баткан нәстә»нең сыерлар арасында кайнашуына көлебрәк кенә караса да, тора-бара хәлләр тамырдан үзгәрде.

Иң беренче эш итеп Мөхәммәт Вәлиулла силос, печән урларга өйрәнгән авыл халкын фермага якын килмәслек итте. Эш болай булды: көннәрдән бер көнне үз атын җигеп фермага печән алырга төшкән Күзлек Гамиры Мөхәммәтнең печән өеме янында нидер кычкыргалап, сикереп-сикереп биеп йөрүенә шаһит булды. Гомере буе китап укыган Гамир, билгеле инде, Мөхәммәттән аның нишләвен сорады. «Вуду», – дип җавап бирде тегесе. Чәчләре үрә торган Гамир, атын чыбыркылый-чыбыркылый, авылга чапты. Шул ук көнне

«Әминәнең нигыры фермы курмысын каргаган икән, аны ашаган мал шунда ук үлә икән» дигән хәбәр бөтен авылга таралды. Моңа артык ышанмаса да, авыл халкы, бәладән баш-аяк дигәндәй, фермага йөрми башлады. Ә үзе белән эшләүче терлекчеләргә Мөхәммәт мал чөгендере хәтле йодрыгын гына күрсәтте – бүтән көрпәгә тиюче булмады.
Мөхәммәт Вәлиулла эшли башлагач, сыерлар күзгә күренеп көрәйде, хәтта ки үгезгә дә җан керде. Сыерларга ашау яхшыру уңай тәэсир итсә, сыер савучыларга Мөхәммәт Вәлиулла үзе берәр ничек тәэсир итте, ахрысы, – алар эшкә вакытында килә башладылар. Алай гына да түгел, эштә соңга кадәр калып эшләүчеләре дә булды.
Колхоз рәисе Салих Вафич, савылган сөт күләменең артуына ышанмыйча, гомер булмаганны, фермага үзе төшеп карады. Чыннан да, сыерлар көр, сыер савучылар да матураеп киткән, ә сыер абзары чиста иде.
Район газетасында басылган сводкада элек терлекчелек буенча күрсәткечләре иң артта булган «Якты юл» хуҗалыгы икенче урынга менде. Күзлек Гамиры моны сенсация дип билгеләде. Берничә көннән элекке ферма мөдире Наилне эшеннән алып, аның урынына Мөхәммәт Вәлиулланы куйдылар. Авыл аһ итте.
Җитмәсә, нәкъ шул көннәрдә авылда яңа имеш-мимешләр таралды...

**VII**

Авыл хатынын шәһәр хатынынннан бик нык аерып торган бер нәрсә бар: ул да булса беренчесенең һәрчак күз алдында булуы. Ягъни мәсәлән, турырак итеп әйтсәң, авыл хатыны, күршесе, авылдашы белмәслек итеп, бернәрсә дә эшли алмый.
Авыл хатыннары үз ишләреннән кайсының табак-савытны икешәр көн юмавын да, кайсының каенанасы белән җан талашуын да, кайсының ире белән аерым йоклавын да белеп торалар. Ә шәһәрдә эш бүтәнчә. Анда күрше – күршене, якташ якташны белми. Бәлки, авыл кызларының соңгы елларда күпләп шәһәргә ыргылу сәбәбен нәкъ менә шуннан эзләргә кирәктер.

Ахирәте Әминә, дүртенче ир итеп, шәһәрдән үзенә Мөхәммәт Вәлиулла исемле нигыр мужигын алып кайткач, Сәрия ничектер боегып калды. Юк-юк, сәбәп монда көнләшүдә генә дә түгел иде, билгеле. Законлы рәвештә генә дә ике ир куенында булган Сәрияне Әминәнең, ирле булгач, үзеннән ничектер читләшүе борчыды. Мәхәббәт килә дә китә – дуслык мәңгелек дигән принцип белән яшәгән хатын ахириен аңлый алмый иде. Ничек инде яшьлек дустыңны, нинди булса да, ир кочагына алыштырырга мөмкин? Соң, таза да булсын, кара да булсын, ләкин ир ир бит инде ул! Нәрсәсе бар икән соң бу Мөхәммәтнең шулкадәр? Сәриягә шул сорау тынычлык бирмәде.

Кеше тормышына, хәлбуки ул үзе бүтәнчә уйласа да, очраклы хәлләр, очраклы эшләр йогынты ясый. Шуңа күрә дә, Мөхәммәт Вәлиулла ферма мөдире итеп куелгач, Сәриянең шул ук фермага бозау караучы итеп урнашуына әллә ниткән сәбәпләр табып булса да, без аны очраклы хәл дип саныйк. Шулай ышанычлырак булыр.

Төбе-тамыры белән авыл кызы булганга, Сәриягә бозау карау күптән күнегелгән эш булып тоелды. Алай гына да түгел, яше инде утыз тирәсендә булып та, ана булу бәхетенә ирешә алмаган хатын, бозауларны чын мәгънәсендә үз балалары кебек яратты. Ул эшли башлагач, моңа кадәр артык тәрбия эләкмәгән яшь бозаулар күзгә күренеп диярлек үсә башладылар, аларның һәрвакыт аслары чиста, улаклары тулы иде. Сүз дә юк, Сәрия бозауларга гына түгел, көн саен бозау абзарына кереп, тикшереп торган яңа ферма мөдиренә дә сирәк кенә карашлар ташлаштырды. Ләкин Озын Улакның иң үткен хатыннары рәтендә йөрсә дә, Сәрия нишләптер Мөхәммәткә авыз ачып сүз дәшәргә базмады. Алай гына да түгел, ул кергәч, нишләптер аның битләре ирексездән алсулана, сулышы ешая иде. «Үзенең артык бернәрсәсе дә юк инде, – дип уйлады Сәрия. – Безнең Җәмил моңардан бернәрсәсе белән дә калышмый ла».

Бозауларның киләчәктә сыерлар булачагын аңлагангамы яисә башка сәбәптәнме, Сәрия эшли башлагач, Мөхәммәт тә бозау абзарына ешлады...

Нәкъ шул вакытта авылда Әминәнең йөрәгенә тоз салган төрле имеш-мимешләр таралды да шул. Бу имеш-мимешләрнең көн геройлары, әлбәттә, Сәрия, Мөхәммәт һәм Әминә үзе иде. Иң аянычы шул: бу сүзләр яңадан телгә килгән Бәдәр Җиһанның авызына да эләкте. Авылның тагын бер үзенчәлекле ягы бар: анда, күңел ачу чаралары аз булганлыктан, сүз йөртү гадәти хәл санала. Бериш халык исә, булмаганны да булды дип, ә булганны ике тапкыр булды дип сөйләп йөрүне үзенең изге бурычы итеп саный, шуңа күрә дә вакыт үтә торды, Әминәгә, Мөхәммәткә һәм Сәриягә кагылышлы имеш-мимешләр йөри торды. Сүз, әлбәттә, Җәмилгә дә ишетелде.

– Кара әле, Җәмил, – диде аңа беркөнне дусты Гариф, алар икәү баш төзәтеп утырганда. – Теге кара малай Әминәне кыерсыта дип сөйлиләр бит әле.

Җәмил сискәнеп китте. Гомер булмаганны, ул инде авызына тидерергә өлгергән чәркәсен яңадан җиргә куйды.

– Ничек кыерсыта? – дип сорады ул, Гарифка кинәт чәнечкелегә әйләнгән куз карашын төбәп. – Кыйный диме әллә?

Сүз уңаеннан шуны әйтеп китәргә кирәк: холкы әллә ни йомшаклардан булмаса да, үз гомерендә хатын-кызга бармак белән дә чиерткән кеше түгел иде Җәмил. Алай гына да түгел, вакыт-вакыт хәләл җефетләренә «акыл өйрәтергә» яраткан ирләрне ул кешегә дә санамый иде.

– Юк ла, – диде дустының нидән болай сискәнүен яхшы аңлаган Гариф. – Ни ди бит, Мөхәммәт, имеш, теге... ни... Сәрияне дә...

Гарифның бу сүзләреннән Җәмил шаркылдап көлеп җибәрде.

– И-и, Гариф, – диде ул, көлеп туйгач һәм чәркәдәге аракыны йотып куйгач. – Шул Әминәне кыерсыту буламы инде? Хатын-кызны аны ул сораган әйберне бирмичә генә кыерсытып була, беләсең килсә. Ә Мөхәммәтнең исәнлеге бар, кайгырма. Әминәгә дә җитәр, Сәриягә дә. Әле әзрәк башкаларга калса да гаҗәпләнәсе юк.

Шуның белән сүз тәмамланды.

Ә Әминәгә килсәк, ул да артык озак кайгырмады. Дөресен генә әйткәндә, ахирие Сәрия белән ни булса да уртак итү аның өчен яңалык түгел иде.

Ягъни мәсәлән, искә төшерсәң, Сәриянең икенче ире, Сәриядән киткәч, Әминәнең өченче ире булып торды. Участковый Харис булмаса, бәлки, әле бүген дә торган булыр иде. Шулай да Әминә хәлне төгәл генә белергә булды. Бер кичне, Мөхәммәт эштән гадәттәге вакытта кайтмагач, ул Сәрияләргә менеп төшәргә карар итте.
Ул килеп кергәндә, Сәрия эштән кайтып, чишенеп кенә маташа иде әле. Әминәне ул бик ачык йөз белән каршы алды. Тиз генә чәй куйды да өстәл тирәсендә кайнаша башлады.
Өстән-өстән генә хәл-әхвәлне сорашкач, Әминә, озын-озакка сузмыйча, төп мәсьәләгә күчәргә булды.
– Кара әле, кызый, – диде ул, өстәл артына утыргач. – Ни бит... авылда әллә нәрсәләр сөйләнәләр. Инде ышанырга да, ышанмаска да белмим. Мөхәммәтнең үзеннән сорарга да кыенсынам...
Әминә сөйли башлагач та, сүзнең ни турында булачагын аңлаган Сәрия авыр сулап куйды. Аннары, бераз читкә карап торгач, Әминәгә таба борылды.
– Дөрес, кызый, – диде ул, тагын көрсенеп. – Бөтенесе дә түгелдер түгелен, ну кайберсе дөрес. Баштан ук шуны әйтеп куям: мин Мөхәммәтне синнән тартып алырга җыенмыйм. – Сәрия тагын бераз дәшмичә торды. – Аннары ни, кызый, мин бит авырлы да әле...
Әминә ни әйтергә дә белмәде.
– Соң... соң... – дип мыгырданды бераздан. – Ни бит, кызый, мин дә ни бит, синең кебек...
Алдан сүз куешкан кебек, кинәт ике хатын берьюлы көлеп җибәрделәр. Көлеп туйгач, Әминә әйтеп куйды:
– Соң, нишлибез инде, кызый?
– Мин табарга булдым, – диде Сәрия, җитдиләнеп. – Үземә иптәш тә булыр...
Бу кичне ике хатын тагын нәрсәләр сөйләшеп беткәннәрдер, анысы билгесез, ләкин шул көннән соң аларның дуслыгы тагын да ныгыды. Иң гаҗәбе шул: авылдагы имеш-мимешләр дә, үзләреннән-үзләре бетеп, бүтән йөрмәс булды...

**VIII**

Көн артыннан көн үтә торды, эссе Африканың куе урманнары арасында дөньяга килгән кап-кара Мөхәммәт Вәлиулла Озын Улак авылының үз кешесенә әйләнде.

Озын Улакта кеше, гомумән, кушаматсыз яши алмаганга, Мөхәммәткә дә үзеннән-үзе кушамат табылды. Авыл халкының олысы-кечесе аны хәзер Чуваш Мөхәммәт дип кенә атый иде.

Кушамат Мөхәммәткә алар Колга Җәмиле белән икәү күрше чуваш авылы Арслантауга, Җәмил әйтмешли, «экскурсиягә» менеп төшкәч тагылды. Арслантауга Җәмил дустын, аның карышуына карамастан, «Мин сиңа настоящий хатын күрсәтәм» дип алып менгән иде. Ике иргә дә, ягъни Мөхәммәткә дә, Җәмилгә дә әллә «экскурсия» нык ошады, әллә башка берәр нәрсә, ләкин аларны Арслантаудан, ике көн үткәч кенә, көч-хәл белән табып, Гариф алып кайтты.

Җәмилгә берни булмаган, ә менә Мөхәммәт бик ябыккан, хәтта ки, ничектер агарыбрак та киткән иде кебек Озын Улакка кайтканда. Шуннан соң аның исеменә Чуваш кушаматы өстәлде дә инде.

Кушаматлы булгач һәм ферма мөдире булып эшләгәнгә, Мөхәммәт тиз арада ачы итеп сүгенергә, мөмкинлеге булганда биш намазын калдырмый торган хак мөселман ире булса да, «нирвысы уйнаганда» «Идел» тәмәкесе тартырга һәм кичләрен, «әзрәк кеше күреп керим әле» дип, аягына галуш кына киеп, капка төбенә чыгып керергә өйрәнде.

Хәзер инде ул нәкъ Аксубай мишәре кебек чеп-чи итеп татарча сөйләшә, әче бал куя, ат җигә һәм, кирәге чыкканда, хәләл җефете Әминәне Җәмилдән өйрәнгән рус сүзләре белән сүгә белә иде. Кыскасы, каралыгын исәпкә алмаганда, Мөхәммәт гап-гади авыл иреннән бернәрсәсе белән дә аерылмый диярлек.

Озын Улак тормышында Мөхәммәт күпме генә тырышса да аңлый алмаган бер генә нәрсә булды: ул да булса дин мәсьәләсе. Кыргый кабиләдә туып

үсүенә карамастан, ислам дине кануннарында тәрбияләнгән Мөхәммәт язмыш шаяруы үзен мөселман авылына китереп ташлаганын аңласа да, моңа күңеле белән ышана алмады. «Ничек инде бер генә хатын белән торган, аракы эчкән, тәһарәтнең нәрсә икәнен дә белмәгән һәм намаз укымаган халык мөселман була алсын?! Юктыр, болар безнекенә охшаган дин генә тоталардыр», – дип уйлады пәйгамбәр исемен йөрткән ир. Мөнир мулла әйткән азанда егерме җиде хата санагач, ул бу уенда ныгыды гына. Ләкин янганы урынына төзелеп килүче яңа мәчет, халыкның изге рамазан аенда ураза тотмаса да авыз ачарга йөрүе аны гел икеләндерә башлады. Ахырда ул бу турыда, җаен китереп, дусты Җәмилдән сорады.

Сорау бирелгән мизгелдә коточкыч махмыр өянәгеннән интеккән Җәмил кул гына селтәде:

– Мөселманнар без, чуваш та, керәшен дә түгел, – диде ул, кул селтәүдән кинәт ярылырдай чатнап киткән башын кысып.

Мөхәммәт тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде дә, Җәмил аны үзенең чалбар төймәсенә тотынып туктатты.

– Нәрсә, ышанмыйсыңмы әллә? – диде ул, йөзен чытып. – Ышанмасаң, хәзер күрсәтәм.

Шуннан соң Мөхәммәт бу турыда бүтән сүз кузгатмады. «Аллаһы Тәгаләнең кодрәте киң, – дип уйлады ул. – Боларда ислам диненең мин белмәгән берәр тармагыдыр, күрәсең».

...Кыш артыннан яз җитте, бәрәңгеләр чәчелде. Авылның изге бер йоласына әйләнгән бу эш вакытында Мөхәммәт сука тотарга һәм инде җылы җиргә чыгып өлгергән колорадо коңгызын чын-чынлап танырга өйрәнде...

...Ире Мөхәммәтнең һаман Озын Улакта документ-фәләнсез яшәп ятуы күңелен тырнап торса да, соңгы вакытта шактый түгәрәкләнеп киткән Әминә, ниһаять, җәй җитүгә бик шат иде: җәй көне бар халык кояшта янып карала, алар арасында Мөхәммәт Вәлиулла да артык күзгә бәрелеп тормаячак. Җәй авыл кешесенә бетмәс-төкәнмәс эш алып килсә дә, гаҗәеп рәхәт вакыт бит. Сабан туйлары, печән өсләре үзе генә дә ни тора...

Сабан туеның нәрсә икәнен Мөхәммәт башта аңламады. Ахырда ул аны, үз кабиләсендәге кебек, мәҗүсилектән калган берәр бәйрәмдер дип уйлады.
– Яңа елдан кала иң зур бәйрәм инде бу безнең, – диде аңа бу турыда Гариф.
– Бу көнне күпме эчсәң дә, беркем бер сүз әйтә алмый...
Үз гомерендәге беренче Сабан туе мәңгегә Мөхәммәтнең исендә калды, чөнки ул анда һаман шул Гариф котыртуы буенча мәйданга чыкты... Һәм инде ничәнче ел рәттән берәүгә дә бил бирмәгән егетне – Бүдәнә Фатыймасының шәһәрдән кайткалап йөрүче кияве Расихны җиңде. Бериш халык, моның белән риза булмыйча, «Африкага кайтып көрәшсен ул!» диешсә дә, беренчелек барыбер Мөхәммәтнеке булды.
Җиңеп алган тәкәне шул ук көнне чалып, кич белән шашлыкка киттеләр.
Авыл читендәге әрәмәлектә чи сарык ите кимереп утырганда, Мөхәммәт үзен нәкъ туган джунглиендагы кебек хис итте. Күктә тәгәрәгән ай да нәкъ андагыча елтырый, баш өстенә иелгән тал ботаклары да андагы агачлар сыман тирбәлә. Җитмәсә, тирә-юньнән чын-чынлап бәйрәм иткән авыл яшьләренең нәкъ джунглидагы кыргый җанварлар авазлары чыгарып акырышуы ишетелә иде.
«Эх, бер генә көнгә кайтып киләсе иде, – дип уйлады Мөхәммәт. – Үзем генә түгел, Әминәне дә, Сәрияне дә, Җәмилне дә, Гарифны да алып кайтасы иде безгә».
Туган иле, нәсел-ыруы сагындырса да, Мөхәммәт инде үзенең тормышын авылдан, фермадагы сыерлардан, Җәмил белән Гарифтан, Әминәдән һәм... һәм... кыскасы, бик күп яңа өйрәнгән нәрсәләрдән башка күз алдына да китерә алмый иде.
...Эх, бар да без уйлаганча гына барса икән ул. Язмыш безнең теләкләрне, уй-хыялларны үз планнарына кертеп эш итә икән. Ләкин ни генә булса да, тормыш дәвам итә. Аяусыз, вакыт-вакыт хаксыз булса да, дөнья матур, дөнья киң ул...

**IX**

Печән өсләре җиткәч, Мөхәммәт Вәлиулла өчен кызу көннәр башланды. Озын Улак кояшы быел Африка кояшыннан бер дә ким кыздырмый иде. Малларга кышлык печән кайтару, силос салырга әзерләнү кебек эшләр артыннан көне буе чабып, кич белән арып-талып кайтып барган Мөхәммәткә чишмә буенда Сәрия очрады. Табигате белән дә бик җыйнаклардан булмаган хатын бөтенләй түгәрәкләнгән иде соңгы вакытта.

– Исәнме, Мөхәммәт, – диде башка чакны чатнап торган Сәрия кыюсыз гына. – Эштән кайтып барышмы?

– Эштән, Сәрия, – диде Мөхәммәт, эре тешләрен елтыратып. – Синең хәлләр ничегрәк соң әле?

Сәрия башын аска иде.

– Бүген-иртәгә китеп тә барырмын инде, – диде ул, бераз дәшми торгач. – Мөхәммәт, ни... син ничек булса да бер генә тапкыр минем янга килеп китәрсең инде, яме. Минем бит бүтән беркемем дә юк.

Мөхәммәт, үзләрен берәрсе күрүе мөмкин икәнен дә уйламыйча, Сәрияне кочаклап ук алды.

– Килмимме соң, – дип пышылдады ул, калын иреннәрен Сәриянең колагына тидереп. – Киләм, Сәрия, киләм. Әле менә Әминә дә...

Чыннан да, Әминә шушы араларда бәби табу йортына китәргә җыена иде.

...Ике хатынның да күңелендә нәрсәләр булганын белү авыр, ләкин игътибарлы кеше соңгы вакытларда Әминәнең дә, Сәриянең дә сагаебрак киткәнен сизми калмагандыр. Алар гына да түгел, хатыннарның билләре калынайган саен, авыл халкы да аларга бүтәнчәрәк карый башлады. Авыл урамнары буйлап төрле сүзләр йөрде. Берәүләр акка караны кушкач нинди төс килеп чыгуын юрады, икенчеләр «юньле булмас бу» диюдән узмады. Җитмәсә, шул ук көннәрдә Сәрия белән Әминәнең бу хәлдә үзләре генә түгел икәне дә ачыкланды, Гариф сүзенә ышансаң, күрше чуваш авылы Арслантаудан да шикле хәбәрләр ишетелде...

– Вәт булдыра ичмасам бу малай, – диде Җәмил Гарифка, алар икәү Арслантаудан Питрау бәйрәмен бәйрәм итеп кайтканда. – Болай булса,

озакламый хатыннарның безне куып чыгара башлавы да бар. Әллә эчүне ташларга инде?..
– Да-а, малай, – диде нидер уйланып баручы Гариф, бу сүзләрдән кинәт абынып китеп. – Юк, Җәмил, мин лутчы хатынны аерам.
Бераз дәшмичә бардылар. Аннары Гариф, нидер исенә төшкән кешедәй, кинәт әйтеп куйды:
– Без ярар, башкалар нәрсә уйлый икән?
Чыннан да, соңгы вакытта авыл ирләренең күбесе хатыннарына шикләнебрәк карый башлаган иде. Моның сәбәбен, Мөхәммәт Вәлиулла пәйда булгач, авыл хатын-кызларының үз килеш-килбәтләренә игътибарны арттыра төшүләре белән дә, соңгы вакытта телевизордан Африка турында күрсәтелә торган тапшыруларның авылда бик популярга әйләнүе белән дә аңлатып була иде...
...Ләкин җәйнең кызу бер көнендә көтелмәгән хәл килеп чыкты: авыл Советына Казаннан шалтыраттылар.
Төшке аш ашап килү сәбәпле йокымсырап утыручы җирле үзидарә рәисе Сабирҗан абзый телефонның кинәт чылтыравыннан дерт итеп китте, аннары, ашыгып, трубкага үрелде...
Берничә минуттан ул җил-җил фермага таба атлый иде инде. «Кара син анны, ә, кара син аны, – дип мыгырданды ул үзалдына. – Ничек була инде бу, ә? Вәт, каенын еккыры».
Калганы тиз арада булды. Шул ук көнне кичкә таба авылга моңарчы Озын Улакта беркемнең дә күргәне булмаган мүгәлдәк арбасыннан да озын ике чем-кара машина килеп төште. Алар, кая барырга икәнен алдан ук белгәндәй, туп-туры Әминәләр янына барып туктадылар. Машиналарның берсеннән килеш-килбәте нәкъ Мөхәммәтнекенә охшаш бер ир, ә икенчесеннән нәсел үгезеннән чак кына калышлы өч егет чыкты. Ни бар икән дип капкадан чыгып килүче Мөхәммәт аларны күргәч егылып китә язды. Башта ул, берни әйтмичә, тораташтай катып калды, аннары, йөгереп килеп, үзенә охшаган кара ирне кочаклап алды. Аны бу мизгелдә күрүчеләр Мөхәммәтнең күзләре

яшьле икәнен абайладылар. Шул арада Әминәләр тирәсенә халык җыелды. Этләр өрде, хатыннар елашты. Силсәвит Сабирҗан абзый җыелган халыкка Озын Улакка Мөхәммәт Вәлиулланы эзләп аның бертуган абыйсы килгәнен аңлатты. Күзлек Гамиры исә җыелган халыкка шатлыклы да, кайгылы да хәбәр җиткерде: Мөхәммәтнең туган илендә сугыш беткән һәм анда ил башына Мөхәммәт Вәлиулла ыруы килгән икән. Бу турыда, имеш, узган атнада ук Мәскәү гәҗитләрендә язган булганнар, тик печән чабу белән мәшгуль булган Гамир бу гәҗитне кичә генә укыган икән.

Ике машина да авылда төн кунды. Иртә белән аларның Мөхәммәтне алып китәчәкләре билгеле булды.

Авыл аһ итте. Бар да Әминә белән Сәрияне җәлләде. Иртән урамга чыккан Мөхәммәт кәчтүм-чалбар кигән, ләкин үзе ничектер боегып калган, хәтта ки агарып та киткән иде.

Мөхәммәт Вәлиулланы озатырга Озын Улакның бөтен халкы килде. Тетрәнгән, сүзсез калган кешеләр төркеме дәһшәтле тоела иде. Машинага утырыр алдыннан, Мөхәммәт күзләре белән халык арасыннан Җәмилне эзләп тапты. Әминә белән дә, Сәрия белән дә ул инде саубуллашып өлгергән иде. Авыл халкына рәхмәт әйтелде.

– Җәмил, – диде Мөхәммәт, дустының җилкәсенә бөдрә башын салып. – Онытмагыз мине, Җәмил... Әминә белән Сәрияне ташлама Инде, туганым.

Халык төркеменнән тагын елау авазлары ишетелде. Мөхәммәт машинага кереп утырды. Инде кузгалып киткәч, ул, тәрәзәдән башын чыгарып:

– Нәчтүнне дә, – дип кычкырды.

Машиналар кызулый башлагач, җыелган халык аның «Мин кайтырмын әле, сыерларны карагыз» дигән сүзләрен ишетте.

– Кайтырсың, – дип мыгырданды башын аска игән Җәмил. – Әлбәттә, кайтырсың.

Аннары ул, башын күтәреп, Гарифка карады.

– Әйдә, Гариф, – диде ул. – Берәр нәрсә табып басыйк йөрәкне...

Кояш болыт астына чумды. Авыл ничектер караңгыланып, моңаеп калды...

Литературно-художественное издание

**Шигапов** Илфак Илдусович

**Потеря**

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Шиһапов** Илфак Илдус улы

**Югалту**

Мөхәррире *З. В. Шәйхразиева*

Рәссамы

Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*

Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы

Корректорлары